1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
2020 ДЕКАБРЬ № 12

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

БАЙ ИР *тэрәкме әллә...*

«КЫШКЫ РОМАНС» *бер җыр тарихы*

әфлисунлы, алмалы ЯҢА ЕЛ ҮРДӘГЕ

Эльмира КӘЛИМУЛЛИНА

«Алтын Казан» – туган җирнең тылсымы!»



СӨЕМБИКӘ 2021

ГЫЙНВАР

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31

ФЕВРАЛЬ

Д	1	8	15	22
С	2	9	16	23
Ч	3	10	17	24
П	4	11	18	25
Җ	5	12	19	26
Ш	6	13	20	27
Я	7	14	21	28

МАРТ

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	31
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	





АПРЕЛЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	
Я	4	11	18	25	

МАЙ

Д		3	10	17	24	31
С		4	11	18	25	
Ч		5	12	19	26	
П		6	13	20	27	
Җ		7	14	21	28	
Ш	1	8	15	22	29	
Я	2	9	16	23	30	

ИЮНЬ

Д		7	14	21	28
С	1	8	15	22	29
Ч	2	9	16	23	30
П	3	10	17	24	
Җ	4	11	18	25	
Ш	5	12	19	26	
Я	6	13	20	27	

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2019



Фото: Анна Арахамия

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Тышлыкта:
Эльмира Кәлимуллина
Фото: Рамил Гали

Верстка:
Резеда Галиуллина
Бүлек мөхәррирләре:
Чулпан Галиәхмәтова
Раилә Хәялиева
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәр:
Олег Сердюк

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 25.11.2020 ел.
Чыгу көне: 4.12.2020 ел.
Заказ А-3225
Тираж 8030

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО "АК БАРС" БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Фото: Анна Арахамия

Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Галәм барлыкка килгәннән бирле кешелек дөньясы төрле катаклизмнар, афәтләр белән очрашып торган. Узып баручы 2020 ел да безнең өчен шундыйлардан булды... Яңа елга аяк басканда алда безнениләр көткәнен күз алдына да китермәгән идек. Кичерешләр, сынаулар, югалтулар... Авыр булды... Әмма без бирешмәдек, яңача аралашырга, яңача яшәргә, эшләргә, өметләнергә өйрәндек. Бергәләп өйрәндек! Ә иң мөһиме – без бергә булдык.

Тормыш бер урында гына тормый. Көенечләрне сөенечләр дә алмаштыра. Узып баручы елны без дә зур сөенеч белән тәмамлыйбыз. Журналистларның «Бәллүр каләм» республикакүләм бәйгесендә «Сөембикә»без «Елның иң шәп редакциясе» дип табылды. Монда, һичшиксез, сезнең дә өлешегез бар! Эшебезгә гадел бәя бирәсез, безне һәрвакыт илһамландырып торасыз.

Журналыбызның һәр санын әзерләгәндә сезне күз алдында тотабыз. Ә бу юлы Яңа ел кәефе тудырсын, тормыш мәшәкатьләрен бераз оныттырып торсын иде дип тырыштык. Әйдәгез, Яңа елны менә шундый рәхәт дулкында – бәхетле мизгелләргә төренеп каршылыйк!

Яратып,
Лариса Маликова

Безнең тышлыкта



«Алтын Казан» – ул гаҗәеп әсәр: затлы музыка, мавыктыргыч эчтәлекле матур әкият. Спектакльне карамыйча, аны тыңлап кына утырсаң да, ул сине искиткеч әкият дөньясына алып кереп китәчәк...

28 Мин ышанам сиңа, Казан!
Эльмира Закирова

Заман һәм без

6 Баллы тормыш баллымы?
Чулпан Галиәхмәтова

16 Җырчы лаборант
Гөлнур Хәсәншина

12 «Иң якын кешем...»
Гөлнур Сафиуллина

18 Яңа ел – могҗиза көтү...
Руфия Рәхмәтуллина

22 «Әз булсын, тәмле булсын...»
Чулпан Галиәхмәтова






Татар дөньясы



24 Челтер-челтер талир тәңкә
Лилия Гәрәева

Мәдәни тормыш



34 Гомернең ике яры
Гөлнур Сафиуллина



38 Асылташ югалмый ул
Чулпан Галиәхмәтова

Яшәеш



48 «Син – гомер агышларым»
Раилә Хәялиева

52 Умка
Асия Юнысова

Хуҗабикә



58 Ә бездә – Яңа ел!
Раилә Хәялиева



60 Яңа ел үрдәге





PRESSA

АКТУАЛЬ ТЕМА

БАЛЛЫ ТОРМЫШ БАЛЛЫМЫ?


Фото: www.pixabay.com

Хатын-кызның табигате шундый: ул көчле ир-атка тартыла. Элек физик көч турында сүз барса (Сабантуй батырына кайсы кыз өмет итмәгән икән?!), хәзерге цивилизациядә көчле ирләр – мөмкинлекләре булганнар, гади итеп әйткәндә, акчасы булганнар. Шуңа күрә көчлеләрне һәм уңышка ирешкәннәрне якын җибәрмәгез, хәерчеләрне сайлагыз, һәрхәлдә, зыяны тимәс, дип кызларга киңәш бирү – беркатлылык. Әмма финанс ягыннан тәэмин ителгән ир белән корылган гаилә гадәти булмаячак. Үзен дөнья кендеге дип санаган иргә чикләр кую, аны тәрбияләү, тәртә арасына кертергә тырышу, дәгъва белдерү мөмкин түгел, чөнки ул көчле. Ә көчлеләр һәрвакыт хаклы! Монысы инде үзенә күрә бер канун. Гадәти кешеләр өчен гаилә – һәрвакыт бер-берең юл кую. Ә бай ирнең хатыны белә: ул гына чигенергә тиеш. Киресенчә булган очракта күп нәрсәне югалтырга мөмкинсең, һәм бу хакта ире бик яхшы белә! Мондый гаиләдә яшәгән хатыннарга үзен ничек кую дөрес булыр? Төрле хатын-кызларның тарихлары аша әнә шул хакта сөйләшик әле.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

Рублевка фаҗигасе

Моннан берничә ел элек Мәскәүдә алтын тәлинкәләрдән генә ашап йөргән бомонд даирәсендә танылган, «светская львица» печате сугылган Яна Прежевская хәерчелектә, кыйналудан үлә. Чибәр була ул. Мәктәптә укыганда ук төрле бәйгеләрдә катнашып, үз матурлыгын раслаган кыз, Мәскәүдә югары уку йортында юрист һөнәрен үзләштерә башлый. Киләчәге бик якты күренә: адвокат, гаилә, балалар... Әмма бер бәйрәмдә бизнесмен Евгений Фролов белән танышкач, киләчәккә планнары кисәк кенә үзгәрә дә куя. Олигархлар яшәгән Рублевкага күчә. Языльшмый гына яши башлыйлар. Аларның өч уллары туа. Хатын байлыкта коенып яши. Иртән тора, няняларга балаларын мәктәпкә җыярга булыша, аннан кибетләр, дус кызлар белән шампан шәрабы эчүләр... Әбәттән соң шәхси косметологы, маникюр остасы, стилист килә. Кичкә ял иткән, көне буе үзен караган хатын ире белән берәр бәйрәмгә барырга әзер.

Күпчелек хатын-кызлар ак мерседеска утырган принцка өметләнә, хәтта кияүгә чыкканнары да...

Ә анда төне буе музыка, төрле коктейльләр, күлмәкләрең белән мактанышу. Шундый ук бер «светская львица» Янаның тормышын әнә шулай тасвирлый. Әмма бизнесмен ирнең нәфесе яшьрәк хатын тели башлый. Яна өйдән чыгып китәргә мәҗбүр була. Ялгызы! Язылышмый яшәгәч, ул ир күрсәткән рәхимлелеккә генә ризалашырга мәҗбүр була. Дуслары арендага фатир алып бирә. Әмма хатын сына. Эчә башлый. Әнисе сүзенә караганда, дус дигән кешеләре бөтен булган байлыгын – кыйммәтле туннарын, бриллиант алкаларын, машинасын талап бетерә. Көннәрдән бер көнне йөзе күгәреп беткән Янаны фатирында карават астыннан табып алалар. 11 ел бер кайгысыз, ялтыравыклы тормышта яшәгәне өчен ул гомере белән түли. Соңгы юлга озатырга ире дә, балалары да килми.

Яна Прежевская фаҗигасе беренче һәм соңгысы түгел. Ул күпләрне тетрәндерсә дә, яңа Золушкаларга ул кесәсе тулы акчасы булган принцлар турында хыялланырга комачауламый. «Минем белән андый хәл булмаячак. Мине яратып, иркәләп кенә торачаклар, чөнки ул – МИН», дип уйлый алар. Бай иргә кияүгә чыгарга гына кирәк, аннан баллы тормыш башлана дип саныйлар. Әмма мондый ирләр белән яшәгәннәр тормышларының рухи яктан авыр булуын әйтә. Әйе, алар гадәти гаиләдә тормыш арбасын үзләре тартып барган хатыннар кебек, балаларымның түгәрәкләренә кайдан акча алып түләрмен икән, дип борчылмый, суыклар башлангач, берданбер сапогиенның бу сезонда да чыдаячагын күреп сөенми, косметика кибетендә духилар иснәп йөргәч, хушбуем төбендә калды әле бераз дип, борылып чыгып китми. Әмма...

Алтын читлектән чыгу куркынычмы?

«Синнән көнләшәм», – дигән иде танышым бервакыт миңа. Дөрес ишетәммe, дип аңа карыйм. Өстендә дөньяви дәрәҗәдә танылган брендлы пуховик, кулында соңгы модельле «Порше»ның ачкычы. Беләм: әле генә гаиләләре белән Европа курортына барып, чаңгы шуып кайттылар. Моннан да рәхәтрәк тормыш юк кебек. «Син эшлисең, кешеләр арасында йөрисең, шуңа кызыгам», – ди, балалары тугач бер көн дә эшләмәгән танышым. «Синең акча эшләвең кирәкми. Өйдә, балалар янында бул! Алар караулы булсын», – ди аңа ире баштарак. Һәм ул ризалаша. Ире карьера баскычлары буйлап күтәрелә, ул балалары белән кайнаша. Финанс ягыннан тәэмин ителгән ирнең хатыны чибәр, каралган булсын. Танышым да, төрле процедураларга, шәһәр үзәгендәге аерым катлам кешеләре өчен генә эшләгән спорт залларына йөри.

– Әмма мин анда бер стакан каһвә да эчмим. Акча туздырырга ярамый. Мин өйдәге мебель кебегрәк инде. Элек гаиләләре белән урамга һава суларга йөрүчеләргә кызыга идем. Балалар кечкенә чакта да, коляска тартып, әтиләре белән урам буйлап йөргән булмады. Әмма мин иремне битәрли дә, моның өчен үпкәли дә алмыйм. Ул – өйдә хуҗа. Әйе, без Европа курортларына барабыз. Бу аның социаль статусы өчен кирәк. Иң рәхәт вакыт – ул командировкаларга киткәндә. Балалар белән ни телибез, шуны эшлибез...

– Аерыл соң. Иркенләп яшәрсең, – дим, бу сүземә җавапны белсәм дә.

– Балалар үсеп килә. Аларның күңелләрен яралыйммы? Аннан соң мин кемгә кирәк?! Шушы яшемдә гап-гади бухгалтер булып эшли башлыйммы? Ул хезмәт урынына да алмаячаклар әле, чөнки тәҗрибәм юк... Мин иремә буйсынып яши генә беләм...

Куып чыгармаса, түзәм инде дип яшәүче хатыннар аз түгелдер. Бигрәк тә ирләре тапкан акчага яшәүче хатыннар. Ә куып чыгарса... Яна Прежевская хәлендә калу өчен иренең миллиардер булуы кирәк түгел. Рублевканы да башка планета итеп карарга кирәкми. Алар да шундый ук кешеләр, шундый ук мөнәсәбәтләр – статуслары гына башка. Мондый хәлләр безнең мохиттә дә булырга мөмкин.

18 яшендә үк кияүгә чыга Эльвира. Гашыйк була. Заманы өчен егете дә төшеп калганнардан түгел, ә иң мөһиме: әти контроленнән котыла. Кияүгә чыгуга бик рәхәт яши ул. Ире иркәләп кенә тора, нәрсә тели, шуны алып бирә, бүләк итә. Бер-бер артлы балалар туа. Балалар туган саен, хисләр дә үзгәрә... Институтта укырга вакыты булмый Эльвираның. Бик ялынып сорагач, элемтәләре булган ире аңа диплом алып кайтып тоттыра. Эльвираның амбицияләре шуның белән басыла. Ул да балалары белән кайнаша. Өен килеп җыештырып китүләренә, ресторанда кичке аш ашауга, төрле илләргә сәяхәткә йөрүгә ияләшә. Дөрес, ире белән мөнәсәбәтләре кояш яктысы кебек булмый булуын. Төрле чаклар була, әмма Эльвира гел юл куя. Беренчедән, әтиәни тәрбиясе – ирне олылау канына сеңгән; икенчедән, ул бит ире авызына карап яши. Сораштыра башласа, ире аңа: «Артык сораулар бирмә», – генә ди. Әлбәттә, ул хатын-кыз, аның да җаны бар: көнләшә, интегә, үпкәли, нәрсәдер расларга тырыша... Ире андый очракларда тыныч кына ишеккә күрсәтә, янәсе көчләп тотмый. Эльвирага барысын да йотарга туры килә.

«Шайтан кабыргага төрткән» чорга җиткәч, ире бөтенләй шашына. Моңа кадәр дә уҗымга чыгарга яраткан ир, яшь хатын алып кайтырга карар кыла. 20 ел яшәгән хатынын әнисенә илтә дә куя. Елаулар, әрләшүләр, мыскыл итешүләр күп була бу вакытта. Рәсми төстә аерылышкач, Эльвирага һәм балаларга яшәгән йортлары кала калуын, әмма ул өйгә бит азык-төлек үзе килми. Яшәр өчен акча кирәк. Балаларга ярдәм итсә дә, Эльвирага ир бер тиен дә акча бирми. Гомеренең иң яхшы елларын хыянәтче ире белән үткәргән өчен хатыннарга компенсация түләргә кирәк дигән канун юк. «Пластик опера-

Ир-атны бөтен тормышыңны тәэмин итә алачак иркәк дип кабул итү – иллюзия ул.

цияләр ясатып, күкрәк үлчәмен үзгәртеп йөрисе калмаган, – дип үкенә хәзер Эльвира, – үз-үземне үстерәсе: укыйсы, һөнәр аласы, әкренләп кенә булса да тәҗрибә туплыйсы калган. 40 яшендә кулы бер эш белми торган кеше җәмгыятькә кирәк түгел икән инде. Өйрәнә башларга да соң кебек...» Каңгырап йөри торгач, улы ярдәме белән базардан бер сәүдә ноктасы сатып ала. Киштә артына басып, үзе сата башлый. Ә бит заманында музыка мәктәбен «бишле»гә генә тәмамлаган иде, укытучыларының аңа өмете зурдан иде...

Бай ир һәм бер кайгысыз тормыш хәзер күпчелек кызларның хыялы. Әмма статистикага караганда, кызларның 15 проценты гына калын кесәле ирләрне аулый. Мондый кызлар, гадәттә, кияүгә соң чыга, яшьлекләренең иң матур вакытларын «эзләнүдә» үткәрә. Бала белән ирне бәйләп булмаганын барыбыз да чамалыйбыз. Ә замана Золушкалары өчен бу иң җиңел ысул кебек. Әмма ике арада чыккан аңлашылмаучанлыкны бала гына җайлап бетерә алмый. Ир хатынын юкка чыгарырга тели икән (бигрәк тә ул финанс яктан тәэмин ителгән булса), аның мөмкинлекләре рухи яктан да, материаль яктан да күбрәк. Ә хатын аның акчасына бәйле булса, ир бу уен көч куймыйча да башкарып чыгачак.

Үз эшем, үз тормышым

– Мин бай кешедә кияүдә, – дип сөйли Казандагы риэлторлык компаниясе хуҗасы Альбина (исеме үзгәртелде – *ред.)* – Кияүгә чыкканда ук, хәзерге көндәге кебек зур булмаса да, үз бизнесым бар иде. Үз-үземне тәэмин итәрлек хәлдә идем. Уртак дусларыбызның бер бәйрәмендә таныштык. Ул миннән зуррак, аерылган иде. Аралаша башлаганда мине комда уйнаган бәләкәй кыз итеп кабул итә иде бугай. Җитди итеп үз эшемне алып баруымны танызйсы килмәде. Хатын-кызның үз дөньясы булырга тиешлеген, ә моның өчен аңа күпмедер күләмдә ирекле булырга кирәклеген кат-кат сөйли, дәлилли торгач, ул минем белән ризалашты. Элек: «Син минем матурым дисә, хәзер син минем акыллым», – ди. Бала тапкач та озаклап өйдә утырмадым, эшли башладым, чөнки бизнесым минсез бара алмый. Хәзер мин ике бала әнисе, янәшәмдә – яраткан һәм хөрмәт иткән ирем (ә яшәештә монысы күбрәк тә кирәк бугай?!). Бик күп кызлар финанс яктан тәэмин ителгән, йә булмаса, акча таба белгән иргә кияүгә чыкканнан соң, үз киләчәкләре өчен берни дә эшләмиләр (бала тәрбияләү белән ашарга пешерү моңа керми), ә соңыннан зарланалар. Ләкин тормышта көтелмәгән әллә нинди хәлләр була ала. Ярар, иреңнең күзенә башка хатын-кызлар күренмәсен, гел синең күзгә генә карап яшәсен дә ди, ә үлеп китсә?! Ирең җыйган байлыкны түкми-чәчми яши белергә кирәк. Ә ул байлык булмаса нишләргә?

Һәрбер кеше белергә тиеш – кара көнгә нинди активы бар? Ирнең капиталы бар, ә синеке, балаларныкы нәрсә? Гомумән, бу хакта ирең белән утырып сөйләшү зыян итмәс. Никах килешүе язу оят эш түгел хәзерге заманда. Хәтта бик кирәкле гамәл. Моны башкарганда куйган шартларың белән ир килешми икән, бу инде һөнәрле булырга тиешлегеңә бер ишарә. Мин кызларга әйтер идем: бай кешегә кияүгә чыгарга телисез икән, туйга кадәр үк никах килешүе турында сөйләшә башлагыз, бәлки, ул өйләнү уеннан кире дә кайтыр. Ә ныклы гаиләнең сере бик гади: хатын-кызның мөстәкыйль булуы, ирен яратуы һәм аңа ышанычлы булуы кирәк.

Могҗиза юк ул. Бай иргә кияүгә чыгасың икән, аның белән бер булып сөйләшер өчен үз өстеңдә эшли башла. Яна кебекләр хәленә калмас өчен, кимендә, белем алырга, аны куллана белергә кирәк. Гаилә нинди генә социаль хәлдә булса да, икең бергә үсү ул. Берең алга барып, икенчең туктап кала икән, бу инде фикер каршылыклары, аңлашылмаучанлыклар китереп чыгара. Ни дисәң дә, гаиләнең ныклыгы уй-фикерләрнең бер дәрәҗәдәрәк булуындадыр. Балалар белән мәш килеп, дөнья мәшәкатенә күмелеп, кухнядан чыга алмаган хатын көннәрдән бер көнне киләчәккә карап яшәгән, үз көче белән мал тапкан һәм шуны арттыра алган иргә кызыксыз буласың икән, ирне гаепләргә кирәк түгел монда. Хәер, тормыш булгач, төрлесе була, әлбәттә.

Лилия кияүгә яратып чыга. Ире дә мал таба белгән кеше. Визажист һөнәрен үзләштергән хатын, декрет ялында өйләренә йөреп клиентларын бизәндерә башлый. Моңа бер-бер артлы балалары тууы да комачауламый. Лилия кечкенә генә офис арендалап, мастерлар җыя, хезмәт күрсәтү төрләрен дә арттыра. Кечкенә балалары – кайсы бакчада, кайсы үзе белән йөри шулай. Клиентлары күбәйгәч, зур бина сатып алып, аны үз зәвыгы белән ремонтлап, эшен шунда дәвам итә. Дүртенче баласын табып, бизнесын тагын да киңәйткәч, ире аңа кызыксыз була башлый. Уртак кызыксынулар юкка чыга, чөнки Лилия финанс ягыннан гына түгел, рухи яктан да үсә. Аңа яңалык, яңа уйлар, яңа тәэсирләр кирәк. Әмма ире генә элекке дәрәҗәдә кала. Ничек булган, ничек мал тапкан, шулай яшәвен дәвам итә. Дүрт баласы белән Лилия иреннән аерыла. Бәлки, күпләр моны тәртәгә тибү дип тә кабул итәр. Әмма бу ситуацияне бераз гадиләштереп карыйк әле. Син балаларыңны төрле түгәрәкләрдән алып, бөтен түләүләрне түләп, әле, җитмәсә, бер сумка азык-төлек күтәреп кайтып кергәндә, ирең кырын ятып телевизор караса йә дөньясын онытып компьютерда уйнап утырса, ачуың килми калмас, әмма монысы инде бөтенләй икенче тарих. Башка язма өчен...

P. S. Язмамда геройларымның фотолары булмау сәер тоелыр. Алар берсе дә моңа риза булмады, хәтта кайберләре исемнәрен үзгәртергә кушты. Берләре бәхет тынычлыкны ярата дисә, икенчеләре баллы тормышларының әче якларын фаш итәргә базмады. Якыннары, нинди булса да, ирләре бар бит әле...



Гүзәл ШАКИРОВА, Казанның 18 нче үзәк клиник хастаханәсе каршында ачылган инфекцион госпиталь мөдире

Казанга мин Башкорт дәүләт медицина университетын тәмамлап килдем. 2016 елдан 18 нче хастаханәнең амбулатор-поликлиника хезмәтендә терапевт булып эшлим. Быелның июль аенда хастаханә каршында вакытлыча инфекцион госпиталь ачылды. Беренче көннән үк мин дә – COVID-19 вирусын йоктырган авыруларга медицина ярдәме күрсәтүче бригадада. Куплар, курыктыңмы, дип сорый. Дөресен әйтәм, курыкмадым. Дөньяга афәт янаганда табибның куркырга хакы юк дип саныйм. Тик әти-әниемне борчымас өчен, «кызыл зона»да эшләвемне баштарак алардан яшердем. Август аеннан исә мине әлеге инфекцион госпитальнең мөдире итеп билгеләделәр. Интенсив терапия палаталарында ятучы авыр хәлдәге пациентларны дәвалыйм. Эшем иртәнге обходтан башлана. Көндезге унда «кызыл зона»га күтәреләм. Эш сәгатьләребез дүрттә тәгәлләнергә тиеш булса да, соңга кадәр эшләү хәзер инде нормага керде. Бик авыр атналарда кичке уннарга кадәр дә «кызыл зона»да калырга туры килә иде. Чынлыкта, тәүлекнең 24 сәгатендә дә элемтәдә без. Кайчак хәтта төнлә дә виртуаль консилиум җыярга туры килгән чаклар була. Бу чир бик мәкерле, пациентның хәле сәгать эчендә авыраерга мөмкин. Карарны тиз һәм бик уйлап кабул итәргә кирәк, бигрәк тә бактериаль препаратлар белән дәвалауга кагылышлысын. Һәркем өчен борчыласың, үземнең дә әтием бик авыр кичерде бу чирне. Пациентларның савыгып өйләренә кайтып китүләре безнең өчен куаныч. Күптән түгел генә ике егетебезне өйләренә озаттык. Үпкәләренең 80–90 проценты зарарланып кергәннәр иде. Шулай да җиңел суларга иртәрәк, без, табиблар, сафтагы солдатлар кебек, гел әзер булырга тиеш. Барыбызга да сәламәтлек телим, авырмыйк!

COVID «СОКЛАНДЫРДЫЛАР-2020

Лилия ханым – медицинада 1993 елдан. 28 елдан артык эш дәверендә төрлесен күрә ул, ләкин быелгысы кебекне... Ул эшләгән хастаханә июль аенда Covid-19 вирусын йоктырган авыруларны дәвалаучы госпиталь итеп үзгәртелә. Беренче көннән – Лилия ханым «кызыл зона»да. Бер смена – алты сәгатьлек. Алты көнгә тиң алты сәгать... Өстә – махсус кием, кулда – икешәр кат перчатка, биттә – маска өстеннән киелгән респиратор. Кул белән йөзнең ачык калган бер генә өлешенә дә кагылырга ярамый. Маңгайдан тамып төшкән тир тамчылары бит очларын ничек кытыклый! Ләкин аларны кул аркасы белән генә дә сыпырып ала алмыйсың. Ничек тә түзәргә!

Баштагы көннәрдә бу режимга күнегүе бик авыр була, билгеле. «Кызыл зонада»гылар тулысынча изоляциядә – өйгә кайту, туганнар белән очрашу мөмкин түгел. Аннан чыккач, һәркем иң беренче итеп телефонга үрелә. Ничә сәгать буе киеп йөргән битлек эзләре тәнгә батып кергән, перчатка астында бармаклар шешенгән, ләкин якыннарыңның тавышын ишеткәч, авырлыклар онытылгандай була. «Үзеңне сакла!» – дип инәлә ире. «Тырышам, – дип елмая Лилия. – Сез дә үзегезне саклагыз!»

Лилия ГАТАУЛЛИНА, Чаллының 5 нче шәһәр хастаханәсенең шәфкать туташы


– Баштарак, кешеләр бу чиргә ышанмады, – ди Лилия Тәлгатовна. – Ә безнең бүлеккә көненә унар-унбишәр авыр хәлдәге авыруларны китерәләр иде. Сулый алмыйлар, тыннары буыла. Үз тыныңны сулатырдай булып, кулдан килгән ярдәмне күрсәтергә ашыгасың. Андый чакта берәү дә үзен уйламый, бар көчне кешенең гомерен саклауга саласың. Смена тәмамланганда һәрберсе белән күңелемнән генә саубуллашып, унике сәгатьтән соң исән-имин очрашырга насыйп булсын иде дип теләп чыгам. Иң авыры – икенче юлы кергәндә инде кемнеңдер булмавы... Хәзер күпкә җиңелрәк. Тиздән бу авырлыклар узасына ышанам.





ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Бүгенге язмабыз белән «ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан» проектын төгәллибез. «Азат хатын» тышлыгында чыккан геройларыбыз арасында кемнәр генә юк! Табиблар, төзүчеләр, укытучылар, терлекчеләр, спортчылар, депутатлар… Аларның хезмәт юлы аша республикабыз ирешкән уңышларны күрсәтергә теләдек. Шунысы кызык: күпләр инде башка фамилия алган, районнар алышынган, оешмалар бүтән… Дистә еллар дәвамында никадәр яңалык! Ә ул хатын-кызларның язмышы бүген дә сокланырлык!

ДЕПУТАТ ХАНЫМ



































Фото: Анна Арахамия

Филсинә ФӘХРИЕВА:
«Икенче срокка сайланудан үзем баш тарттым. Хатын-кызның төп роле әни булу, ир хатыны булу дип саныйм. Быел ноябрь аенда никахыбызга 40 ел тулды. Үткән гомернең бер генә көне дә үкенерлек итеп яшәлмәгән, шуңа куанам».

Узган гасырның 70–90 нчы елларында Казандагы бишенче трамвай маршрутын күпләр хәтерлидер әле. Компрессорлар заводы янынннан җай гына кузгалып китә дә, шәһәрнең берничә районы аша узып, үзәккә алып килеп җиткезә. Куйбышев (хәзерге Тукай) мәйданында борылыш ясап алып, килгән юлы буйлап, кирегә теркелди.

Арча районының Комыргуҗа авылында (хәзер Әтнә районында) үскән кызның кечкенәдән бар хыялы – трамвай йөртүче булу. Роза апасына кызыга да соң! Аның караңгы зәңгәр төстәге вагон йөртүчеләр формасын ничә киеп карады: шундый матур, шундый килешә! Ләкин... унынчыны тәмамлап Казанга килгәч, «трамвай йөртергә яшең тулмаган», диләр. Ике ел төзелештә эшләп торырга туры килә (плиточница-мозаичница таныклыгы саклана әле). Ниһаять, хыялына ирешә кыз – Казанның 2 нче трамвай депосында вагон йөртүче ул! Әнә бишенче маршрут трамвае тукталыштан кузгалуга йөртүченең йомшак тавышы салонга яңгырый: «Кадерле пассажирлар! Тирә-ягыгызга игътибар белән карагыз әле, яныгызда өлкән яшьтәгеләр, авырлы хатын-кызлар басып бармыймы?» Аның сменасында әллә пассажирлар шундый тәртипле, әллә вагон йөртүченең ягымлылыгы шулай тәэсир итә – ызгыш-талашлар бик очрамый. Алай да кайчак булгалый. Андый чакта микрофоннан кабат мөлаем тавыш яңгырый: «Кадерле пассажирлар! Уң як тәрәзәгә күз салыгыз. Бульдозерлар эшләп йөргән урне күрәсезме? Монда революционер Мулланур Вахитовка һәйкәл куелачак!» Салондагылар тынычлана. Бу вакытта пассажирлар үзләре утырып барган вагонны илнең Югары Советы депутаты йөрткәнен белсәме?!

1984 елның 4 мартында СССР Верховный Советының 11 нче чакырылышына сайлаулар уза. Татарстаннан сайланган 26 депутат арасында Филсинә Фәхриева исеме дә бар. Әйе, әйе, бишенче маршрут трамваен йөрткән Филсинә ханым үзе! Башта бу яңалыкны бары ире Даниял гына белә. Кызының исем-фамилиясен газетада күргән әтисе Газиз абый исә ышанмый, азмыни илдә адашлар?! 24 яшьлек ханым үзе дә нинди җаваплы вазыйфага алынганын ул вакытта тулысынча аңлап җиткерде микән? Апрельдә яңа чакырылыш депутатлары беренче сессиягә җыела. Филсинә Газизовнаны Торак-коммуналь хуҗалык комиссиясе секретаре итеп билгелиләр. Исәпсез-сансыз шикаятьләрне карап тикшерәсе, авыр тормыш шартларында калучыларны кабул итеп, гозерләрен тыңлыйсы, проблемаларын хәл итү өчен урыннарга юллыйсы, хатлар язасы... Утырышлар арасында кунакханәгә – улы янына йөгерәсе... Ривальләре кырык кына көнлек бит. Ярый әле ире аңлый торган кеше: улларын карап торыр өчен, эшен калдырып Мәскәүгә кадәр бара. Аңа чын-чынлап таяна ала Филсинә ханым.

Депутат – дәүләт кешесе. Кая барса да бу хакта исенә төшереп кенә торалар. Кайда күперне ташу агызган, кайда юл юк... Ләкин барысын да ул гына хәл итеп бетерә алса икән!

Филсинә Фәхриева турында ул елларда матбугатта күп языла. «Советская женщина», «Работница», «Азат хатын» журналларының герое ул. 1986 елгы журналыбызның февраль саны тышлыгы аның фотосы белән чыга. Ул фото – шул кадерле көннәрнең бер истәлеге.

Лилия ГӘРӘЕВА

Видеокотлау »




«ИҢ ЯКЫН КЕШЕМ...»

Гөлнур САФИУЛЛИНА

Алтын туй! Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит МӨХӘММӘТШИН һәм аның җәмәгате Луиза Әкрәмовна гаиләсендә әнә шундый матур бәйрәм быел! Инде бергә бик озын юл үтелгән. Шатлыгы да булган, сөенече дә, борчу-мәшәкате дә. Сынаулары да... Гомернең бу чорында бәхет инде башка төшенчәләр белән бәяләнә. Ул инде гап-гади шушы сүзләргә дә сыя: «Иң якын кешем...» Алар белән бергәләп тагын бер кат тормыш сәхифәләрен барлыйбыз.







Фотолар: гаилә архивыннан

Танышу

Фәрит Хәйруллович: 50 ел! Бер уйласаң, бик күп гомер! Әйе, бу вакыт эчендә әллә никадәр вакыйга булган, күбесе хәтердән дә чыккан. Әмма Луизаны беренче күргән мизгел, безнең ничек танышуыбыз онытылмый! 1968 елның ноябре иде ул. Яңа гына армиядән кайтып төштем, һәм дуслар мине «Восток» ресторанына шуны билгеләп үтәргә чакырдылар. Нәкъ шул көнне Әлмәт яшьләре ресторанда шәһәр комсомол оешмасының Хезмәт Кызыл байрагы ордены белән бүләкләнүен бәйрәм итәләр иде. Безне орден таныштырды дисәк тә була... Күрше өстәлдәге чибәр кызга шунда ук күзем төште. Үз-үзен тотышы җәлеп итте бугай. Әмма бу актив комсомолкага барып сүз дәшәргә, биергә чакырырга нигәдер җөрьәт итмәдем. Үземне кыюсыз дип тә әйтә алмыйм югыйсә... Һәм берничә айдан бер дустымның туенда очраттым мин аны. Кунаклар арасында ул да бар иде! Дус кызы белән иде Луиза. Мин инде бу юлы мөмкинлекне кулдан ычкындырмадым – без якыннан таныштык. Сөйләшер өчен әллә никадәр уртак тема табылды, тормышка карашлар бер икәне дә ачыкланды... Туй соң тәмамланды, автобуслар, билгеле, йөрми иде инде. Мин Луизаны бөтен Әлмәт буйлап озата кайттым. Алар иске шәһәрдә тора икән – җәяү шактый атладык, әмма юлның озынлыгын тоймадым...

Луиза Әкрәмовна: Ул көнне ресторанда Фәриткә мин дә игътибар иттем. Яңа гына хәрби хезмәттән кайтуын да аңладым. Минем якка гел күз төшерүен дә сизеп утырдым. Биергә чакырыр дип тә көттем. Чакырмады... Ә теге туйдан соң инде очраша башладык. Ике ел йөрдек без. Бер-беребезне яхшырак белер өчен аз вакыт түгел бу. Ул арада әллә ничә тапкыр сүзгә килергә, хәтта, аерылышып, икең ике якка китәргә мөмкин иде. Әмма боларның берсе дә булмады. Фәрит соңрак: «Шул ике ел гомеребезне җәллим – танышуга өйләнешәсе калган», – дип тә әйтте.

Фәрит Хәйруллович: Луизаны еш кына өйләренә кадәр озата кайтсам да, бусагаларын атлап кергәнем булмады. Ул чакта андый гадәт юк иде бит әле. Әти-әнисе мине бер елдан соң гына күрде. Менә нәрсә ачыкланды: Луизаның әтисе Әкрәм Хаҗиевич белән әнисе Оркыя Саримовна минем әти белән бер мәктәптә укыганнар икән! Сугыштан соң партия райкомында да бергә эшләгәннәр – бер-берсен яхшы беләләр. Безнең өйләнешүгә ике яктан да каршы килүче булмады. Әтиләр белән автобуска утырып кыз сорарга киттек. Анда инде безне табын әзерләп көтәләр иде... Туй көнен билгеләдек, туйга нинди бүләкләр салачагыбызны сөйләштек: кемгә – күлмәклек, кемгә – шәльяулык... 1970 елның салкын декабрь аенда язылыштык без. Комсомол-яшьләр туе үткәрдек, әллә ни зурдан купмасак та, кешенекеннән ким дә булмады – ул чактагы гадәт буенча ике көн бәйрәм иттек.

Луиза Әкрәмовна: Әйе, әтиләр чордашлар булып чыкты! Бергә эшләгәннәр, яшь чакта бер футбол командасында уйнаганнар. Без өйләнешкәч: «Бер-берегезне белгәнгә таныштыргансыздыр инде балаларыгызны», – дип әйтүчеләр дә булды аларга. Мин кечкенә чакта Фәритнең әти-әнисенең безгә килгәннәре дә булды. Кызлары барын да белә идем. Ә Фәритне бер тапкыр да күрмәдем.

Туй дигәч, искә төште әле. Фата эзлим, тик Әлмәтнең бер кибетендә дә юк. Ә ансыз кәләш буламыни инде?! Шул көннәрдә эштәге бер дус хатыным Мәскәүгә командировкага китте. Бөтен өметем аңарда иде. Алып кайтты бит! Бүгенгеләрнеке кебек егермешәр метрлы түгел, әлбәттә. Әмма аның матурлыгы! «Миңа иң-иңен бирегез, безнең кәләш актриса Одри Хепбернга охшаган дип сорадым сатучыдан», – дип көлдергән иде... Туебызда әни «Киек казлар» җырын җырлады. Бүгенгедәй күз алдымда: өстендә ак күлмәк, үзе ишек яңагына сөялгән... Күзеннән бер яшь бөртеге таммаса да, аның җаны елый иде бугай. Кыз баланы оядан очыру бер анага да җиңел түгел...

Гаилә

Луиза Әкрәмовна: Фәритнең әти-әнисе белән бергә яши башладык. Әмма һәр яшь гаилә кебек, башка чыгасыбыз килә иде. Озакламый андый мөмкинлек туды: безгә «малосемейка»дан бүлмә бирделәр. Бөтен уңайлыклары – бәдрәф тә, салкын су. Кредитка аклы-каралы «Березка» телевизоры алып куйдык. Тагын электр плитәбез бар иде – анысын Фәрит үз куллары белән ясады. Ашарга да шунда пешердек, балалар тугач, аларны коендырыр өчен суны да шунда җылыттык.

Фәрит Хәйруллович: Беренче балабыз – Дамир туган көннәр дә кичә генә кебек... Яланаякка резин итек киеп, Луизаның апасына сөенеч алырга чапкан идем. Башкача ничек хәбәр итәсең – телефоннар юк...

Мирзиян бабам килеп, намазлар укып: «Улым, син Дамир булырсың!» – дип, балага үзе исем кушты. Вәсилә әби белән котлап, сабыебызга күлмәк бүләк иттеләр. Хәзер дә истә: шотландка күлмәк. «Базарга кереп алдык», – диделәр...

Без өйләнешкәндә Луиза Миңнебай газ эшкәртү заводында, икътисад бүлегендә эшли иде. Җиңел атлетика белән шөгыльләнергә – кыска дистанцияләрдә йөгерергә дә өлгерә. Завод кына түгел, шәһәр, район ярышларында катнаша, алдынгы урыннар яулый. Ә мин армиядән соң ук «Әлмәтнефть» идарәсенә урнаштым, контроль-үлчәү приборлары слесаре булып эшли башладым. Кичен газ сәнәгате техникумында укыйм. Иҗтимагый эшләрдә катнашам, комсомол тормышында кайныйм... Улыбыз тугач, безнең алга сорау килеп басты: институтта укуны кайсыбыз дәвам итә – улмы, минме? Читтән торып кына укысак та, ике студентның барысына да өлгерә алмаячагы көн кебек ачык иде: эш тә, сессияләр дә, өй дә, яшь бала да... Техникумны тәмамлаганнан соң югары белем алу турында да хыялланган Луиза шул вакыт: «Син укы, сиңа кирәгрәк», – диде... Миңа үсәргә мөмкинлек биргән өчен аңа бүгенгәчә рәхмәтлемен. Һәм әлегә кадәр үземне аның каршында гаепле саныйм...

Комсомол эшенә күчкәч һәм Уфа нефть институтына укырга кергәч, гаиләгә вакытым бөтенләй аз калды. Өй, бөтен көнкүреш мәшәкатьләре, балалар тәрбиясе – һәркайсы Луиза өстендә булды.

Луиза Әкрәмовна: Фәрит хөкүмәт эшенә чумды – өйгә йокларга гына кайта. «Балаларга дөрес тәрбия бирәмме икән? Алла сакласын, ул-бу хәл чыгып: «Син кара-

магансың, син дөрес тәрбия бирә белмәгәнсең», дип әйтер көнгә калмабызмы?» – дигән чакларым булды...

Балалар

Луиза Әкрәмовна: Әти-әниләр гаиләсендәге иң төп кагыйдәләрне без үзебезгә дә күчердек. Әйтик, балалар кечкенә чакта алар һәр көнне сәгать тугызда йокларга ятарга тиеш иде. Бу тәртипне «тагын бераз уйныйсы килү» дә, өйдә кунаклар булу да беркайчан үзгәртмәде. Тугызда икән – тугызда... Һәр эшне планлаштыру, вакытның кадерен белү – шушыннан башлана. «Кемнеке дигәндә, анықы диячәкләр, йөзебезгә кызыллык китермәгез!» – дип үстердек. Шөкер, тәүфыйклы, тәртипле булдылар.

Фәрит Хәйруллович: Дамирның нинди дә булса берәр музыка коралында уйнавын бик теләгән идем. Музыка мәктәбенә укырга бирдек, прокатка баян алдык. Әнисе зур футлярдагы шушы баянны күтәреп, аны музыка мәктәбенә озатты, каршы алды. Мин дә үз өлешемне керттем: эштән кайткач, икәү ноталар кабатларга утыра идек. Музыка мәктәбенең өченче классына җиткәч, ул безнең янга саннар язылган бер кәгазь тотып килде дә: «Әти-әни, карагыз әле, мин музыка белән шөгыльләнмәсәм, безнең менә никадәр акчабыз янга калачак», – диде. Әмма Луиза каты торды: «Башлаганбыз икән, тәмамларга кирәк!» – диде. Һәм, ниһаять, ул көн килде – Дамир безне Әлмәт музыка мәктәбенең чыгарылыш укучылары куйган концертка чакырды. Барысы да бик әйбәт чыгыш ясады. Дамир да. Өчәүләп өйгә кайтып кердек. «Менә, әни, сиңа музыка мәктәбен тәмамлау турында документ. Булды!» – диде Дамир. Шуннан баянны ялгыш та башка кулына алмады. Тик шунысы кызык: Дамир инде күптән безнең акчаны да, үзенең вакытын да суга салдым дип санамый. Ул гитарада бик әйбәт уйный, җырлый – музыкаль белем алуы, әлбәттә, эзсез узмады. Ярый теге чакта кире чигенмәдек дип уйлыйм.

Безнең Дамирга намуслылык кебек сыйфат бик нык салынган. Әнисе белән мин дә тырыштык, бабасының – минем әтинең дә өлеше бар. Бервакыт аның шәһәр комсомол комитетына: «Мине үз теләгем буенча Әфганстанга җибәрегез», – дип гариза язуын белеп әнисе белән шаккаттык. Тугызынчы класста гына укып йөргән чагы әле. Кич белән өйдә бу хакта, әлбәттә, сүз чыкты. Дамир безне «юата»: «Соң мин бит әле иртәгә үк китеп бармыйм. Әмма сугыш туктарга охшамый бит, бөтен ил анда катнаша икән, нигә мин читтә калырга тиеш? Исемлеккә кертә торсыннар», – ди. Бәхеткә, улыбыз армия яшенә җиткәнче, әфган сугышы тәгәлләнде.

Чыгарылыш кичәсендә Дамирга: «Әлмәтнең 2 нче мәктәбенең иң гадел укучысы» дигән исем бирделәр. Хәтта шулай дип язылган майка бүләк иттеләр. Классташларының әниләре күп вакыт хатыныма шалтыратып: «Ә сезнең Дамир өйгә кайттымы әле?» – дип сорыйлар иде. «Юк, әле урамда», – дигән җавапны ишеткәч, тынычланалар. «Алайса ярый, безнеке класс белән паркка барабыз дигән иде, Дамир анда булгач, тәртиптер», – диләр иде.

«Сез мине артык дөрес итеп тәрбияләгәнсез. Бүген болай яшәргә авыр – тирә-юньдә нинди тормыш икәнен беләсез бит», – дип әйткәли ул кайчак. Әмма... үзгәрергә дә ашыкмый. Менәмчә, теләми дә.

Шундый ук сыйфатларны кызыбызда да күрәм. Гаделсезлек белән килешә алмау, кемдер моңа мохтаҗ икән, аңа шунда ук ярдәм кулы сузарга ашыгу... Бу яктан Лилиягә җиңелрәк: ул – табибә, үзенең бу теләкләрен көн саен, сәгать саен канәгатьләндерә ала.

Луиза Әкрәмовна: 1989 елны Фәритне Татарстанның сәүдә министры итеп куйдылар. Ул Казанга күченде, үзе белән Дамирны – ул инде студент иде – һәм Лилияне дә алды. Бөтенләй күченергә туры килсә, кызыбызга кат-кат мәктәп алыштырып йөрергә туры килмәсен дип үзебез шулай хәл иттек. Ә мин Әлмәттә калдым. Әти-әнинең сәламәтлеге инде әллә кем түгел, иске «финский» йорт булса да, аны да ташлап китеп булмый, эшем дә бар. Гаиләбезнең бөтен ир-атларын кайгырту тугызынчы класста укучы кызыбыз өстенә төште. Алар бер ел буе кунакханә номерында яшәделәр. Кухняда – электр плитәсе, Лилия шунда өчесенә ашарга пешерә. Көн саен кул белән әтисенең һәм абыйсының күлмәкләрен юа. Аңа бик авыр булыр дип уйлаган идем, ничектер бик тиз ияләште, зарланмады. Лилиябез кияүгә чыккач, Фәрит аның гел янәшәдә булмавына бик озак күнә алмады. Аннан шунысы да бар – Лилия өйдә нәрсәнең кайда ятканын һәрвакыт хәтерли, белә иде, «Кызым, шул әйбер кайда икән?» – дип сорарга гына кирәк...

Аерым торган бу еллар гаиләбез өчен зур сынау булды. Әмма ул безне тагын да бер-беребезгә якынайтты. Ә Лилия белән без, гомумән, дусларга әйләндек. Әгәр Әлмәттә генә яшәп калган булсак, кызым белән араларыбыз бу кадәр якын булыр идеме икән дип уйлыйм кайчак. Ярты сүздән аңлашабыз... Мәктәпне ул медаль белән тәмамлады һәм шунда ук Казан дәүләт медицина институтына укырга керде.

Начальнигым кайвакыт эш белән Казанга бара иде. «Мине дә алып бармассызмы икән?» – дип сорыйм. Аңлый, хәлемә керә, ризалаша иде. Иртәнге дүрттә юлга кузгалабыз – паром кичүе аша чыгып йөргән чаклар бит әле, төнлә генә кире кайтып керәбез. Үземнекеләр янында аз гына булырга өлгерәм... Йөрәгем өзгәләнә иде инде, «алар анда минсез нишлиләр?» дип уйлый идем...

Фәрит Хәйруллович: Ике елдан мине Татарстан министрлар Советы рәисенең урынбасары итеп билгеләделәр. Гаиләбезгә Казанда төпләнергә туры киләчәге көн кебек ачык иде – Луиза башкача Әлмәттә кала алмады. Мин аңа шул вакытта: «Өйдә, меңгә бүленмә инде, өйне генә кара», – дип әйттем. Хатын-кыз өчен өй җылысын саклаудан да зур эш була алмый...

Луиза Әкрәмовна: Эт елында туганмын, әллә шуңамы икән – мин гел сакта. Менә әтиләре өйдә, балалар белән бар да әйбәт икәнен беләм – бу минем өчен иң рәхәт сәгатьләр. Фәрит газета-журналлар караштырып утыра, әкрен генә телевизор сөйләп тора, өйдә утлар кабынган... Инде китап укысам да була. Бәхет шушы кебек тоела... Балалар үскәндә мине бу яктан борчымаска тырышты: кая киткәннәрен, кайчан кайтачакларын гел язып калдыралар иде. Кесә телефоннары юк иде бит әле. Хәзер,

әлбәттә, һәркайсының үз тормышы, әмма ул безнекеннән барыбер аерылмаган.

Мөнәсәбәтләр

Луиза Әкрәмовна: Фәрит чираттагы комадировкасына җыенган саен: «Менә ул китә дә, аннары бу эшемне эшлим, тегесен», – дип, күңелемнән моңарчы кул җитмәгән эшләрне барлап йөрим. Аның артыннан ишек ябылуга, кинәт күңелгә бушлык тула, нindидер бер моңсулык биләп ала. Кулдан эш төшә... Сәгатькә карап, минутларны саный башлыйм: менә ул аэропортка барып җиткәндер, һавага күтәрелгәндер, самолет инде җиргә төшәдер... Һәм, ниһаять, ул шалтырата: «Мин килеп җиттем, барысы да әйбәт...» Шул мизгелдә генә икенче сулышым ачылгандай була – инде тынычлап нидер эшләсәм дә ярый...

Безнең хакта беркайчан онытмый ул. Вакыты бик тыгыз икәнен белеп торам, әмма шалтыратып алырга җай тапмый калмый: «Нәрсә эшлисең? Хәлләрең ничек? Җыен да урамга чык әле – көн шундый матур», – ди...

Фәрит Хәйруллович: Кайчак миннән журналистлар: «Ә сез хатыныгыз белән киңәшләшәсезме?» – дип сорыйлар. Нindидер мөһим карар кабул итәргә туры килгән чакларда ничек инде киңәшләшмим ди? Ул бит минем эшем өчен үземнән дә ныграк борчыла! Халыкта «энә белән җеп» дип әйтү бар – бу Луиза белән безгә дә кагыла.

Минем өчен иң кыен әйбер – Луизаны нәрсәгәдер борчылган килеш күрү. Ул – гаиләбезнең рухи терәге. Бик авыр көннәр була, эштән арып, кәефсез килеш кайтып керәм – күзгә берни күренми. Һәм шундый вакытта Луиза бер җылы сүз әйтеп куя, һәм барысы да үзгәрә...

Луиза Әкрәмовна: Күпне кичерергә туры килде, әмма иң авыр чакларда гел бер-беребезгә таяндык. Әти-әниләрдән үрнәк алдык! Фәритнекеләрне искә төшерәм... Зур, тату гаилә иде алар. Кайнатам белән кайнанам кайчак икәү диванга янәшә утырырлар иде, әти шул вакыт әнигә: «И-и, Маһинурым, күз нурым!» – дияр иде...

Минекеләр үз йортлары белән яшәделәр. Зур хуҗалык: бакча, мунча... Газ, су кермәгән! Әмма без һәр шимбә кичкә таба аларга бара идек. Апам үз гаиләсе белән килә – балаларыбыз бергә гөрләшә. Кибет киштәләре буш чак булса да, әни ничектер җаен таба – мичтә безнең өчен зур бәлеш пешә... Ә әнинең пәрәмәчләре табадан төшәргә дә өлгерми кала...

Безнең оныклар да шундый ук тату гаилә корачагына бик ышанам. Традицияләр юктан бар булмый һәм юкка да чыкмый: без дә менә хәзер шимбә саен балаларны көтәбез. Иртән иртүк пешеренә башлыйсың, тәрәзәдән күзне алмыйсың... Бер-бер артлы килеп тулалар – өй аларның шат тавышларына күмелә. Рәхәт! Фәрит оныклары өчен менә дигән бабай булып чыкты! Ул аларның һәркайсын үзенчә ярата, һәрберсе белән үзенчә аралаша.

Кем өчендер ул Фәрит Хәйруллович, билгеле сәясәтче, җитәкче, фәннәр докторы... Ә минем өчен – гомер иткән ирем, балаларымның атасы, ышанычлы дустым. Бөтен җир йөзендәге иң кадерле кешем! Кайчакларда: мин бит үз тормышым белән түгел, күбрәк аныкы белән яшим дип уйлап куям. Булсын! Моның өчен беркайчан үкенмәдем!

Лилия АБАШЕВА, 2 нче республика клиник хастаханәсенең физио терапия бүлеге мөдире:

– Әти белән әни турында бер-берсеннән аерып алып сөйләп булмый. Әти нindидер биеклеккә күтәрелгән, республика, хәтта халыкара күләмдә хөрмәтле шәхескә әйләнгән икән – бу аларның уртак уңышы. Алар бер-берсенә таяныч кына түгел, берсе икенчесен канатландыручы да.

Әтинең гел эштә булуына кечкенәдән ияләштек: без торганчы ул китә иде, ул кайтканчы без йокларга ята идек. Әмма әтисез үсәбез дигән хисне тоймадык! Монысы – әнинең тырышлыгы. Нәрсә генә хәл ителсә дә, өйдә иң соңгы сүзне әти әйтәсен белә идек. «Әти әйткәнчә булыр» – бу гаиләбезнең язылмаган кагыйдәсе иде. Әтидән курка идек дия алмыйм, әмма ул әйткәнне берсүзсез үтәдек.

Абый белән без дә әти белән әнигә охшарга, аларны кабатларга тырышабыз. Икесе дә җай чыккан саен әби белән бабайның хәлен белешә иде. Мин дә һәр иртәне эшкә килүгә иң элек әти белән әнигә шалтыратып алам. Көн дәвамында әни белән тагын берничә тапкыр хәбәрләшәбез. Алар кебек үк, җай булуга гаилә белән табигатькә чыгып китәбез. Атна саен төп йортта очрашуларны да гадәт иттек: мунча керәбез, аралашабыз, сыйланабыз... Кайчак әнигә: «Бик арасың, бу атнада килмик әле, ял ит», – дим. Үзем алдан ук белеп торам: килмибез икән, алар, һичшиксез, үзләре безгә сугылачак.

Дамир МӨХӘММӘТШИН, «Татнефть» ААҖнең генераль директоры урынбасары – Казандагы департаменты директоры:

– Берсендә утырдым да, әтинең үзем янында күпме вакыт үткәргәнен санадым. Миңа ул чакта 16 яшьләр тирәседер. Нибары өч ел дип исәпләп чыгардым. Ул гел эштә булды... Аның буш чаклары безнең өчен шуңа да бәйрәмгә әверелә иде. Әти, гомумән, өйдә утыра белми. «Нишләп торабыз соң, әйдәгез, йә табигатькә чыгыйк, йә дусларның берәрсен чакырыйк», – диярго тотына. Дуслар дигәннән, аларның кайберсе белән әти инде кырык елдан артык дус, инде аларның балалары белән дуслыкны без дәвам итәбез.

Атна ахырында әби-бабайларда очрашу гадәтен әти белән әни Казанга да алып килде. Гаиләнең зурлыгын, бөтенлеген, бер-береңнең кадерен тоярга ярдәм итә бу очрашулар, безне барыбызны берләштерә.




Фото: Марина Корнилова. Шәхси архивтан

ҖЫРЧЫ ЛАБОРАНТ

Гөлнур ХӘСӘНШИНА

– Яшермим, беренче мәлләрдә гел еладым... Өйгә кайтам да: «Башка анда бара алмыйм... Минем эш түгел бу...» – дим... Күз алдына гына китерегез: мин бит моңарчы биек үкчәле туфлиләр, затлы матур күлмәкләр генә киеп йөргән кеше. Ә монда – җәен-кышын өстә калын халат, аякта калын табанлы ботинкалар, чәчләр һәрвакыт җыелган... Химик реактивлар, кислота, селте белән эшлибез – куркынычсызлык чаралары иң беренче урында тора... Тагын – безнеке кебек лабораториягә хас үзенчәлекле ис... Анысына һич ияләшеп булмас төсле иде...

«Татнефть»тә хезмәткәрләр өчен барлык шартлар тудырылган: эшләргә дә, ял итәргә – сәламәтлекләрен ныгытырга да.

Әйе, тормышның борылышлары гаҗәп аның.

Кайчан да булса менә шулай бөтенләй башка – капма-каршы өлкәгә кереп китәрмен дип Рәсимә ханым да уйламаган, әлбәттә. Алабуга мәдәният-агарту училищесын тәмамлап, 1986 елда туган ягына – Нурлат районы Күлбай-Мораса авылына эшкә кайта ул. Татар театрына нигез салучы Габдулла Кариевны биргән төбәк бу – мәдәниятне үз итү, театрны ярату авыл халкының канында. «Елга өч яңа спектакль куябыз!» – дип тагын кайсы авыл мактана ала?! Шәһәр мәдәният сарайлары да моны булдыра алмый. Ә алар куя! 18 яшьлек Рәсимә беренче эш көненнән үк шушы дулкынга чума... Нәкъ шул елны үзешчән коллективлар арасында Бөтенроссия конкурсы игълан ителә. Алар Сәет Шәкүровның «Сине ташлап китә алмыйм» спектаклен сайлыйлар. Эшне... гаиләләрне көйләүдән башлый ул: хатынына роль бирсә, иренә барып ялына, ире уйнаса – хатынына. Аннан, урам-урам йөреп, спектакль өчен декорацияләр җыя. Зур сәхнәгә чыкканчы чарланасы да бар бит әле: бөтен тирә-күрше авылларны әйләнеп чыгалар. Ягылмаган клублары салкын булса да, алкышлары җылыта... Спектакль өчен коллективка лауреат исеме бирәләр. Яшь-яшь белгеч өчен зур уңыш бу!

Җыр-моңга гашыйк кызны сәхнә тарта, әлбәттә. Зур заллар, меңләгән тамашачы... Әмма аякка язмыш урала. «Китәм» дигән гаризасына кул куймыйлар – бары район мәдәният сараена эшкә күчерәләр. Район данын яклап ул катнашкан бәйге-конкурслар, фестивальләрнең саны юк! Алган исем-бүләкләрнең дә. Арада – аеруча кадерлеләре бар. «Болгар» радиосын тыңласаң – үзеңне ишетерсең» республика җыр радиобәйгесе – шуларның берсе. Жюри рәисе – Хәния Фәрхи үзе! «Туган көнем иде, – дип сөйли ул. – Бөтен гаилә белән табын янында утырабыз. Радио да сөйләп тора. Һәм шунда: «Рәсимә Туктарова. Нурлат районы. Бәйгебезнең лауреаты!» – дигән сүзләрне ишетәм! Иң зур бүләк шушы яңалык булган иде!» Җирле композитор Тәлгать Бадигыйның Гәрәй Рәхим сүзләренә язган «Мәхәббәтем турында җыр»ны башкара ул әлеге бәйгедә. Нинди генә конкурста катнашса да, тыңлаучыны иң элек бер нәрсә җәлеп итә – моңарчы беркем башкармаган яңа җыр сайлавы.

Инде «Чияләр» турында. Нурлат халкы өчен бу җыр һәм якташлары Рәсимә – гел янәшә. Ул – аның иң беренче башкаручысы!

– Элек ел саен отчет концертлары була иде. Зур коллективыбыз белән Казанга барып, андагы тамашачы алдында хисап тотабыз. Мин ул елны үзебезнең җирле композитор Рамил Мифтаховның Фәүзия апа Мөхәмматова сүзләренә язылган «Чияләр» дигән җырын башкардым. Кайтып, бер-ике көн үтмәде: «Сине телефонга Габделфәт Сафин чакыра», – диләр. «Шаяртмагыз инде», – дим вахтер апага. Телефонны алсам, чынлап та – ул! «Рәсимә ханым, җырыгызны ишеткәч, төне буена йоклый алмадым... Бик матур җыр! Башкалар сораганчы дип шалтыратам – бирегез әле миңа «Чияләр»не!» – ди. Габделфәтне җырның авторы Рамил Мифтахов белән таныштырдым...

«Миңа йөрәк бүген кирәк» (Рамил Мифтахов көе, Роберт Миңнуллин сүзләре), «Кара миләш» (Рамил Мифтахов көе, Фәнис Яруллин сүзләре) җырларының беренче башкаручысы да – Рәсимә Туктарова!

Рәсимә белән җыр янәшә торса да, гаилә белән сәхнә генә гел янәшә була алмый шул... Ун ел элек сукмаклар аны «Нурлатнефть» газ һәм нефть чыгару идарәсенә алып килә – химик анализ лаборанты булып эшли башлый. «Бер ай дигәндә яңа һөнәремә тәмам күндем, – ди ул. – Эшемне яратам! Кызык ул! Лаборантка иң кирәк сыйфат – төгәллек. Бу минем өчен авыр дия алмыйм. Безне кечкенәдән һәр эшне җиренә җиткереп эшләргә өйрәттеләр...»

Җир астыннан чыгуга нефть (Рәсимә аны беренче тапкыр лабораториягә аяк баскач кына күрә!) туп-туры промышленностька китми бит әле. Ул – әллә никадәр катнашмалардан тора, һәм лаборатория кызларының төп бурычы – әлеге катнашмаларның күләмен ачыклау, җир маена бәя бирү. Су күпме бу нефтьтә, күкерт, тоз никадәр, аның тыгызлыгы нинди, үзлелеге (Нурлат ягында табылган нефть башкалардан нәкъ менә үзлелеге белән аерылып тора да)... Идарәгә караган һәр скважинадан суыртылган нефть шулай тикшерелә. Лаборантның ялгышырга хакы юк! Эшеңә җаваплы караганда, бөтен күңелеңне биреп эшләгәндә ялгышларга урын да калмый.

– Без лабораториядә гел хатын-кызлар гына. Бер-беребезгә булышып, ярдәм итеп эшлибез. Нефтьтәге хлорорганик кушылмаларны ачыклау кебек катлаулы анализларны иң тәҗрибәле лаборантлар гына башкара. Без барыбыз да шул дәрәҗәгә күтәрелергә омтылабыз. Мин дә...

«Татнефть-Добыча» бүлекчәсенең нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехы лаборанты Рәсимә Туктарова монда күптән үз кеше. Лабораториядә аңа инде барысы да якын, үз. Кайчандыр әйтергә тел дә әйләнмәгән вискозиметр кебек приборлардан алып, исенә кадәр. Чәчләргә кадәр сеңгән ул исне үзе инде сизми дә, ире: «Кайтты минем механизаторым», – дигәч кенә искә төшә. Яратып әйтә – Ринат үзе дә бөтен гомере буе «Татнефть»тә хезмәт итә.

Ә җыр... Заманында Салават Фәтхетдинов үткәргән «Чаллы былбыллары» бәйгесендә Салаватның махсус бүләгенә ия булган, «Татар җыры»нда катнашкан вакытлар күптән инде артта. Әмма җыр – һәрвакыт күңелдә! Гармунда, фортепианода, гитарада, думбрада уйнаган җырчы лаборант, идарә данын яклап, сәхнәгә бүген дә күтәрелгәли. Ә эшләгәндә онытылып «Гөлҗамал»ны сузып җибәргән чаклары гел булып тора...

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

Видеокотлау »


ЯҢА ЕЛ – МОГҖИЗА КӨТҮ...

1992 елны каршылыйбыз (төгәл беләм, чөнки беренче сыйныфта укыйм). Яңа ел бәйрәменә киеп барырга ак колготки кирәк, ә ул юк. Елыйм, Кыш бабайга ничек шигырь сөйләрмен?! Алланың рәхмәте, әти Яльчикка барып, ак колготки алып кайтты. «Кыш бабай бүләге бу», – ди. И-и, сөенгәннәрем… Хәзерге балаларга Кыш бабай бүләге дип ак колготки алып кайтсаң, шаярту дип кабул итәрләр иде. Ә минем өчен ул мәңге истә калырлык кадерле булды.





Руфия РӘХМӘТУЛЛИНА

«Кыш бабай белә»

Чирек гасыр узган, ә шуның кадәр аерма. Бүген элеккеге кебек төсле кәгазьдән ясалган уенчык, чылбырлар белән өй, фатир бизәүләр бетте. Ә бар иде бит заманалар... Бер көнгә унар метр чылбыр ясыйсың. (Мәктәпкә алып барырга, өйне дә бизәргә кирәк.) Аның әле төсле кәгазе дә бетә. Шулай да чыгу җаен табасың: туры сызыклы дәфтәр битләрен буяу белән төрле төсләргә буйыйсың. Кипкәч, туры сызыклар буенча дәфтәр битен кисәсең. Еш кына әле аның ябыштырыр өчен җилеме дә булмый. Шуңа да пешкән бәрәңгене тәлинкәдә изеп, крахмалын чыгарасың. Ул катып китсә, кәстрүлдән икенче бәрәңгене аласың. Яңа ел чылбыры менә шулай ясала... Һәм иң рәхәте җитә – өйне бизәү. Стеналарга, түшәмнәргә аллы-гөлле чылбырны кнопка белән ябыштырып чыгасың. Соңыннан: «Эх, ничек матур булды!» – дип сокланасың. Әти-әни дә, бу эшеңне күреп, мактап җибәрсә, бетте инде, башлар түшәмгә тия...

Кечкенә чакта Кыш бабай бизәлгән йортка гына киләдер кебек тоела иде. Янәсе, матуррак бизәгән саен, ул сиңа затлырак бүләк алып килә. Ул көнне тиз генә йоклап киттем юк. Юрган астыннан шыпырт кына карап ятасың: Кыш бабай башта тәрәзәдән карап алыр, аннан морҗадан төшеп бүләген калдырыр кебек. Менә шул мизгелне күреп каласы килә... Балачак үтте, ә Кыш бабайның морҗадан төшкәнен тәки тотып булмады. Бары чыршы төбендә уенчыгын, абый белән икебезгә калдырган ике мандаринын гына ала идек...

Кыш бабайга хат язганны хәтерләмим. Ул чакта аның алып килгән һәр бүләге затлы, көтеп алынган була иде. Җитмәсә, әни дә: «Кыш бабай нинди бүләк бирәсен үзе белә», – дия. Бер елны ул бүләк – эчке кием, икенче елны курчак булырга мөмкин. Кыш бабай үзе белә...

Бүген дә йорт, фатирларны бизибез. Әйе, дәфтәр битен буяп, кисеп ясалган чылбыр белән түгел. Хәзер кибетләрдә өч, җиде, ун метрлы стенага әлә торган тоташ гирлянда, тагын әллә ниләр бар. Биш минут эчендә фатир аллы-гөлле утлар яктысына күмелә. Ул көнне, Яңа ел рәсеме төшерелгән эскәтерне җәеп, гаилә белән кечке ашны ашыйсың. Әле чыршы да бизәлгән булса... Дөрес, балачактагы кебек тәрәзәдән карап йөрүче Кыш бабайны көтмисең инде. Хәзер үзебез могҗиза тудыручылар ролендә бит.

Өченче сыйныфта укучы игезәк кызларыбыз узган ел Кыш бабайның чын түгел икәнен кайтып әйттеләр:

– Әни, мәктәпкә бүген Кыш бабай килде. Ну... куштырнаклар эчендә... Бүләкләр бирде. Без инде аңа ышанган булып кыландык, ләкин аның чын түгел икәнен белдек. Унынчы сыйныф малае иде ул, таныдык без аны.

– Димәк, чыны өйгә килер, – дим.

– Беләбез инде, анысын да сез чакыртасыз. Акча түләп. Кыш бабайга бүләкне дә сез алып бирәсез.

– ?!

– Инстаграмнан күрдек, Яңа ел төнендә Кыш бабайны чакырту ике тапкыр кыйммәтрәк була икән.



Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ, Татарстанның баш казые

– Әлбәттә, минем Яңа ел каршылаганым юк. Оныклар булса да, өйдә чыршы да бизәмибез. Ә менә балалар 31 декабрь көнне берәрсенең өендә җыелып утыралар. Әлбәттә, ул хәмерсез табын була. Әле яшьләр атлар бизәп, Кыш бабай булып киенеп, авылдашларга бүләк тә таратып йөри. Кечкенә балаларга Коръән укыттырып карыйлар. Һәм башларыннан сыйпап, бүләк тапшыралар. Без аннан проблема ясамыйбыз. Туган көннәрдә дә шулай җыелалар. 1 Майда табигатькә чыгалар.

Мин оныкларыма Яңа елга бүләк бирәм. Алар аны башта Аллаһы Тәгаләдән дога кылып сорый, без алып кайтабыз. Дини бәйрәмнәрдә дә оныкларны бүләксез калдырмыйм.

Балалар турында сүз чыккач, тагын шуны әйтим: бала күңелендә уңай персонаж булырга тиеш. Кыш бабай шундый бер герой гына бит. Аны зурлап сөйләп, күпертергә кирәкми. Кешеләр әллә нинди зур гөнаһлар эшли, Кыш бабай аның янында чүп кенә ул...

Бер мисал. Бөрбаш бакчасында оныгым белән бер төркемгә егермегә якын бала йөри. Күз алдына китерик – алар үзара: «Сиңа Кыш бабай нәрсә алып килде?» – дип сөйләшә. Барысы да нәрсә алып килгәнен әйтеп чыга. Ә безнең онык: «Безнең әти-әни намаз укый, безгә Кыш бабай килми», – дип әйтә. Шуннан төркемдәге башка балалар ничек уйлый? «Кара, намаз уку начар икән, анда Кыш бабай да килми...» – диячәк бит.

Кайбер очракта өлкәннәр баласын чыршы бәйрәменә җибәрми. Бала елап, шешенеп бетә. Әйе, әти-әни Яңа ел белән баш катырмаса, Аллаһы Тәгалә каршында гөнаһлы булмыйдыр. Тик бит аның икенче ягын да исәпкә алырга кирәк. Баланың иптәшләре исламны куркыныч, караңгы итеп күреп үсә...



Фото: Анна Арахамия



Гөлшат АБДУЛЛИНА,
Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясенең башлангыч сыйныфлар буенча директор урынбасары

– Бала могҗизага ышансын дисәң, башта ата-ана үзе шуңа инансын. Әйе, замана белән балалар да үзгәрә. Әле олы кызым үскән чорда, 10, 11 яшькә кадәр чын күңеленнән ышанып, Кыш бабайга хат язды. Кече улыбыз җиденче сыйныфта укый. Аның инде Кыш бабайга икенчерәк мөнәсәбәт булды. Шулай да башлангычта укыганда Яңа елны зур бер дулкынлану белән көтә иде.

Гимназиядә ел саен Яңа ел бүләкләрен Кыш бабай тарата. «Әле генә бизәлгән чанасына утырып, махсус сезгә дип бүләкләр алып килде», – дибез. Беренче, икенче сыйныфлар Кыш бабайга самими күзләр белән карап, шундый сөенәләр инде... Өченче, дүртенче сыйныфлар әлеге көтелгән кунакны бүтәнчәрәк кабул итә: ышаныргамы, юкмы икән дигән сыман. Шулай да тәмле бүләкләр алу алар өчен дә бик күңелле!

Яңа ел балачакның иң күңелле бер бәйрәме булып истә калган. Без Кыш бабайдан бүләк сорап хат язмадык. Шулай да әти ел саен чыршы алып кайтып, аны бергәләп бизәү матур бер гадәт иде. Яңа елны каршы алганда, өй шулай якты, матур булырга тиеш дип уйлый идек. Бүген дә Яңа елны көтеп алам. Нииндидер могҗиза булыр сыман. Безне бит киләчәккә яхшы өмет, хыял яшәтә. Шунсыз бу тормышта мөмкин түгел...

Менә шулай Кыш бабай турындагы якты әкият бер көндә чәлпәрәмә килде. Алар инде бу хакта мәктәптә дә сөйләшкәннәр. Шулай да кызларыбызның күңел түрендә бер өмет яши – чын Кыш бабай да бар. Ләкин ул бер генә, ә Россия бик зур. Ул бөтен балаларга да килеп җитә алмый. Чын Кыш бабай күбрәк Балалар йортында яшәүче малайлар-кызлар янына бара, чөнки бүләк алырга аларның әти-әниләре юк. Дөресрәге, бу мин уйлап чыгарган хикәя. Ләкин кызларга бу хикәя ошый, алар шуңа разый... Шуңа быел да Кыш бабайга хат яздылар.

Һәр чорның үз маймылы

Әйе, бүгенге балалар артык күпне белә. Монда телевизор, интернет йогынтысы да зур. Ләкин яшәү рәвешебез, ата-аналар да балаларыбызны хыяллана белү бәхетеннән мәхрүм итә кебек. Бүген өстәл тулы ризык, кием-салымны әйткән дә юк. (Гомумән, балаларның яңа киемгә исләре китми.) Уенчык белән дә шаккатырып булмый. Шул берәр заманча гаджетка сөенсәләр генә. Менә шуңа да Кыш бабай алып килгән конфет-печенье аларга тансык түгел. Декабрь башында гына кибетләргә кайта торган апельсин, мандариннарны да ел әйләнәсе ашыйбыз. Ә бит әле без үскәндә дә бу җимешләр Яңа ел символы иде.

Бүгенге заманның үз символлары шул. Яңа ел җиткәндә социаль челтәрләр яңа ел фотолары белән тула. Заманча сүз белән әйтсәк, бу хәзер – тренд. Бер ел эчендә танышларыбыз ничек үзгәргән, балалары ничек үскән, шуннан беләбез.

Фотосессиягә бигрәк тә гүзәл затлар җитди карый. Алдан бөтен гаилә өчен пардан киемнәр сатып алалар (тектерәләр), макияжлар, чәчләрен ясаталар. Казанда яшәүче ике бала әнисе, фотограф Лилиана Вәлитова яшерми – даими рәвештә фотосессия ясаткан әниләрне аңлап бетерми. Бу яктан ул итексез итекче кебек – Яңа елга гаиләсе белән төшкән фотолары юк.

– Мин күбрәк видеолар төшерәм, – диде Лилиана. – Ә фото дип исем китми, аның кирәген күрмим. Фотога төшергәннән соң клиентларыма ссылка гына җибәрәм. Барлык фотографлар да шулай эшли хәзер. Дөресен генә әйткәндә, аларның күбесе ул фотоны бастырмый да, электрон форматта гына калдыра. Шул социаль челтәрләргә кую өчен кирәк инде ул.

Лилиана әйтүенчә, Яңа ел фотосессияләре декабрь башында башлана. Залны арендалау 1 мең 300 сумнан башлап 2 мең 300 сумга кадәр икән. Шуның өстенә, фотограф сәгатенә 2 мең сумнан 3 мең 500 сумга кадәр ала. Кыскасы, социаль челтәрдә синең гаиләңә карап соклансыннар, матур комментарийлар язсыннар дисәң, ким дигәндә 10–12 мең сум акча кирәк. Тик... Монда могҗиза кайда соң? Шул лайклар саны миллионга җитсен дип көтсәң генә инде...

Бүген балалар да Яңа елны бүтәнчә кабул итә кебек. Тылсым җитми димме... Ә психологлар бертавыштан могҗизага ышанырга кирәк, диләр. Бигрәк тә бу балалар психикасы өчен уңай йогынты ясый икән. Эгоизмны бетерә, якты киләчәккә ышандыра, диләр. Шул исәптән, өлкәннәргә дә. Ә бүген без үз кулыбыз белән могҗиза ясарга тырышабыз. Һәм ул ясалма килеп чыга, моңа хәтта балаларыбыз да ышанмый. Кызганыч ки...





Алинә ЗАҺИТОВА, фигуралы шуу буенча Олимпия чемпионы, Дөнья чемпионы, Европа чемпионы, Россиянең иң популяр спортчысы

Алинә – Алинә шул инде! Инде ярышларда катнашудан тукталып торса да, шаккаттыруын, сокландыруын дәвам итә. «Безнең Алиһә!», «Кабатланмас һәм илаһи!», «Планетаның иң шәп фигуристкасы», «Уңай эмоцияләр бирә торган сылу кыз», «Боз королевасы» дип йөртәләр аны. Японнар өчен Алинә – матурлык һәм көчле ихтыяр символы. Кытайлар исә аны «Россиянең карлы лотос чәчәге» дип атаган. Атаклы тренер Александр Жулин: «Алинәнең бозга чыгуы һәрвакыт бәйрәм! Үз стиле булган искиткеч спортчы ул. Аның чыгышын каравы ук рәхәт, күңелле», – ди.

Ә Алинә ел буена һаман уңышлары белән сөендерә безне. Гыйнварда «Спящая красавица» боз мюзиклында баш рольдә катнашып, тамашачыларга Яңа ел бүләге ясады, мәктәпне тәмамлап, дәүләт имтиханнары тапшырды, журналистика факультетына укырга керде, машина йөртү правасы алды, аның 812 меңнән артык язылучысы бар, телевидениенең I каналында популяр шоу «Ледниковый период»ны алып бара, тренировкаларын дәвам итә... «Матч ТВ» телеканалы күптән түгел Алинә Заһитованы Россиянең иң популяр спортчысы дип атады. «Фигуралы шууга гашыйклар» фестивалендә Олимпия чемпионының чыгыш ясавын исә Заһитованың бозга триумфаль кайтуы дип билгеләп үттеләр. Һәм, ниһаять, фигуралы шуу буенча Россиянең Мәскәүдә узган Гран-при этабы. Алинә анда «Жизнь» программасын күрсәтте, икенче бүлектә исә «Нотр-Дам де Пари» мюзиклы музыкасында Гюгоның Эсмеральдасы белән таң калдырды! Җанатарлар күз яшьләре аша елмаеп, аягүрә басып алкышлады! Трибуналардан бозга чәчәкләр һәм мандарин төсендәге «йөрәкчекләр» яуды. Бу төс – кояш төсе, бәхет, шатлык төсе, якынлашып килүче Яңа ел төсе! Миллионнар синең Бозга кабат кайтуыңны көтә, Алинә!

СПОРТ

«СОКЛАНДЫРДЫЛАР-2020

Күзаллау гаҗәеп көчкә ия: бер минут, һәм ул сине әллә кайларга очыртып алып китә! Пабло Пикассоның «Девочка на шаре» картинасын хәтерлисезме? Шар өстендәге кыз, XX йөз башындагы Париж, циркачлар... Шундый шәп картина! Фигуралы шуу буенча чемпион титуллары яулаган Казан кызы Камилә Вәлиева нәкъ менә шул картинадагы кыз образында тамашачыны таң калдыра!..

«Миңа башта картинаны күрсәттеләр, мин – шар өстендәге кыз, җанланып, чынбарлыкка әләгергә тиеш. Программаның икенче өлешендә дөнья инде чынлап та матур икәнен тоя башлыйм. Ләкин ахырдан миңа кабат картинага кайтырга һәм хәрәкәтсез калырга кирәк. Мин менә шулай күрдем программаны», – ди Камилә. Күзгә күренмәс нәфис хәрәкәтләр, талгын сикерешләр – әйтерсең Камилә әле генә картинадан төшкән; ә гәүдәсе мамык кебек җип-җиңел – әйтерсең ул сөяксез... Музыка әкренләп көчәя, куәтләнә бара, ә фигуристка күз иярмәс тизлектә бөтерелә! Һәм кинәт бар да өзелә: бу галәмдә вакытның коточкыч тизлектә очуын аңлап, Камилә картинада тораташтай басып кала. Рәссам акробат кызның сыгылмалылыгын тасвирлаган. Камилә – нәкъ картина герое! Хәтта кофта белән шортигы да шул ук – шар өстендәге кызныкы! Таллинда узган Дөнья чемпионатында Пикассо картинасы буенча куелган программасы белән 227,30 балл җыеп, Камилә дөнья рекорды куя! Вәлиеваны 2022 елда Пекинда узачак Олимпия уеннары фавориты итеп күрәләр хәзер. Аны «икенче Заһитова» дип тә йөртәләр, Каролина Костнерга да охшаталар, «принцесса» дип тә атыйлар... Юк, Камилә Вәлиева – бердәнбер, ул – кабатланмас. Өч яшь ярымда ук бозда шуа башлаган бу бөтерчек кызны әти-әнисе кечкенәдән үк йә фигуралы шуу, йә нәфис гимнастика, йә балет буенча китәргә әзерлиләр. Камилә фигуралы шууны сайлый. Гаиләләре белән Мәскәүгә күченгәч, аңа төрле тренерларда шөгыльләнергә туры килә. Хәзер ул – Этери Тутберидзеның талантлы укучысы.

Камилә ВӘЛИЕВА, Россия спортчысы, спорт мастерлыгына кандидат, 2020 елда фигуралы шуу буенча юниорлар арасында Дөнья чемпионы



Фото: @azagitova, @kamilavalieva.team

«ӘЗ БУЛСЫН, ТӘМЛЕ БУЛСЫН...»

Татар халкының бөек җырчылары Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев варисы ул, бөекләр чылбырын дәвам итүче, диләр аның хакында. Үзенә генә хас мелизмнары белән җырлаганда, иң кирәкле урыннарга басым ясап, күңелләрне бөтереп алып, әллә кайларга алып китеп, сулыш алырга да оныттыра ул. Затлы, зыялы кешеләр өчен аның концертына бару үзенә күрә бер мәртәбә санала. Атналар буе концерт куймый ул, чөнки тормыш шигаре башка. Сәхнәдә үзен тәрбиялелекнең иң югары дәрәҗәсендә, кысаларда тоткан Татарстанның атказанган артисты бәрхет тембрлы Филүс КАҺИРОВ тормышта бөтенләй башка икән. Үзе белән сөйләшик әле.



Филүс, сине «алтын тавыш» иясе, диләр. Үзең бу бәягә ничек карыйсың?

– Бу бәяне композитор Резеда Ахиярова биргән иде, әмма бөтен кеше дә алай уйламыйдыр. Һәр тамашачының үз яраткан җырчысы «алтын тавышлы» булып тоеладыр. Мондый бәя җаваплылык кына өсти.

Белүемчә, син консерваториядә опера җырчысы булам дип укымагансың?

– Авыл баласы бит инде без. Бер авыл баласы да, үскәч опера җырчысы булам дими, чөнки ул аны аңламый, аннан ерак. Нота да белми идек. Җырны ничек отып алдык, шулай җырладык. Музыка училищесына укырга кергәч, укытучым Галия Мусина: «Казанга барсаң, консерваториягә укырга кер», – ди иде. Ә минем арияләр башкарасы килми. Хыялым: татар эстрадасының танылган җырчысы булу. Менә шуңа таба атладым. Консерваториягә дә халыкчан җырлау бүлегенә укырга кердем. Укытучым Зилә Сөнгатуллина: «Болар сиңа кирәк булачак», – дип, арияләр дә

өйрәтте. Дүртенче курста «Евгений Онегин»да Ленскийны җырларга чакырдылар. Әкренләп өйрәнә башлагач, ошап китте. Кызыксына башладым. Академия бүлегенә күчтем. Операларда партияләрем барлыкка килде. Аннан дилемма алдына килеп бастым. Ике юлның берсен сайларга кирәк иде. Классиканы да җырлыйсы килә, эстрада – балачак хыялы. Менә шулай икесен дә алып барырга тырышам. Мөслим Магомаев та операда да, эстрадада да җырлаган. Опера тавышны формада тотарга ярдәм итә. Әле менә мюзиклда да җырлыйм.

Әйе, син «Алтын Казан» мюзиклында төп рольләрнең берсе – Битимерне башкарасың...

– Мюзикл бөтенләй икенче дөнья. Аны опера белән эстрада арасында торучы бер жанр дип кабул итәм. Нәкъ минем өчен инде. (*Көлә.*) Җырлаганда үз йөземне югалтмыйча, икесен бергә кушарга тырышам. Җырлау – бер, әле заманча биюләр биисе бар анда.

Эстрадада киң катлам өчен нинди җырчыларның популяр икәнен күреп торасың. Җыр сыйфаты, тавыш сыйфаты өчен җан аткан җырчы буларак, күңелең төшенкелеккә бирелмиме?

– Булыштырды. Нишләп бу кешегә ярый, миңа ярамый дигән уйлар еш килә иде. Без бит консерватория тәрбиясе алган җырчылар. «Монысы ярамый, тегесе ярамый», – дип өйрәттеләр. «Ярамый»лар хәтта артык күп дип тә әйтер идем. Әмма кысаларсыз да булмый. Тамашачылар өчен артист өлге булып торырга тиеш. Ә хәзер ул күршегә әйләнеп бара.

Филүс, ник концертларыңны ике генә көн куеп чикләнәсең? Сине тыңларга теләүчеләр ике көндә генә бетмидер дип уйлыйм.

– Миллиардлар бирәбез дисәләр дә, аена 30 концерт эшли алмас идем. Ялкыта. Бер урында таптанып торырга яратмыйм. Әз булсын, тәмле булсын. Миңа һәрвакыт яңалык кирәк. Шуңа күрә дә әле эстрадада, әле операда, әле мюзиклдамын.

Сине пародия остасы, диләр.

– (*Рөстәм Закиров тавышы чыгарып.*) Алай дип әйтмәс идем, Чулпан, әмма кеше шулай дип әйтә икән, ышанырга кирәк. Халык сөйли – хак сөйли. (*Рөстәм абый кебек йөреп күрсәтеп алгач, кычкырып көлеп җибәрәбез.*) Концертларымда бик сирәк очракта гына кулланам бу сәләтемне. Пародия остасы булган коллегаларым мактый, концертларыңда юмор куллан, диләр. Күп кирәкми! Әйтәм бит, әз булсын, тәмле булсын (*Филүс пародияләре QR-код аша кереп, ютубтагы роликлардан карый аласыз. – ред.*). Бу – кечкенәдән килгән сәләт. Башта актер буласым килгән иде.

Операга тартылуың менә ни өчен икән...

– Менә... Анысы да бар икән шул. Чынлап та! Уйнау кирәк миңа. Без кечкенә чакта мәҗлесләр өйдә уза иде бит. Әллә кемнәр булып уйнап, килгән кунакларны көлдерә идек.

Димәк, сәхнәдәге Филүс белән тормыштагы Филүс аерыла?

– Тормышта мин күңелле кеше. Әңгәмәдәшемне көлдереп, күңелен күтәрәм икән, үземә рәхәт. Әмма бик оялчанмын. Укыганда такта янына чыгып сөйли башласам, кып-кызыл була идем. Укытучы (*тавышын үзгәртеп*): «Филүс ояла, бу – әйбәт», – дип әйтә иде. Кеше алдашса, кызара. Мин алдасам, алдамасам да кызарам. (*Рәхәтләнеп көлә.*) Сәхнәгә чыккач та кызарам. Дулкынлану, борчылу микән инде бу...

Нинди хыяллар белән яшисең?

– (*Бераз уйланып торганнан соң.*) Иң авыр сорау булды бу! Моңа тиклем интервьюларда хыялларны әйтмиләр, ул тормышка ашмый дип котыла идем... (*Уйга калып.*) Балачак хыялым чынга ашты инде. Шуннан соң нәрсә?.. Менә монда аптырап калдым, нишләргә? Бәлки, дөньякүләм танылуны максат итеп куяргадыр? Моның өчен нинди юнәлештә эшләргә? Тагын бер югарылык алсам, нәрсәдәндер баш тартырга кирәк булачак. Мин әле моңа әзер түгел. Уңайлы мохиттән чыгар вакыт җитмәгән. Әмма уйландыра башлады...

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА
Фото: Анна АРАХАМИЯ
Видео: Фәнис САДЫЙКОВ



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



ЧЕЛТЕР-ЧЕЛТЕР ТАЛИР ТӘҢКӘ



Лилия
ГӘРӘЕВА

Татар кызын күргәнче, башта ишетәсең, дигән борынгылар. Чулпы, хәситә, чәч тезмәләрендәге талир тәңкәләре челтер-челтер челтерәп, урамнан татар кызы килүен алдан ук хәбәр иткән шулай. Бүген, әлбәттә, атлаган уңайга тәңкәләр челтерәми, чулпылар такмыйбыз, киемнәребез дә бүтән... Хәситә нәрсә дә, яка чылбыры ни, дип сорасаң, күбебез аптырап ук калыр иде. Югыйсә хәситә, изү, яка чылбыры ише милли бизәнү әйберләре – үзебезгә генә хас үзенчәлекле детальләр дә бит... Онытканбыз шул, хәтерләмибез... Интернеттан хәситә дип эзләсәгез, ул сезне музей битләренә алып керәчәк, тарихын күрсәтәчәк. Ә менә хәзер замана кызлары да киеп йөрердәй хәситә ясаучылар бармы соң? Дөресен әйтим, бүгенге героебызны озак эзләдек. Хәситә ясаучылар бар, ләкин борынгыча итеп, кыйммәтле ташлар белән бизәп ясаучысын гына табуы кыен. Ә безгә нәкъ менә борынгылыкны заманча куллана белгән, аның кыйммәтен аңлаган оста кирәк иде. Оренбург кызы Гөлфия ШӘЙДУЛЛИНА-БИЛАЛОВА без эзләгән кеше булып чыкты. Ул тегүче һәм дизайнер... Әти-әнисе аны үзләре кебек укытучы яисә табиб итеп күрергә теләсә дә, Гөлфия бөтенләй башка өлкәне сайлый. Хәер, очраклылык юк монда.

– Кечкенәдән тегәргә яраттым, – ди ул. – Әтиемнең әнисе Гөлчирә әбием дә матур киенергә һәвәс иде. Кунакка кайткан саен, яңа күлмәктән каршы ала иде безне.

Тугызынчыны тәмамлагач, Оренбургтагы 18 нче һөнәр училищесына укырга керә. Балачактан Сания әбисенең «Зингер» машинасын текелдәтүләр, әтисенең чалбарларын «яңартып тегүләр» үзенекен итә – героебыз тегүче-кисүче һөнәрен сайлый.

– Училище минем өчен бик зур мәктәп булды. Осталарның бер дигәннәре белем бирде безгә. Дүрт ел дәверендә тегүчелек һөнәренең үземнеке булуына инандым. Әмма безнең гаиләдә бар да югары белемле. Минем үземнең дә югары белем аласым килә иде, – дип, студент елларын да искә төшереп үтә Гөлфия.

Дизайнер дигән сүз сирәк ишетелә әле ул чорларда. Шул сирәк белгечлеккә ия булу теләге Оренбург дәүләт университетының архитектура-төзелеш факультетына алып килә аны. Бу факультетны медакадемия белән чагыштыралар. Анда да уку катлаулы, монда да.

– Икенче курстан соң Европа илләрендә стажировка үтәргә кирәк иде. Җиде илдә булып, андагы халыкларның сәнгать һәм дизайн тарихын өйрәндек. Баштарак, шактый зур чыгымнар тотып, бу илләргә ник баруыбызны аңлап та җиткермәгәнмендер, – ди ул. – Ләкин бик тә кирәкле тәҗрибә булган ул – дөнья җәүһәрләрен үз күзләрең белән күрү күңел офыкларын киңәйтә, күзаллауны тулыландыра. Дизайнер фантазиясе ачылсын өчен дөньяны өйрәнү мөһим.

Нидерландларның әле дә үзләренең милли аяк киеме саналган агач кәвешләрен саклавын, аларны көнкүрештә куллануларын хәйран калып сөйли. «Минем халкымның да борынгы, үзенә генә хас киемнәре булган бит, ник без аларны шулай саклый һәм башкаларга күрсәтә белмибез?» – дигән беренче уй әнә шул чакта тугандыр, бәлки. Кашемир яулыкларын татарча таратып бәйләгән Сания һәм Гөлчирә әбекәйләре күз алдына килә.

...Университетта күңелле ыгы-зыгы – студентлар фәнни конференциягә әзерләнә. «Ә нигә әле сиңа үз милләтең белән бәйле тема сайламаска, – ди укытучысы өченче курс студенткасы Гөлфиягә. – Сиңа костюмнар темасы якынрак бит...» Өч ел дәвам иттерелеп, соңыннан диплом эшенә дә әйләнәчәк татар милли костюмы темасына әнә шулай кереп китә ул. Бу теманың үзен никадәр мавыктырасын ул вакытта әле күз алдына да китерми.

Борынгы киемнәрдә бер генә очраклы деталь дә юк. Барысы да энергияне саклауга хезмәт итә.

– Оренбург зур шәһәр түгел, андагы күргәзмә, музейларны йөреп чыгып, үземә материал тупладым, – дип искә төшерә Гөлфия.

Аның өчен бар да яңа. Әйтик, гасыр тузаннарын сеңдергән менә бу борынгы түбәтәй ничек тегелгән? Эчке ягында ниләр бар? Һәммәсен җентекләбрәк беләсе һәм өйрәнәсе килә аның. Соңыннан Казандагы дәүләт милли музеена тәҗрибә тупларга килгәч, хыялына ирешәчәк әле ул – борынгы җөйләрне күрәчәк, экспонатларны ничек реставрацияләүләрен күзәтәчәк. «Ник мин боларны элегрәк белмәдем икән?» – дип гаҗәпләнәчәк.


Казаннан рухи яктан да, матди яктан да баеп кайта булачак дизайнер. Монда үзе өчен бәһасе булмаган китапларга юлыга. Арада иң кыйммәтлесе – халкыбызның борынгы сәнгате белән бәйле һөнәрчелеккә багышланганы.

Диплом яклар көн якынлаша. Берничә шәһәрдән яхшы тукымалар кайтарта. Җитәкчесенең фикерен тыңлап, төрле чылбырлар сатып ала. Ләкин ничек кенә тырышса да, чылбырлар җанына ятмый. Татар милли бизәкләре башкачарак булырга тиеш кебек... Казаннан алып кайткан китапларын кулына ала. Шулчак әйтерсең күңел күзләре ачылып итә! Беренче хәситәсе, яка чылбыры һәм чулпылары диплом коллекциясе белән бергә туа. Татар халкын таныта торган иң билгеле өч зур эшләнмәне башкарып чыга Гөлфия.

– Вакыт бик аз калган иде. Костюмнарны да үзем тегәсе, җитмәсә, бизәкләрен кулдан чигәргә кирәк... Өлгермисең, диде укытучым. Тиз арада әниемне һәм чигә белгән туганымны эшкә җәлеп иттем. Оренбургтагы зәркән кибетенә көн дә эшкә барган кебек бара идем, – дип көлә яшь дизайнер. – Кулыма берәр муенсаны алам







Күзең төшкән кызга күңелеңне белдерү өчен бирелә торган көмеш тәңкәне талир тәңкә дип атаганнар.

да, тәсбих тарткан кебек, мәрҗәннәрен саныйм. Кибетчеләр аптырагандыр инде. Ә миңа хәситәм, чулпыларым өчен ничә таш кирәген исәпләргә кирәк. Коллекциям өчен тукымаларның затлыларын сайладым, димәк, аксессуарлар да чын ташлардан ясалган булырга тиеш.

Коллекция гаҗәеп уңыш казана. Европа стилендәге эшлекле костюмнар татарча милли бизәкләр белән бөтенләй көтелмәгәнчә ачыла. Соңыннан әлеге коллекцияне күргәч: «Классик костюмны милли бизәкләргә өйләндерә алгансың», – ди мода белгече Александр Васильев.

Беренче хәситәсе әле дә кадерләп саклanучы ядкарь.

– Хәзер шул эшләремә карыйм да, елмаеп куям. Тәҗрибә эшли-эшли, өйрәнә-өйрәнә килә шул, – ди ул. – Дөресен әйтим, хәситәне мин башта озак кына аңлый алмадым. Ничек киелә ул, нинди очракларда? Әбиемнән дә сораштым, ул да ишетеп кенә белә булып чыкты. Хәситәне элек бай тормышлы хатын-кызлар кигән, аннан әнисеннән кызына мирас булып калган.

Ә безгә исә хәситәне ясау процессы кызык. Нинди материаллар кулланыла, аларны кайлардан таба оста?

– Ярашлы материаллар табу – иң катлаулысы, – ди Гөлфия үзе дә. – Кая гына барсам да, мин гел үземә кирәкле ташлар, сәйләннәр эзлим, каптырма-фурнитуралар караштырам. Беренче эшләнмәләремнең кимчелеге дә фурнитураның сыйфатлысын таба алмавымда иде. Алар бик чыдам булырга, вакытлар узгач та төсен үзгәртмәскә тиеш.

Аның эш өстәле салават күпере балкышын хәтерләтә. Бу сәйләннәр хәситә булып тезелгәнче, башта җентекле сайлау уза әле: зурлыгына карап, төсенә, рәвешенә карап...

– Эш өстәлемне кешегә күрсәтергә дә оялам. Анда ниләр генә юк, – ди дизайнер. – Башта мин барысын да таратып салып, палитра сайлыйм. Атна буе да шулай таралган килеш торырга мөмкин ул. Өйдәгеләр белә инде, андагы бер генә нәрсәне дә урыныннан кучерергә ярамый.

Элеккеге хәситәләр тукыма җирлеккә беркетелгән брошкалардан, тәңкәләрдән тезелгән. Анда арзанлы материаллар юк – алтын-көмеш һәм асылташлар. Бу хакта озак уйландым. Алтын-көмешләр кулланcам, ул эшләнмәләр бик зур бәягә чыгар иде. Шуңа да ярым кыйммәтле ташларга туктaлдым. Вакыт узса да, алар төсен югалтмый, тоныкланмый. Ташлар энергияне дә саклый. Хәситәнең төп асылы да шунда – хатын-кызның энергиясен саклауда булган бит. Гаҗәеп әйбер ул. Аның формасы да гадәти генә түгел – иңбашында таррак, ә урта өлеше чак кына киңәеп китә. Хатын-кызның иң мөһим органнарын, чакраларын яман күзләрдән саклау өчен шулай уйланылгандыр, минемчә. Аны сул як җилкәгә кияләр. Монысы да кызык. Сәбәбен сорашканым булды. «Уң як җилкәдәге фәрештә яхшы гамәлләрне яза, аңа комачауламас өчендер», – дип шаярттылар.

Уйласаң, борынгыларның киемендәге бер деталь дә очраклы түгел. Татар хатын-кызлары ике кулына да көмеш беләзек кигән. Христианнарда исә җиң очлары чигүле. Болар да энергияне саклау өчен. Чәч тезмәсен алыйк. Толымны каплап, умыртка буйлап сузылып төшә ул. Татарлар гына түгел, башка халыклар да кулланган аны. Чәчләр бит бик көчле антенна дип исәпләнелә. Алар чит энергияне кабул итеп, тәнгә сеңдерә. Борынгылар энергияне саклауга зур әһәмият биргән.

...Гөлфия хәзер Казанда яшәп иҗат итә. Әле университетта укыганда ук укытучылары аның киләчәген Казан белән бәйли. Шулай килеп чыга да. 2015 елда Казанда халыкара мөселман хатын-кызларының кием күргәзмәсе уза. Оренбургтан килгән яшь дизайнерның коллекциясе катнашучыларның игътибарын шунда ук җәлеп итә.

Киемдә мөселманлыкны, заманчалыкны һәм миллилекне ничек яраштырырга? Гөлфия бу хакта озак уйлана. Татар халкының үзенчәлекле бизәкләре бары музейларда гына яшәвен күрү күңелен төшерә аның. Әйе, ул үзе дә милли детальләр кулланып, үзенчәлекле киемнәр тегә. Ләкин кием туза, онытыла. Ә Гөлфиянең тузмый да, онытылмый да торган әйберләр иҗат итәсе килә.

Дөньяда бертөсле ике кеше булмаган кебек, оста кулында яралган бизәкләр дә бер-берсен кабатламый.

– Бик теләсәм дә, аларның копияләрен башкача ясый алмыйм, – ди ул. – Гомумән, заказ бирүче миңа тулысынча ышанган очракта гына эшләрем уңышлы чыга. Заказлар катлаулырак булган саен, үземә дә кызыклырак. Әлегә мин ташлар, сәйлән белән эшлим. Ташлар телен өйрәнәм. Ләкин күңелемне торган саен металлар күбрәк җәлеп итә. Пәрәвездәй нечкә генә чыбыклар белән эшләве үтә дә катлаулы. Махсус җиһазлар булуын таләп итә ул. Бәлки, тора-бара ул техниканы да кулланырмын. Камиллеккә чикләр юк, диләр бит...

Аның хәситәләре хәзер дөньяның төрле почмагында – Казакъстанда, Австралия һәм Америкада, Германия һәм Австриядә...

– Аларның хуҗалары барысы да татар ханымнары. Минемчә, чит илдә, милләттәшләреңнән аерым яшәгәндә үз янында халкыңның кечкенә генә бер кисәкчеген булдырасы килү табигыйдер, – ди оста. – Әле кайчан гына милли бизәкләргә игътибар юк иде, хәзер кызыксыналар. Табиб булып эшләүче бер ханым хәситә ясап бирүемне үтенде. «Патшабикәләр кебек киенәсем килә юбилеемда. Аннары мин аны кызыма ядкарь итеп калдырачакмын», – ди.

Музейга куелган борынгы хәситәләргә карап еш кына уйлана идем. Кайсы оста ясады икән боларны, хуҗалары кемнәр булган? Гаҗәп бит, оста инде күптән бу җирдән киткәндер, ә аның иҗаты әле дә яши, сокландыра... Үземнең хәситәләремә дә шундый озын гомер телим. Буыннардан-буыннарга тапшырылучы мирас булсын алар.

Фотолар: Гөлфия ШӘЙДУЛЛИНА-БИЛАЛОВА архивыннан

ХӘСИТӘ



Рәмзия
КАШАПОВА

ТАССРның 100 еллыгын бәйрәм итү кысаларында Казанда «Алтын хәситә» Халыкара милли кием бәйгесе зур уңыш белән үтте. Ул тамашачыларга татар мәдәниятен, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның мәдәнияте үрнәкләрен тәкъдим итте.

Әлеге конкурстан соң татар милли киеменең бер бизәге булган хәситә белән кызыксыну бермәбер артты! Ул кабатланмас, бөтенләй гадәти булмаган борынгы бизәнү әйбере ислам динен кабул иткәнгә кадәр үк булган.

Нәрсә соң ул хәситә? Сәнгать белгече Светлана Сусловaның Идел-Урал татарлары костюмнарына багышланган монографиясендә хәситә турында әллә ни күп әйтелмәгән, шулай да кызыклы мәгълүмат табарга була.

«Тукыма бәйләвеч – татар хатын-кызларының бик үзенчәлекле күкрәк бизәге. Аңа төрле тәңкәләр, асылмалар, кабырчык-каурыйлар, йомры сәдәфләр, ювелир эшләнмәләр тегелеп, берничә катлам тукымага тарттырып куела. Аларны хәситәнең бөтен буена рәт-рәт итеп тезгәннәр. Озынлыгы 30–40 см, киңлеге 5–12 см булган тукыма бәйләвечне күлмәк өстеннән сул беләк аша үткәреп, уң култык астына кигәннәр.

Мариларда, мәсәлән, бәйләвечләр архаик йола киемнәрендә очрый, һәм ул күкрәк бизәге булып хезмәт итә. Төньяк удмуртларның кайбер төркемнәрендә йола бизәге буларак та билгеле...»

Кешенең җаны тәненнән уң култык асты аша чыгып китә дигән инануларны да исәпкә алсак, хәситәнең нинди зур максатка хезмәт итүен аңларбыз. Димәк, Идел буе халыкларында мәҗүсилек чорында ук хуҗасының җан сакчысы булган ул.

Күптән түгел мин Санкт-Петербургта Россия этнография музее профессоры Татьяна Григорьевна Емельяненко белән очраштым. Ул – гомумтөрки мирасны өйрәнү барышында туган төрле сорауларыбызга җавап бирә, киңәшләре белән ярдәм итә торган күренекле галимә.

Этнография музеенда Казан ханлыгы чорына караган нинди дә булса табылдыкка юлыгуны өмет итмәсәң дә, бәхетле очраклар килеп чыгу ихтималы да бар икән. Минем белән шундыйрак хәл килеп чыкты. Петербургка хәситәгә бәйле тарихи белешмәләр тупларга өметләнеп барган идем. Һәм ул өметләр тулысынча акланды.

Татьяна Григорьевна минем каршымда Л. И. Альбауманың «Живопись Афрасиаба» дигән китабын ачып куя. Анда Афрасиаб шәһәрчегендәге стена рәсеме сюжетының репродукциясе *(10 нчы рәсем; Көньяк стена, 3 нче деталь, реконструкция. Җайдаклар).*

Тарихи белешмә: 1965 елда Урта Азия халыкларының материаль мәдәни тарихын тикшергәндә зур вакыйга булды – Сәмәркандта безнең эраның VII гасырына караган Афрасиаб шәһәрчегенең стена язулары сакланган сарай комплексы ачылды. Ә ун ел узгач, 1975 елда аларны ачу, консервацияләү, реставрацияләү һәм аларның сюжетларын өйрәнүгә караган фундаменталь монографияләр бастырылды. Бу китаплар хәзер раритетка әйләнде. Ул рәсемле язуларның төп нөсхәләре Сәмәркандтагы Афрасиаб музеенда саклана.


Шулай итеп, репродукциядә ни күрәбез, дисезме? Чаганиан дәүләте илчесе балдахин астында филгә утырган принцессаны янәшәсендәге хезмәтчесе, ат өстендәге сарай хатын-кызлары озатуында Согди дәүләте хакименә алып бара.

«Алдагы беренче хатынның сурәте барыннан да яхшырак сакланган. Ул, аякларын бер якка салындырып, көрән атта иярдә утырган... Маңгаена төшкән кара чәчләре бөҗраланып тора, чәчләрендә бизәнү әйберләре. Үзе озын итәкле җиңел ефәк күлмәктән: аның өске өлеше тезгә кадәр кызыл төстә, ә түбәнге өлеше – күпсанлы сырлар белән йомшак кара итәкләренә кадәр җиткәнә – сары. Уң җилкәсе һәм күкрәге аша киң тасма булып сул кул астыннан билгә кадәр тукыма бәйләвеч (хәситә!) төшкән. Йөгән тоткан кулның арткы ягында согди язуы аермачык шәйләнә «байбикәнең якыны...»

VII–VIII гасырларда Согыт дәүләте затлы киемле хатын-кызлар – төркиләрнең илчеләрен кабул итә шулай. Безнең милли хәситә аерым бер бизәк булып күзгә ташлана.

Петербургка соңгы баруымда мине әнә шундый табыш көтә иде. Татар хәситәсе XVIII гасыр белән генә чикләнмәгән, димәк: тамырлары бик еракта, тирәндә аның...

Аңлашылганча, нинди дә булса нәтиҗәләр ясар өчен исбат итә торган дәлилле чыганакларга – документларга, дивар сурәтләренә һәм шуларның реконструкцияләренә таянырга кирәк шул.



Вакыйга » «Алтын Казан» мюзиклы

МИН ЫШАНАМ СИҢА, КАЗАН!



Фото: Рамил Гали

Опера театрында – «Алтын Казан»! Мюзикл премьерасы! «Үзгәреш җиле» фестивалендә тамашачыны ике сәгатьлек шоу көтә! Джаз, оркестр, импровизацияләр!.. Гаҗәеп декорацияләр, төсләр балкышы, биюләр... Ул динамика, ул эйфория!.. Яшь композитор Эльмир Низамов һәм либретто авторы шагыйрь Ренат Харисның иҗади тандемы соклангыч әкияти әсәр тудырган! Беренче тапкыр шундый масштабтагы тамаша! Бу уңайдан М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры җитәкчелегенең мюзиклны сәхнәгә кую өчен Россия, Германия мэтрларын да җәлеп иткән. Куючы-режиссер Михаил Панджавидзе, сәнгать җитәкчесе Вадим Эйлинкриг, рәссам-сценограф Гарри Гуммель, дирижер Станислав Курбацкий, биюләрне куючы Сергей Мандрик...

Вакыйгалар хәзерге заманны да, ерак үткәнне дә колачлый: сюжеттагы безнең көннәр Казанга нигез салыну легендалары белән үрелеп бара. Баш геройлар гына түгел, хор артистлары да бии анда! Эльмира Кәлимуллина, Филүс Каһиров, Алинә Шәрипҗанова, Артур Исламов, Айдар Сөләйманов, Айдар Нургаянов, Ирек Фәттахов кебек затлы җырчылар катнашу үзе үк күп нәрсә сөйли...

Мюзикл нигезенә Казан барлыкка килү турында шундый риваять салынган. Алтын казан бар икән, ләкин ул гади генә түгел, хикмәтле казан ди. Үләннәр белән дәвалаучы Сихәтбану аның серен ача: бары чиста куллы, яхшы күңелле, әхлаклы кешеләр кулында гына ул кайнап чыга ала! Һәм шул урында шәһәр төзергә җыеналар... Тик менә хан кулында ул... кайнамый ди. Чөнки аның кулы канга баткан. Финалда казанны аждаһа еланы урлап кача һәм Казансу төбенә яшерә. Сер, маҗаралар тулы мюзиклда шундый күренеш белән дә очрашасың: бүгенге заманның яшь кешеләре ниндидер тылсым көче тәэсирендә ерак үткәннәргә күчә. Урланган казанны эзли торгач, алар тагын бүгенге көнгә кайтып төшә. Ул казан чынлап та булганмы соң, дип аптырап та калалар, бер-берсеннән сорашалар. Үзләре үк җавабын да таба: әлбәттә, булган! Аны кире кайтарырга кирәк! Финалда: «Мин ышанам сиңа, Казан!» – дип җырлыйлар. Ә хәзер мюзиклда Аксылу ролен башкарган җырчы, Татарстанның атказанган артисты, Беренче каналның «Голос» проекты финалында җиңүче Эльмира Кәлимуллина белән сөйләшәбез, «Алтын Казан» премьерасы авторларының фикерләрен тәкъдим итәбез.

«Алтын Казан» мюзиклы синең өчен нәрсә ул, Эльмира?

– Соклануымны яшерә алмыйм, миндә хисләр өермәсе!.. Артист буларак, минем өчен бу зур уңыш! Талантымны, нәрсәгә сәләтле булуымны күрсәтә алу, камилләшү мөмкинлеге. Искитмәле команда белән эшләү тәҗрибәсе – режиссерлар, музыкантлар, хореографлар, костюмерлар, биючеләр, минем коллега-дусларым... Сүз дә юк, команда белән эшләр гөрләп бара. Һәркем үз урынында, проектка катнашы булган һәр кеше аны ярата, ул һәркайсыбызга кадерле. Һәркемнең күзләре яна, барыбыз да дулкынланабыз. Берәү дә битараф түгел. Аларның һәркайсы проектка энергия өсти, һәм әсәрнең кабатланмас формасы барлыкка килә. Һәм әлбәттә, Эльмир Низамовның гаҗәеп музыкасына эшләү – чиксез зур бәхет. Миңа калса, «Алтын Казан» – зур форматтагы иң якты музыкаль әсәрләрнең берсе. Һәм ул, һичшиксез, Опера театры сәхнәсендә яңгырарга тиеш иде. Әлеге зур эшнең инде финалына якынлашабыз. Мин күп әйберләргә өйрәнәм, көн дә репетициягә ашкынып барам. Авыр, катлаулы мизгелләр дә була, һәр эшнең үз нечкәлекләре бар, әлбәттә. Әмма һәр мизгелнең тәмен тоеп калырга тырышам.

Мюзикл турында башкаларга, тамашаны күрмәгән кешеләргәниләр сөйләр идең?

– Беренчедән, бу гаҗәеп әсәр дияр идем – затлы музыка, мавыктыргыч эчтәлекле матур әкият. Спектакльне карамыйча, аны тыңлап кына утырсаң да, ул сине искитмәле әкият дөньясына алып кереп китәчәк. Ул әкияттә гади кешеләр, тик могҗизага да урын бар, ә могҗизаны кешеләр үзләре тудыра. Мин әлеге әсәрне татар музыка сәнгате өчен, алай гына да түгел, гомумән, музыка дөньясы өчен зур вакыйга дип саныйм. Мондый дәрәҗәдәге әсәрләр музыка өлкәсендә иң югары бүләкләргә лаек. Яшь композитор халык шагыйре белән бергәләп шундый әсәр тудырды. Ә без аны халыкка җиткерәбез: «Алтын Казан» мюзиклы аша татар моңының иң матур үрнәкләрен тәкъдим итәбез, тамашачыда зәвык тәрбиялибез. «Алтын Казан» – ул оркестр белән театр сәхнәсендә уйналучы, зур команда катнашындагы тулы канлы беренче мюзикл. Әлбәттә, музыкаль спектакльләр шактый, тик мондый мюзикл бездә әле беренче тапкыр.

Эльмир Низамов белән иҗади дуслыгыгыз кайчан, ничек башланды?

– Мин Эльмир белән якыннан 2011 елда консерваториядә таныштым. Ул композиторлар факультетын тәмамлый иде. Ә «Алтын Казан» – аның диплом эше булды. Шул вакыттан башлап, музыка безне бәйләде. Бергә эшли башладык. Шундый талантлы, амбицияле дустым булуы белән горурланам. Аңа һәрвакыт таянырга була.



Ренат ХАРИС, Татарстанның халык шагыйре

«Бөек шәһәрләр үзләренең барлыкка килүләре турында риваятьләр тудыралар. Мондый бәхет безнең Казан каласы өлешенә дә тигән. Ә риваятьләр тора-бара повестьларга, романнарга, шигырьләргә, поэмаларга, музыка, театр, сынлы сәнгать әсәрләренә әвереләләр.

Мин һәрвакыт Казан турында зур, монументаль әсәр язу турында хыялландым. Мирсәет Яруллин белән бергә язган «Кеше» ораториясе зур уңыш казанганнан соң, 1976 елда миңа композитор Бату Мөлеков та оратория язарга тәкъдим итте. Мин аңа Казан риваятен тәкъдим иттем, ул аны хуплады. «Казан» (1977) ораториясенең икенче кисәге «Легенда» дип атала, һәм анда бер чибәр кызның елгага алтын казанын төшереп җибәрүе, аны берничә ел эзләү дәверендә елга ярында агач йортлар төзелүе, аннары таш биналар калкуы, шулай итеп безнең Казаныбыз барлыкка килүе бәян ителә.

2009 елда Казан консерваториясе студенты Эльмир Низамов һәм аның профессоры яшь композиторның диплом эше итеп опера язарга уйлауларын сөйләделәр. Мин яңадан Казан турындагы әлеге риваятьне искә төшердем һәм, аны Сазаган (аждаһа) риваяте белән берләштереп, либретто яздым. 2011 елда Эльмир Низамов «Алтын Казан» дигән опера белән шәп итеп консерваторияне тәмамлады. Опера иҗат итеп консерватория тәмамлау – дөнья музыка сәнгате тарихында сирәк очрый торган хәл. Бу әсәр, асылда мөкәммәл булса да, зур сәхнәләр өчен түгел иде әле. Ләкин аның күп арияләре әле дә күренекле җырчыларыбыз репертуарын бизәп тора.

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов безгә шушы әсәр нигезендә тулы күләмле мюзикл куярга тәкъдим иткәч, мин либреттоны шактый үзгәрттем. Әсәрнең нигезен, асылын саклаган хәлдә, явыз Сазаганны (Зилантны) шәфкатьле, көчле, гакыйль – Казанны яклаучы-саклаучы, аның гербына лаеклы затка әверелдердем. Моңа карап, әсәрнең әхлакый, эстетик, философик мәгънәләре дә үзгәрде. «Алтын Казан» либреттосын язганда мин кешенең могҗизага тиң мөмкинлекләре, якты өметебез, туган җирнең тылсымы, ата-бабаларыбыздан килгән традицияләрнең изгелеге һәм, әлбәттә, мәхәббәтнең бөек көченә ышаныч турында уйландым.

Мин сөекле Казанымның музыкаль визит карточкасы турында уйладым.»



Михаил ПАНДЖАВИДЗЕ,
куючы-режиссер

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры белән 15 еллап хезмәттәшлек итәм инде. Мин ул чакта әле Мәскәүдә, Зур театрда эшли идем. Мине Казанга чакырып алдылар. «Принцесса Турандот», «Мадам Баттерфляй», «Шагыйрь мәхәббәте», «Җәлил» опералары куелды. Һәм шуннан бирле Казанга карата аерым бер җылылык яши миндә... Театр, Казан, артистлар – барысын да яраттым! Мин биредәге иҗатташ дусларыма рәхмәтле. Алар минем өчен барысын да эшләде.

«Алтын Казан»ны куярга мине шагыйрь Ренат Харис чакырды. Без аның белән бергә «Шагыйрь мәхәббәте»н сәхнәгә куйган идек инде... Миңа кызык тоелды. Яшь композитор Эльмир Низамовны да белә идем инде. Шуңа күрә бу тәкъдимне шатланып кабул иттем. Эш барышында яңа идеяләр, яңа фикерләр туа торды. Ә «Алтын Казан»ны опера-балет театры сәхнәсендә уйнау тәкъдимен инде театр җитәкчелегенә мин җиткердем. Төрле яклап уйлап, тикшереп караганнан соң бу теләк уңай хәл ителде.

Эльмир Низамов бик тә үзенчәлекле мюзикл тудырган. Ул аны рок-опера дип атаса да, жанры башка аның – чып-чын классик бродвей мюзиклы! Эндрю Уэбберның «Призрак Оперы» мюзиклын хәтерләтә хәтта! Чып-чын гүзәллек үрнәге! «Алтын Казан» мюзиклын куяр өчен дә бөтен иҗат процессын заманча технологияләр белән баетырга кирәк. Хор, оркестр, бию театры, декорацияләр... «Алтын Казан»да уйнаган артистлар – чын профессионаллар! Искиткеч талантлы труппа! Алардан көчле энергетика, иҗат дәрте ташып тора.

Постановканы әзерләгәндә иң кыены пандемия ситуациясе булды дисәм дә, ялгышмам. Ул бөтен нәрсәгә комачаулады! Ә калганнары күңелле мәшәкатьләр генә иде. Алны-ялны белмичә, яратып, тәм табып эшләдек без. Татар мюзиклын куючы режиссер буларак, мин үземне татар сәнгатенә күпмедер дәрәҗәдә өлеш керткән кеше дип исәплим. Хәзер инде үзем турында: «Мин Татарстан Республикасыныкы да», – дип әйтәсем килә.

Ә премьера уңышлы узар, тәэсирләр онытылмаслык булыр дип өметләнәм. Спектакльгә бәхетле сәхнә язмышы телим. Ул яшьләр арасында популяр булыр, Казан тамашачысы яратып кабул итәр аны.

Тормышта да үзеңне Аксылу итеп хис итәргә туры киләме сиңа, Эльмира?

– Безнең һәркайсыбызда бераз гына Аксылу яши. Чөнки Аксылу образы ул, беренче чиратта, эзләнүчән, тормышны тоеп яшәүче гадел кыз. Үз-үзен эзләү юлында безнең һәркайсыбыз язмыш сынауларын үтә. Аксылу да шундый. Мюзикл дәвамында аның ничек үзгәрүен күрәбез, эчке кичерешләрен күзәтәбез. Кешенең көнкүреш теләкләре, үз-үзен саклау инстинктыннан кала, җирдә бөек мәхәббәт хисе бар, мәхәббәт хакына үзеңне корбан итү бар. Тормыш ул – спираль сыман цикл: аны кайсы ноктадан башласаң, шул ноктага кире әйләнеп кайтасың, һәм бу даими кабатлана. Миңа калса, Аксылуда назлылык һәм кырыслык та, йомшаклык һәм ныклык та – табигатьнең барлык чагылышлары да бар. Ул – минем өчен бик кызыклы җыелма образ.

Сиңа, мөгаен, үзара Аксылу дип дәшәләрдер әле. Гомумән, сез сәхнә артында ничек аралашасыз?

– Режиссер миңа гел Аксылу гына дип дәшә, чөнки безнең труппада Эльвира, Эльмира сыман охшаш исемнәр күп. Шуңа мин репетицияләрдә һәрвакыт Аксылу. Аксылу – хәзер минем икенче исемем.

Репетицияләр турында да сөйлә әле! Нәрсә ошый, нәрсә ошамый?

– Эш башланган гына вакытта миңа репетициядә кайсы вакытта чыгарга тиешлегемне белмәү бик авыр иде. Мин ирекктә күнеккән кеше. Тик театрның үз кануннары бар: әгәр 10 нан 15.00 сәгатькә кадәр репетицияләр икән, сәхнәгә чыгасыңмы-юкмы, син барыбер шунда утырырга тиеш. Башта минем өчен бу шактый кыен булды. Килгәнмен икән, мин 100 процентка эшләргә тиеш дип саный идем. Аннары инде репетиция вакытында үзем сәхнәдә булмасам да, читтән карап торсам да, барыбер процесста катнашуымны аңлый башладым. Син шул атмосферада, эш барышында күп әйберләрне аңлыйсың, нәтиҗәләр ясыйсың. Мин – иң бәхетле артист. Чөнки монда гаҗәеп музыка, хыялдагы эш. Шушы мизгелләрне озаккарак сузасы килә.

Премьерада нинди киемнәрдә буласың?

– Бөтен серләрне дә ачып бетерәсем килми. Шуны гына әйтәм: спектакльдә вакыт икегә бүленә – бүгенге заман һәм тарихи чорга. Шуның белән бәйле костюм образлары гадәти көндәлек киемнәрдән җәнлек тиресеннән тегелгәннәренә кадәр алышына.

Элегрәк син Сихәтбануны уйнаган идең, хәзер – Аксылу. Кайсы күңелеңә якынрак? Кайсы рольдә тулырак ачыласың? Ни өчен?

– Аксылу минем өчен бик кызыклы һәм якын, мюзикл барышында әлеге персонаж шактый үзгәрешләр кичерә. Аны уйнаганда төрле алымнар кулланыр-

га була, иҗади яктан ачылырга мөмкинлекләр зур. Бүгенге көндә, минем яшьтә нәкъ менә Аксылуны уйнау ошый. Тик күпмедер вакыттан соң бик рәхәтләнеп Сихәтбануны да уйнар идем. Һәр рольнең үз вакыты бар. Ә хәзергә Аксылу роленнән ләззәтләнеп каласым килә.

– Мюзиклны әзерләгәндә нинди кызык яки кызганыч хәлләргә калырга туры килде? Эчке кухняны ача аласыңмы?

– 2014 елдагы Эльмира Кәлимуллина белән хәзерге артист Эльмира Кәлимуллина – икесе ике кеше. Хәзер мин ролемне бөтен җанымны биреп эшлим. Бәлки, сорауларым, үзем килешмәгән урыннардагы шикләнүләрем белән иҗат төркемен дә, режиссерны да аптыратып бетергәнмендер. Кызып киткән вакытлар да булды. Миңа да кызып җавап кайтардылар. Тик бу эш процессы, тере организм. Эш барышында бар нәрсә белән дә килешсәң, бик сәер булыр иде. Төрле хәлләр килеп чыкты, тик ахыр чиктә бар да җайланды. Миннән бик күп физик көч таләп ителә – чөнки миндә хореографик яктан актив роль. Башкаларның хәрәкәтләр ул кадәр күп түгел, ә Аксылуның һәр чыгышы саен – хореография. Ике сәгать дәвамында мин гел хәрәкәттә. Кайвакыт өйгә тәмам хәлдән таеп кайтам, аяк авыртудан, башның аруыннан елаган чаклар да булды. Тик никадәр генә авыр булмасын, мин бик канәгать, әлеге могҗизада катнашуым белән горурланам!

Мюзиклда тагын кемнәр катнаша?

– Битимерне Филүс Каһиров уйный, Ханзадә – Артур Исламов, Нукәр – Айдар Сөләйманов, Сихәтбану – Алинә Шәрипҗанова, Тарих – Айдар Нургаянов һәм Ирек Фәттахов. 2014 елда алар беренче составта да катнаштылар. Искиткеч талантлы музыкантлар, артистлар. Алар белән эшләве рәхәт, җиңел. Бу – хыялдагы команда.

Элекке куелыш белән хәзергесе нык аерыламы?

– Әлбәттә, аерыла. Беренче куелыш бер сәгать тә ун минут барса, хәзер ике сәгать тә унбиш минутка сузыла. Тагын бер бүлек өстәлде. Вакыйгалар тулыланды. Матур музыка артты. Әлбәттә, «Алтын Казан»ның масштабы сокландыра. 2014 елда ул алмаз булса, хәзер бриллиантка әверелде.

Мюзиклда нинди җырлар яңгырый? Концертларда да башкарасыңмы аларны?

– Һәр персонажның үз җырлары, арияләре бар, алар бик матур. Мин үз репертуарымда әлеге мюзиклдан еш кына өч җырны башкарам: «Аксылу» җыры, Сихәтбану ариясе – «Рәхмәт сиңа» җыры һәм иң танылган җыр – «Мин ышанам сиңа, серле Казан». Минемчә, ул Казанның яшерен гимны. Аны тамашачылар да шулай кабул итә.

Эльмира ЗАКИРОВА



Видеокотлау



Эльмир НИЗАМОВ,
композитор

Музыкаль театр жанрлары – опера, балет, мюзикл – барлык чорларда да композиторларны һәрчак үзенә җәлеп итте: сәнгать синтезы театрда шундый магик көчкә ия инде ул, аның каршында туктап калу мөмкин түгел. Әле дә хәтеремдә: 2006 елда Казанга укырга килгәч, беренче тапкыр опера-балет театрына бардым, һәм опера мине тәмам сихерләде. Консерваторияне, һичшиксез, опера белән тәмамлау хыялы белән яна башладым.

Сюжет эзләү ярыйсы гына озакка сузылды. Шагыйрь Ренат Харис белән нәкъ менә туган көнемдә – 2009 елның 24 декабрендә күрешүем символик мәгънәгә ия булды. Казан шәһәренең барлыкка килүе турындагы риваятькә нигезләнеп, Ренат Харис тылсымлы казан турында кызыклы бер тарих сөйләде, аны диплом темасы итеп тәкъдим итте. 2010 ел дәвамында «Алтын Казан» турында диплом эше яздым, ә 2011 елның язында спектакльне консерваториянең опера студиясе куелышында тамашачыга тәкъдим иттек.

2014 елның 30 августында, Республика көне уңаеннан, спектакль Казан гаилә үзәге мәйданында open-air форматында яңа, кыскартылган версиядә киң катлау тамашачыга тәкъдим ителде. Абруйлы, тәҗрибәле, таләпчән режиссер Михаил Панджавидзе белән эшләү спектакльгә яңа сулыш өрде, аның яңа перспективалары ачылды. Җырлар да, биюләр дә, опера да, театр да, шоу да бар анда. Мюзикл – бөтенесен үзенә җыя торган универсаль жанр ул. Ул рок-опера да, этно-мюзикл да була ала, классиканы да үзенә кертә. Анда минем рок кына түгел, төрле музыкаль стильләр, жанрлар, юнәлешләр ишетелә. Ә финалда яңгыраган «Мин ышанам сиңа, Казан!» җырын «Алтын Казан»ның визит карточкасы дияргә дә була. Спектакль белән Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры җитәкчелеге дә кызыксынды. Узган ел мин спектакльнең яңа редакциясен эшли башладым – ул бишенче «Үзгәреш җиле» фестивале кысаларында махсус театрда уйналыр өчен яңартылды. Яңа җырлар, арияләр барлыкка килде, икенче акт язылды. Минем өчен ул чынлыкта премьера инде.

«Алтын Казан» – минем өчен бик тә үзенчәлекле спектакль: туган телебездә бара, безнең тарихыбызга, риваятькә нигезләнгән. Минем татар телендә мондый әсәр күргәнем юк иде әле! Бу иҗатым миңа музыкаль театр дөньясын ачты, мине опера һәм мюзикл жанрына гашыйк итте. Бу спектакль – Казан шәһәренә яратуымны аңлату ул. Мин бу шәһәрдә тумасам да, композитор буларак танылдым, шәхес буларак формалаштым. Казан ул шундый шәһәр – безнең мюзикл сюжетындагы кебек, халык энергиясеннән кайнап, ургып тора! Анда һәрчак могҗизаларга урын бар! Бик күп талантлы кешеләр тырышлыгы белән иҗат ителгән мюзикл тамашачы күңеленә барып җитәр, сәхнәдә озак яшәр дип өметләнәм мин.



Өйгә кергән кышның айлы киче... Җидегән йолдыз тигән түбәбезгә... Шундый хозур, шундый зәңгәр бу кич!.. Күз алдында – кышкы матур сурәт, рәссам картинасы! Шагыйрәләр Лена Шагыйрьҗан, Нурия Измайлова, Фирүзә Җамалетдинова безне кышкы әкият дөньясына алып кереп китә шулай...

АК БИШЕКТӘ ҖИҺАН...

Лена ШАГЫЙРЬҖАН

Кышкы кунак

Шундый матур тышта ай яктысы –
фонарьларың торсын бер кырда.
Их, шундый кичтә, тының
кысыла-кысыла,
гыйшык хаты иде укырга!..

Өй түрендә туңып басып калган,
яфракларын сагынып, өрәңге.
Өйдә – җылы, өйдә – әти-әни,
мичтә – тәгәрәткән бәрәңге.

Ә мин – кунак,
иске бер бишмәтне
җиңел генә иңгә салдым да,
«Айга карап керим әле» диеп,
чыгып бастым ишегалдына...

Җидегән йолдыз тигән түбәбезгә,
шундый якты булып күренә.
Түбәм күккә тигәнмени, мин дә,
кайткан саен, шуңа үреләм...

Адымнарымнымы саный-саный,
шыгыр-шыгыр килә айлы кар.
Ап-ак карга язсаң бетмәс микән
эчтәге бар борчу-кайгылар?!

Айны әйтәм, әллә тагын да ул
моңайганмы шунда, без киткәч?
...Ә каргышлар калсын әле карда,
агып китәр эреп, яз җиткәч.

Ай яктыларында качып кына
хатлар укый идек унбиштә...
Ишегалдым, күпме истәлекләр
ишелеп искә төште бу кичтә...

Шундый матур тышта, –
рәхмәт кышка!
Өйдә – җылы. Өйдә – балачак.
Ә йолдызлар баш очында мәңге
безгә һәйкәл булып яначак.

Тәрәзәдәге пейзаж

Тәрәз кысасында түгәрәк Ай,
Гүя затлы нәфис картинадай.
Өйгә кергән кышның айлы киче,
Катып калдым күреп, ләззәт кичеп...

Әкияти тылсым алды урап,
Күргәзмәгә килгән кебек торам:
Чын сәнгать ич –
килгән бөтен яктан,
Буяулары ничек тигез яткан!..

Сокланудан күз дә алмыйм Айдан,
Бу сурәткә калып тәмам хәйран.
Күрсәң икән син дә, туганаем,
Тас кадәрле булып тулган Аең...

Тәрәз өлгесенә сыеп кына,
Йолдызларын янга җыеп кына,
Елмаеп тик карап тора миңа
Аяз күктән, гүя оеп кына...

Ясап куйган мәллә даһи рәссам?
Сүзең җитмәс, шигырь итеп язсаң...
Җир йөзенә Нур-Йөз баккан бугай,
Бер Ходайның җисми дәвамыдай...

Ай күрдем лә, шөкер, аман белән,
Кальбем тулсын, Раббым,
иман белән...
Ай нурында юдым йөзләремне,
Ай күк балкып торсын диеп гелән...

Яңа ел дип котлау

Күптән инде шигырь язган да юк,
Яңа ел дип котлап...
Ялтыравык уенчык сүзләрне
Яудырадырыек потлап-потлап...
Яңа гасыр – тәүге дистәсенә
Атлап керү менә...
Чыршыларның ылыслары тулы
Энә, энә генә...
Очларыннан яшел моң кадала
Кемнәр йөрәгенә?..
Ах, уйласам, уелыплар китәм –
Уйламаган көн юк...
Ай, җәмәгать, гомер үтә икән –
Кемнәр бар да, кем юк...
Тәбрик итәм инде, Яңа ел дип,
Котлы була күрсен.
Адәм балалары җылы сүзләр белән
Юатсын бер-берсен!..
Менә шундый котлау юллыйм сезгә,
Шул бит ил йоласы.
Яңа елда килә бит ул һәрчак
Яхшылык кыласы...
Чын күңелемнән котлыйм,
Яңа ел дип,
Ипле була күрсен!
Һәрбер йортка, һәркем күкрәгенә,
Өметләнеп көткәненә күрә,
Бәхет килеп керсен.

Нурия ИЗМАЙЛОВА

Зәңгәр кар киче

Шундый хозур, шундый зәңгәр
бу кич!
Мин дә зәңгәр микән бу мәлдә?
Ак карлар да, җиргә төшкәч, түзми –
Әверелеп китә зәңгәргә.

Азмы миндә моңсу, ямьсез төсләр! –
Бер көнемдә генә мең төс бар.
Бар да чума йомшак зәңгәрлеккә –
Бар дөньямны күмә керсез кар.

Зәңгәр таулар булганмындыр инде –
Әкиятләр чынга ашканнар! –
Зәңгәр кошлар оча күзләремнән,
Зәңгәр гөлләр чыккан ак кардан...
Күңел тәрәзәм зәңгәр генә бугай –
Бүтәннәрен кошлар ватканнар.

Бер кичне

Мәрҗән-мәрҗән тезелеп,
Бизи карлар җирне.
Абау, күзем чагыла! –
Сукыр калам инде.
Карның сафлыгыннан,
И киңәя һава!
Агарган саен, җир
Иркенәя бара.
Кар йомшарткан назлап,
Ефәк иткән җилне.
Абау, бигрәк җиңел! –
Очып китәм инде!
Ак бишектә җиһан –
Гүя яңа туган...
Мин дә әле менә
Туып киләм сыман.
Дөнья белән бергә
Ап-аклана җаным,
Һәм киңәя йөрәк,
Җир киңәйгән саен.
Ах, йөрәгем! Ярылыр... –
Буп-буш киңлек анда!
Буш итмәгез җанны!
Күп кирәкми җанга:
Салыгыз ак эзләр –
Күңелем – иркен урам,
Елмайсачы берәү –
Хәзер гашыйк булам!
Ефәк җилдәй нәфис,
Кардай йомшак күңел.
Җырлагызчы бер җыр –
Түгелеп елар идем.
Теләгез ак теләк!
Эндәшегез көлеп! –
Туып кына киләм –
Шатланыгыз күреп!..

Җем-җем балкыр идем,
Бәхетле җир кебек.
Күңелем балкышына
Җир таң калыр иде.
«Тиңдәш таптым!» – диеп
И шатланыр иде!

* * *

Җилләр кая куса, шунда куна,
Кайда буш урын бар, шунда тула –
Илләре юк юлчы карларның.

Рәхәтләнешеп бер сөйләшмиләр,
Киңәшмиләр, теләк теләшмиләр –
Телләре юк мескен карларның.

Зыңлап көлми алар зәңгәр кичтә,
Үксеп еламыйлар, төннәр килсә –
Өн генәсе юк шул карларның.

Сузып җырлар иде, сагыш басса,
Кубыз уйнар иде, һич булмаса –
Көйгенәсе юк шул карларның.

Юктыр инде шаулы шатлыклары,
Юктыр инде моңлы зарлары –
Күңелләре юк шул карларның...

Рәхмәт, әнкәй! –
мине коткаргансың –
Синең кызың булып калганмын.
Нишләр идем, бер бөртеге булсам
Җансыз, телсез, илсез карларның?!

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА

Тышта буран

Тышта буран.
Җиргә ятып
Елый тәрәз төбемдә.
Тышта буран. Вәгъдәләрең
Югалгандыр бу төндә.

Тышта буран. Адашырсың,
Чыкма берүк юлларга.
...Көртләр ерып барырмын мин
Беркөн синле елларга.

Беркөн синле мизгелләрне
Эзләп буран эченнән,
Өшесәм дә әйтә алмам:
«Мин кышларны кичермәм!»

Җаным гүя бөтерелгән
Гади кар бөртегендә.
...Ап-ак буран хәтеремнең
Елый капка төбендә.

* * *

Бөртек карлар сеңде карашыма,
Быел кышлар суык.
...Яшәгән мәл иде энҗе кар күк
Өр-яңадан туып.
Саф сөюнең яктылыгын сөйләп
Яуды карлар, яуды.
Җаным тулы ялкын очкын чәчеп
Янды, янды, янды.
Ак карларның йөрәгенә басып
Атладык та үттек.
...Быел кыш та
шул сукмакка килдем,
Моңсу һәрбер бөртек.
Мин аларның ап-ак күңеленә
Кагылырга куркам.
Хәтта сине элеккечә итеп
Сагынырга куркам.

* * *

Ярсый-ярсый узып китте,
Тормады буран көтеп.
Уралган үз дөньясына,
Нәкъ минем төсле итеп.
Аклыкка күмелгән дөнья,
Ап-ак мин барыр урам.
...Минем хәлне аңлый алмый
Минем хәлдәге буран.

Вәгъдә

Энҗе карлар, диден, энҗе карлар,
Бүләк итим әле үзеңә!
Ак кышларда бик килешер алар
Кара пәлтә, алсу йөзеңә.

Сибелешеп төште ак энҗеләр,
Арабыздан буран йөреде.
Күкрәгемә алып кадыйм диеп
Үрелдең дә... карлар эреде...

Сөю сулышы

Боз пәрдә элеп куйгансың
Син минем тәрәзәмә.
Сөйгәнеңне күрмә, имеш,
Аңа кул да изәмә...

Күрәсем килә дөньяның
Бүген үк эчен-тышын.
Сөю сулышым пәрдәңне
Эретте бит, и кышым!

* * *

Декабрьдә җаным язга чыкты,
Кар өшерлек салкын ич тышта!
Шул карларга баскан көе дөрлим,
Әллә нәрсә булды бу кышта...





Бездә бүген – дебют! Гөлнур Сафиуллинаның дебюты! Ниһаять!.. Аның хикәяләр яза башлавын бик көткән идек без. Хәер, Гөлнурның журналист язмалары ук чын хикәя итеп кабул ителә: йә елмаеп, йә күз яшьләрен тыярга тырышып укыйсың... Ә геройлары үзенә охшаган: тыйнак, акыллы, сизгер күңелле, серле... Кечкенә генә бер сүзе, карашы, хәрәкәте белән дөньяларны үзгәртә, гап-гади тормышны ямьгә төрә белгән... Менә шулай! Хикәяләрендә – фәлсәфә, хисләр, сизгер хатын-кыз йөрәге, тагын әллә ниләр – кыскасы, өр-яңа халәт!



Гөлнур САФИУЛЛИНА

ГОМЕРНЕҢ ИКЕ ЯРЫ

(хикәя)

– Бигрәк матурлар! Кемнән?

Чәчәкләрне китергән курьер егет, аларны миңа сузды да, ашыгып китәргә дә борылды. «Анда язылган», – дигән сүзләрне дә миңа инде арты белән борылгач кына әйтте. Хатын-кызның йөзенә кунган сөенечкә ничек шулай битараф калырга мөмкин икән? Мин үзем гел бәхетне башкаларга да йога дип уйлыйм. Бөтен кешегә дә йокмый бугай. Әнә бит бер кылы да селкенмәде.

Хәер, аңа юкка бәйләнәм бугай. Сәбәп үземдәдер. Бу чәчәкләр мине берничек тә дөньяның иң бәхетле кешесе итмәве читтән яхшырак та күренәдер. Беләм бит мин кулымдагы ак розаларның кемнән икәнен, сорап тормасам да, бик яхшы беләм.

– Берәү, икәү, өчәү... Унбер!

Әйе, унбер. Санамасам да була иде. Нәкъ былтыргы кебек. Өченче елгы кебек. Аннан алдагы елгы кебек... Ә нәрсә язды икән бу юлы? «Үзебезнең урында көтәм. Иртәгә көндезге сәгать бердә». Кыска-кыска шушы ике җөмләсе дә үзгәрмәдеме икән? Юктыр... Ялгышмадым дисәм, быел: «Бик көтәм!» – дип тә өстәгән. Елмаеп куйдым. Сабырлыгы бетеп барган кеше әйткәнгә охшаган монысы. «Мин сине көтүдән беркайчан туктамаячакмын! Моңа өметләнмә!» – дигән иде бит берәүләр! Көтүнең нәрсә икәнен белми иде шул әле ул чакта Рәис...

Кабинетымның ишеген инде бикләп чыккан идем – кире кереп йөрисе килмәде. Розалар – искиткеч нәзберек гөлләр, ишек-тәрәзәсе ябык бүлмәдә дүшәмбегә кадәр алар, һичшиксез, сулачак. Башка елларда гел эшемдә калдыра идем, быел менә минем белән өйгә кайтсыннар әле...

...Дус кызларына адым саен: «Миңа кара чәчлеләр генә ошый», – дип сөйләп торып, үзе көннәрдән бер көнне сары чәчле егеткә гашыйк булып куйган кеше тагын бармы икән? Сизми дә калдым шул... Яңа ел алды иде. Башлангыч классларның Яңа ел бәйрәменә мине Кар кызы итеп билгеләделәр. «Булдыра алмыйм, гомер кеше алдында җырлаганым, биегәнем юк, миннән нинди Кар кызы чыксын?!» – дип карадым, ишетергә дә теләмәделәр. «Сүзләре күп түгел, ятларга өлгерәсең. Кечкенәләрне җитәкләп, чыршы тирәсеннән генә әйләнә алырсың әле», – дип авызымны да ачырмадылар. Соңыннан гына белдем: «Лилияне Кар кызы итеп куйсагыз гына, Кыш бабай булырга ризалашам», – дип Рәис әйткән икән. Кар кызына караганда, Кыш бабайны табу авыррак шул...

Искә дә төшерәсем килми ул чыршы бәйрәмен. Берничә куплет шигырь белән генә бала-чагага тамаша ясап буламыни?! Аларны түгәрәккә җыеп, чыршы тирәсеннән җырлый-җырлый әйләндерү өчен дә талант кирәк икән шул. Ә миндә ул юк! Ярый әле укытучылар үзләре булышты. Югыйсә Кыш бабайның барлыгына әле чынлап торып ышанган бәләкәчләрне ташлап, залдан

чыгып китәр дәрәҗәгә җиткән идем. Бәйрәмнәренең ямен җибәрдем, дип, соңыннан еладым да еладым. Күз яшемне тыеп кына булмый. Кыш бабай костюмын салырга өлгергән Рәис бер минутка да янымнан китмәде. Нәрсәгә елаганымны аңламаса да, ул барыбер үзен гаепле саный иде бугай...

Мәктәптән ул көнне без бергә чыктык. Рәис бертуктамый сөйләде дә сөйләде. Минем кәефемне күтәрергә тырышкандыр инде. Капка төбенә кайтып җиткәнче инде елмая гына түгел, көлә үк башлаган идем. Безгә бер йорт кала, яныбыздан аның ике классташ кызы узып китте.

– Менә тотылдың! Иртәгә бөтенесенә дә, Рәис Лилияне озатты, дип сөйләячәкләр инде, – дим көлеп.

Ул шундый җитдиләнде.

– Сөйләсеннәр! Ә мин сөйләүләрен телим! Мин бит, чынлап та, сине озатып кайттым. Шулай түгелмени?

Янәшә атлап барган җирдән ул каршыма чыгып басты һәм җавап көтеп миңа карады.

– Белмим... Озаттың бугай...

Гомергә истә калды ул көн: мин беренче һәм соңгы тапкыр Кар кызы булдым һәм... аны очраттым. Гомерлек мәхәббәтемне... Беренче мәхәббәтләрен гомерлек дип уйламаган кешене белмим әле мин.

Мәктәптә күзләр гел бер-беребезне эзләсә дә, тәнәфесләрдә туктап сөйләшеп тормыйбыз. Кая ул?! Минем әни укытучы – аның күзенә чалынсак, шимбә көнне дә урамга чыгармаячак. Бик кырыс ул безнең. «Институт тәмамлап, диплом алмыйча кияүгә чыгу турында уйламагыз да», – дип, сеңлем белән икебезгә тукып кына тора. Мине ул V курста укыганда тапкан. Бик елак булганмын. «Йокы, ял күрмәдем... Имтиханнарны ничек тапшырганны, дипломны ничек яклаганны үзем генә беләм. Акыллы кеше башта укып бетерә, аннары гына кияүгә чыга, бала таба», – ди ул. «Әни, безгә ул хакта уйларга иртә бит әле», – диюебезне ишетми дә.

Рәиснең дә вакыты тыгыз: чыгарылыш имтиханнарына әзерләнә. Хыяллары зурдан – укырга Ленинградка ук китәргә җыена. «Космосны өйрәнәчәкмен», – ди. Икебез генә калган саен: «Анда бит югары уку йортлары күп. Сайла берәрсен. Бер шәһәрдә укырбыз», – ди. «Сине шулай озак күрмичә түзә алмаячакмын бит», – дип тә өсти. Аннан аерылу турында үзем уйларга да куркам.

– Әйдә, бер-беребезгә хат яза башлыйбыз! – диде ул миңа бер шимбә кичендә клубтан кайтканда.

– Һәм аны почта аша җибәрәбезме?

– Юк, мәктәптә бирешәбез!

– Кайдан уйлап таптың инде моны? – дим көлеп.

– Сиңа сөйлисе сүзләрем шундый күп була минем. Күрешкәч кенә барысын да сөйләп бетерә алмыйм. Искә төшкән саен язып барачакмын. Син дә шулай ит...

Хатлар безнең зур серебез иде. Мин алар хакында хәтта иң якын дус кызыма да белгертмәдем. Җай табып, кулыма Рәис тоттырып киткән хатны мәктәптә укып булмый: күңелеңне җылытып ничә дәрес буе ул сумкаңда йөри. Тизрәк өйгә кайтуны, ялгызың гына калуны көтәсең... Хатларында ул миңа бөтенләй яңа яклары белән ачылды. Мин дә аңа шулай бугай.

Чыгарылыш кичәсенең икенче көнендә үк Рәис Ленинградка китеп барды.

Бәйрәмнең яртысыннан качып, яныма килде. Таңны да классташлары белән түгел, минем белән каршылады.

Ул кичне күз яшьләремне берничек тә тыя алмадым.

Син бер дә борчылма, – дип юатты ул мине. – Без бит аерылмыйбыз, уйларда гел бергә булачакбыз... Сагынган саен, утыр да миңа хат яз. Адресымны белү белән хәбәр итәрмен, барысын бергә салырсың...

Аннан беренче хат килгәнче узган бер ай кадәр озын айның аңа кадәр дә булганы булмады, аннан соң да...

Мин бер караганда: «Керәлмичә кире борылып кайтса ярар иде», – дип телим. Аннан Рәиснең моны ничек авыр кичерәчәген күз алдыма китерәм дә: «Имтиханнарын уңышлы тапшырсын иде!» – дип теләргә керешәм. Керсен иде шул институтка – ул бит аның иң зур хыялы! Ә мин... мин сагынуга түзәрмен!

Түзәрмен дидем дә... Сагынуның шундый авыр икәнен күз алдыма да китермәгәнмен икән. Күземне ачуга иң беренче итеп аны уйлыйм. Йокыга киткәндә дә уемда ул була. Тавышын сагынам, көлүләрен, елмаеп миңа карап торуын, кочагына бөтереп алуын, чәчемә кагылуын...

Аз гына вакытым булдымы, аңа хат язарга утырам. Кайсын бер утыруда язып куям, кайсысын, бүленепбүленеп, өчәр көн язам. Минем аңа бөтен нәрсәне дә сөйлисем килә! Кечкенә генә яңалыктан да зур вакыйга ясыйм. Язарга яратам икән мин...

Аның беренче хаты килгән көнне үк, инде ябыштырып ук куйган конвертларыма адресны гына яздым да, барысын берьюлы почта әрҗәсенә салып кайттым.

Кышкы каникулга кайтканчы, хат саен аларны алгач ничек сөенүе турында язды ул миңа. Хат саен бер тапкыр булса да шуны искә төшерде. Хәер, каникулга кайткач та, исәнләшүгә, тагын шул хатларга күчте.

– Син ул хатлар белән мине ничек шатландырганыңны, бәхетле иткәнеңне үзең дә белмисең! Безнекеләр әле һаман да сөйли аны... Күз алдыңа китерәсеңме, ул көнне хатлар шактый килгән иде. Берәм-берәм тарата башладылар. Бөтенесенә диярлек килгән. Минем генә исемне атамадылар. Шундый кәефем төште инде... Сине үлеп сагынган идем... «Бүген дә хаты килмәде», – дип уйлыйм. Старостаның кулында бер кочак конверт калганына игътибар да итмим. «Бетте, башка юк», – диде бит. «Ничек бетсен, ә болары хат түгелмени? Алары кемгә?» – дип сорады кайсыдыр. «Болары... Болары барысы да Рәискә! – диде ул. – Бөтенесе дә бер кул белән язылган. Кызлар кулына охшаган... Бигрәк ярата бугай!» Хатларны берәм-берәм миңа бирә башлады. Ул бирә, башкалар санап тора: «Бер! Ике! Өч!.. Унбер!!!» Синең турында бөтен группадашларым белә хәзер! Ярату менә ничек була, диләр. Фотосын күрсәт дип аптыратып бетерделәр...

Шул кайтуында: «Унбер саны – безнең талисманыбыз була, яме, – диде ул. – Безне гомер буе озатачак ул... Туебыз да айның унберенче көнендә булыр».

– Ә унбере ул айда атна уртасына туры килсә нишләрбез? – дип сүзне шаяртуга бормакчы булам. Әйтерсең, иртәгә никахлашырга җыена кайберәүләр.



– Килсен! Барыбер шул көнне ясыйбыз! – дип, үз сүзендә нык тора ул.

– Ярый соң алайса, – дип килешәм аның белән.

– Бәлки, син әле безнең кызыбызны да унбере көнне табарсың... Аннан улыбызны... Шулай туры китереп буламы икән?

Оялып, йөземне аның күкрәгенә яшерәм.

Укырга мин ул теләгәнчә Ленинградка ук китә алмадым, Казанга гына кердем. Әнидән узып булмады...

Сагыну тулы еллар уза торды. Бөтен нәрсәгә дә ияләшеп була, юк, сагынуга күнеп булмый икән. Каникулга ул кайтыр көннәр җиткәндә сагыну бигрәк тә көчәя – сулап булмый башлый. Минем үземә шулай тоела иде. Рәис кайтып мине кочаклап алгач кына сулый башлыйм кебек... Ә аннан, китәр вакыты җиткәч, ул янымда килеш үк сагынырга керешәм үзен... Әле аңа кагылып, әле җылысын тоеп булганда ук.

Өченче курста укып йөргән чагым. Яңа ел бәйрәменә кайткач, авырып киттем. Температурам төшми дә төшми. Район больницасына күренергә дип кенә барган идем, мине салып ук куйдылар.

– Үпкәңдә кара тап бар, Лилия!..

Бу хәбәрне миңа Рәиснең әнисе җиткерде. Поликлиникада педиатр булып эшләсә дә, һәр көнне кереп, хәлемне белеп чыга иде ул. Безнең Рәис белән аралашуыбызны күптән белә, мине якын да итә кебек иде.

– Сиңа бик озак дәваланырга туры киләчәк... Бүген аерым палатага күчерерләр.

Кәефе юк икәнлеге йөзенә чыккан, шуңа күрә мин аңа артык сораулар бирмәдем. Дөресрәге, берне дә бирмәдем. Үземә нинди диагноз куйганнарын әле аңларга өлгермәгән дә идем бугай.

Палатадан чыгып киткәндә генә, борылып, тагын бер яңалыгын җиткерде:

– Җомга көнне Рәис кайта... Телеграммасы килде.

Җомга көнне күземне ачуга аны көтә башладым. Төш вакыты да җитте, көн кичкә дә авышты, караңгы да төште. Ул һаман юк! Нидер булган да кайта алмаган, кайтса, түзмәс, яныма йөгереп килер иде, дим.

Шәфкать туташы градусниклар таратып чыккач кына, күрше палатада ятучы бер апа, ишекне ачып:

– Лилия, синең янга бер егет килгән анда, – диде.

Ул! Кайткан! Исән-сау!

Очтым гына!

Соңыннан күпме генә искә төшерергә теләсәм дә, хәтерли алмадым: аның кочагына барып сыендыммы, ә ул мине кочаклап алдымы, юкмы, белмим. Күрәсең, юктыр... Көчле куллары белән сагынып кочагына кысуын онытмас идем бит. Кочакласа да, димәк, каты кысмаган.

Градусник куйган килеш чабып чыкканмын икән – ул идәнгә төшеп ватылды.

Без әле бер сүз дә алышырга өлгермәгән идек. Идән юучы юан гына апа, мине ачулана-ачулана, аның ватыкларын җыйды.

Аның: «Табибка әйтәм!» – диюенә әллә ни исем китмәде, мине башка борчу биләп алган иде инде: Рәискә нидер булган! Ул үзгәргән! Башта бу үзгәрешнең нидә икәнен аңламый тордым. Тышкы кыяфәте дисәм... Юк, ул гел шундый – төз буйлы, чибәр, чәчләре һәрвакыттагыча кыска итеп алынган. Күзләре... Сәбәп күзләрдә икән бит! Ул миңа туры карамый! Гел читкә карап сөйли!

Палатага кергәч, мендәремә капланып елыдым.

Нәрсәгә икәнен белмәсәм дә, еладым да еладым.

Каникулы тәмамланганчы ул яныма тагын ике тапкыр гына килде. Һәм... бер тапкыр да мине үпмәде! Читтән карап торганда, без инде ят кешеләр кебек күренгәнбездер: баскан килеш кенә, 1–1,5 метр ара калдырып, сөйләшеп торабыз... Ул үзе куйган шул чикне узып, миңа якынаймады. Минем дә аны бозарга йөрәгем җитмәде...

Рәис килеп киткән саен күзләрем кызаруга игътибар иткән күрше палатадагы теге апа беркөн яныма утырды:

– Нигә елыйсың син, Лилия? – ди. – Егетең өченме?

– Аның башка кешесе бар бугай... – дим. Күзләремә шундук мөлдерәп яшь тулды.

– Юк аның беркеме дә... Сиңа куйган диагноз аркасында бу. Үпкә чире дип уйлыйлар бит. Безнең палатадагылар әнисенең бер врач белән сөйләшкәнен ишетеп калган. «Рәис бик тыңларга теләми теләвен, әмма улымны аның белән йөртмәячәкмен. Нәселдән нәселгә күчә торган чир бит», – дигән. Казанга китеп тикшеренеп кара әле син. Мондагыларның аппаратлары да дөрес күрсәтми, диләр. Юктыр мондый авырту синдә, кайдан килсен ди ул шундый япь-яшь, янып торган кызга?

Йөрәгемә әйтерсең мең энә кададылар...

Киткәч, ул миңа бер тапкыр гына хат язды. Шундый салкын иде ул...

Җавап бирмәдем.

Казан табибларына күренүемне, аларның миндә бернинди чир тапмавын, «Районныкылар булмаган нәрсәне бар дип күргән», – дип әйтүләре турында бер язарга да уйлаган идем, аннан тукталдым.

Аңардан башка хатлар килмәде.

Яратуымны онытырга, сагынуларымны ниләр беләндер басарга кирәк иде. Мин ул чакта яшәмәдем дә бугай: шулай кирәк булганга гына лекцияләргә йөрдем, имтиханнар тапшырдым, ялларда авылга кайттым. Язга, аннан җәйгә ничек барып җиткәнне дә белмәдем. Көзгә кергәнне дә. Уртак танышлар Рәиснең җәйге каникулга авылга кайтмавын әйттеләр. Яшермим, күңелем белән бик көттем аны. Әмма аның белән очраклы очрашу да тагын яңа газаплар өстәячәк иде, шуңа күрә кайтмавына, бер яктан, сөендем дә.

Якшәмбе көн иде.

Әле йокыдан да тормыйча, әнинең чәйгә чакырганын көтеп иркәләнеп ятам. Ишетелә бит – коймак пешерергә йөри ул анда. Менә исе дә чыкты... Гадәттә, авылга шимбә көн лекцияләрдән соң кайтам да, икенче көнне кичкә таба гына китәм.

Ул арада ишек ачылды – кемдер керде.

– Өйдәләрме соң? Лилия дә кайткан кебек иде, әле китмәдеме?

Тавышыннан таныдым – классташым Гөлназның әнисе Әминә апа. Бездән берничә йорт аша гына торалар.



Рәсем: Наталья Васильева

– Уз, әйдә, уз, Әминә, – ди әни. – Лилия тормаган әле, йоклый бугай. Яшьләрнекен беләсең, бик ашыкмыйлар. Мактап йөрисең – коймак пешереп ятам. Чәй эчәрбез...

– Эчеп тормыйм, рәхмәт... Ашыгам... Кичә Рәиснең әнисен очраттым, сөйләшеп тордык. «Рәиснең туена барып кайттык. Бик матур туй булды. Кодалар Ленинградның үзеннән», – ди.

– Шулаймыни?! Әйбәт булган, бик әйбәт!..

Монысы әни тавышы.

Рәис?! Рәис ди бит... Минем Рәис турында сөйли бит Әминә апа! Лилия киткәнче дип, шушы хәбәрне әйтергә ашыгып кергән иртә таңнан...

Алар тагын нидер хакында сөйләштеләр – мин инде калганын ишетмәдем.

Тукта, бүген нинди көн әле? Әйе, якшәмбе. Кичә октябрьнең унысы иде. Бүген, димәк, унбере. Унбере?!

И-и, Рәис, өздең үзәкләремне...

...Ул мине тагын биш елдан соң эзләп тапты. Ышанасызмы-юкмы, августның унбере иде.

– Бүген ничәсе икәнен беләсеңме? – дип сорадым аннан күрешүгә.

– Беләм, – дип моңсу гына елмайды ул. – Мин моны махсус туры китермәдем, очраклы бу...

Күбрәк ул сөйләде.

– Сине күрер өчен генә кайттым бу юлы... Көн дә димим, әмма шундый еш искә төшәсең... Төшләремдә күрәм. Белсәң иде, шундый сагынган чакларым бар... Барысын ташлап, җәяү кайтып китәрдәй булам. Мин аның белән бала хакына гына яшим... Ул моны белә. Синең хакта да белә... Бүген иртән дә шалтыратты: «Лилия белән күрешергә кайтып киттең инде, очраштыгызмы әле?» – ди... Бәхетсез ата-ана янында бала бәхетле булып үсми. Аерылышуыбыз хәерлегә генә булыр... Барысы да синнән тора, Лилия! Кичерсәң, без бит бергә була алабыз... Кичер мин җүләрне...

Хатирәләрнең шушы өлешенә җиткәч, мин гел тынычсызлана башлыйм.

...Кулымдагы чәчәкләрне кысыбрак тоттым бугай – розаның энәсе кадалды. Үземнең тукталышка да җитәм икән инде – узып китмим тагын. Күршемдә утырган япь-яшь егет кем беләндер телефоннан сөйләшә.

– Әйе, әйе, шул кыз белән очрашуга барам! Исеңә төшердеңме кем икәнен? Чибәр кыз, әйеме. Шундый ягымлы ул... Акыллыга да охшаган. Күз алдыңа китерәсеңме, бүген безнең беренче свидание! Ниһаять, ризалашты... Кафега акчам, әйе, җитә... Чәчәк кенә алып булмады менә. Бу атнада ипотекага түләгән идем...

Ул җәлт кенә кулымдагы чәчәкләргә карап алды. Матурлар шул!

– Киләсе тукталышта төшмисезме?

Телефоннан сөйләшүдән аерылмыйча гына, ул мине чыгу юлына уздырды.

Трамвай тукталышка килеп туктады, ишекләре тавышсыз гына ачыла башлады.

– Мә, энем, бу чәчәкләр сиңа!

Ишекләр, ачылган кебек үк, тавышсыз гына ябылды.

Трамвай тәрәзәсеннән миңа аптырап карап торган егеткә елмаеп кул болгыйм. Ул әле нәрсә булганын аңларга да өлгермәгән бугай.

Горький паркы түрендәге аулак эскәмия янында Рәис мине юкка көтә. Без инде күптән гомернең ике яры кебек, ә елга ярлары – очрашмый. Менә хәзер кайтып, өй ишеген ачып керәчәкмен һәм мине анда ирем, кызым каршы алачак...


Фото: Анна Арахамия

Чулпан
ГАЛИӘХМӘТОВА

Г. Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры – бүген үз өен, үз тамашачысын тапкан театр. Ә артта – моннан 33 ел элек оешып киткән театр студиясе, аннан дәүләт театры статусы алу, артистларның төрле авыл-районнарда уйнап йөрүләре, күченүләр… Үткән белән хәзергене тоташтырып торучы артистлар бар Кариевта. Шуларның берсе – Татарстанның халык артисты Халидә **СӨНГАТУЛЛИНА.** Ул – театрның чишмә башында ук торган шәхес. Халык театрыннан чыккан халык артисты дип атый ул үзен. Иҗатка урау юллар аша, зур тормыш багажы белән, дөньяның әчесен-төчесен татып килә. Шуңа да сәхнәдә уйнамый, ә яши. Ялкынланып янып яши! Сәхнәдә нинди булса, тормышта да шундый. Халидә ападагы энергиягә сокланып туймассың. Әле ул – җанын ярып бирердәй ана, әле – дәртле чегән кызы, әле – үзе әйтмешли, «Халидә пикчерс»… Әледән-әле бармак шартлата-шартлата сөйләүләре үзе бер театрга тиң…

АСЫЛТАШ ЮГАЛМЫЙ УЛ

Халидә апа, сез – халык театрыннан чыккан профессиональ артист. Сездәй асылташлар бик сирәк...

– Әйе, артист булам дип үсмәдем. Нинди сәхнә турында хыяллану?! Яшәү өчен тырмаштык. Бик авырлык белән – юклыкта үстек. Әтинең бер аягы юк иде, әни авыр операция ясатты. Сигез бала арасында мин – төпчеге. Төпчек булсам да, иркә бала түгел идем. Әле дә хәтерлим, күп балалы гаилә булгач, безгә дәүләт акча бирә иде, әмма ул акча миңа аяк киеменә дә җитмәде. Мәктәпкә барыр вакыт җитте, ә аягыма кияргә юк. Беренче укытучым Майбәдәр апа аяк киеме алырга акча бирде. (*Елый.*) Ул мине үз өендә укырга да өйрәтте. Балалары булмаганга микән, бик якын итә иде. Менә шулай әйбер кадере, икмәк, шикәр кадере белеп үстек. Җырлап-биеп яшәмәдек. Әни саратский гармунда уйный иде уйнавын. 90 яшенә кадәр кулыннан төшермәде. Кечкенә чакта җырлый идем, әмма актриса булыр өчен каядыр укырга керү башыма да килмәде. Сигезенче класстан соң, Зәйтүнә апама ияреп, Иваново шәһәренә чыгып киттем. Туку заводында эшкә урнаштым. Станокларга буем җитмәсә дә, үҗәт идем. Ул заманда – стахановчылар чоры: Голубевалар кебек буласым килде. Планны арттырып үтәсәм, остазларымнан да кәттәрәк бит мин, дип, эчемнән горурлана идем. Әле сәнгать түгәрәкләренә йөрергә дә, телеграфистлыкка укырга да өлгердем. Анда биш ел эшләгәннән соң, Уфага кайтып, моторлар төзи торган заводта токарь булып эшләдем. Сызымнан карап деталь ясарга да өйрәндем. Төмәнгә барып, самолет детальләре дә ясадым. Аннан Нефтекамск шәһәрендә вязальщица булып урнаштым. Элек тулай торакларда җыр-биюләр өчен «Красный уголок» дигән бүлмә бар иде. Шунда үткән вечерларда биегәнемне күреп калганнардыр инде, парткомга чакыртып бию түгәрәкләре алып баруны йөкләделәр. Аннан халык театрына чакырдылар. Эштән соң репетицияләргә йөри идем. Җиңел булды дип әйтмим. Ташлыйм дип йөргән чакларым да булды. Режиссер Марс Нуретдинов чакыра килгәч, шифоньерга кереп качтым хәтта. Аннан тартып алып, репетициягә алып китте.
Мине беренче тапкыр сәхнәгә чыгарган кеше ул инде! Беренче зур ролем – «Шәмсекамәр»дә – Шәмсекамәр. Гастрольләр белән Уфага баргач, яныма бик матур бер ханым килеп: «Сеңлем, сиңа укырга кирәк», – диде. Уйнавымны бик яраттылар. Уфада беренче тапкыр бер кочак канәфер чәчәкләре бүләк иттеләр. Иң затлы чәчәк санала иде ул. Йөрәгемнең дөп-дөп тибүен әле дә хәтерлим. Актриса булып китәргә әнә шулар да этәргеч биргәндер, мөгаен.

Читтән торып сәнгать институтына укырга керер өчен, Казанга имтиханнар тапшырырга киттем. Беренче имтиханны бирдем, икенчесенә... йоклап калганмын. Югыйсә будильниклар алып килгән идем.
Төн кунарга кергән фатирда күселәр чабышты. Ә минем иң курыкканым – күсе. Сумкамны кочаклап, будильнигымны кулыма тотып, төн буе куркып утырдым. Иртәнгә, күрәсең, йоклап киткәнмен. Керә алмаганыма бик гарьләндем. Аннан тагын бер кат бәхетемне сынап карарга булдым. Актерлык факультетына көндезге уку бүлегенә имтиханнар тапшырдым һәм кердем. Группадашларым миннән 5-6 яшькә кечерәк иде. Мин инде әти-әни җилкәсендә утыра торган кеше түгел. Эш кирәк. Ул чорда театр студиясе оешып килә иде. Җитәкчесе Фәрит абый Хәбибуллинга шалтыраттым. Ул эшкә алды. Мин килгәч, Фәрит абый: «Менә Сәхибҗамал килде», – дигән иде. «Гафу итегез, мин завод-фабрикаларда эшләп йөрим. Сәхибҗамалның кем икәнен белмим», – дидем. Беренче татар актрисасы турында сүз бара икән. Шулай да эшләү дәверендә мәшһүр актрисаның яшь чагын уйнарга туры килде.

Димәк, сез – театрның нигез ташларының берсе?

– 1989 елда мин килгәндә театрда Фәрит абый, Нуриәхмәт абый Сафин һәм Зәйтүн Яркәев бар иде. Нури абый «Сандугачлар килгән безгә» спектаклен сәхнәләштерә иде. Шул спектакльдә бер яшь кыз ролен бирделәр. Мин сәхнәгә: «Сенсация-сенсация», – дип килеп кердем. (*Көлә.*) Бик авыр вакытлар иде ул. Декорацияләрне үзебез ташыйбыз, үзебез юабыз. Каравай бистәсендә ниндидер бер подвалда репетицияләр уздырабыз. Китәсем килгән чаклар булды, әмма Фәрит абыйның миңа булган җылы мөнәсәбәте тотып калды. Ул вакытта татар театрларына да караш башка иде. Казанда бердәнбер татар мәктәбе эшли. Әмма Фәрит абый безне татар телен яратырга өйрәтте. Ялгыш кына башкорт диалекты белән сөйләсәм дә, ачулана иде.

Халык театрында эшләү тагын нәрсәләр бирде сезгә?

– Халык театрларына кимсетеп караучылар да бар. Ә мин аны бик яратам. Анда ихлас уйныйлар. Аларның профессиональ белемнәре юк, шуңа үзләре булып яшиләр. Уку да кирәк, әлбәттә! Әмма чарлаган

PRESSA


■ М. Кәрим. «Озын-озак балачак», Олы инәй.


■ Р. Батулла. «Кичер мине, әнкәй», Минзифа.


■ М. Фәйзи. «Галиябану», Галимәбану.


■ Р. Корбан. «Бүре һәм Кәҗә», Кәҗә.

вакытта калыпларга да кертәләр шул. Артык шомарталар димме соң... Ә халык театрында эшләүчеләр моннан азат. Алар ничек бар, шулай – табигый уйный. Хәзер, гомумән, сәхнәгә табигыйлек кайта. Әле менә «Озын-озак балачак» (Мостай Кәрим) репетицияләре вакытында да режиссер Илсур Казакбаев: «Сез сәхнәдә уйнамагыз, булган багажыгызны гына ачып салыгыз», – дигән бик шәп киңәш бирде. Ә ул багаж миндә җитәрлек.

Авыр булды, дисез. Нишләп башка театрларга күчмисең, дип сораучылар да булгандыр...

– Ник күчим? Һәр театрның үз актрисалары бар. Үземнең театр туган йорт кебек. Аны нинди генә булса да яратасың, ул нинди булса да, якын. Кечкенә чакта умарта белән мәш килергә ярата идем. Умартада ана корт бар. Мин үземне шуңа тиңлим. Театрга да килделәр-киттеләр, ә мин ана корт булып кала бирдем. Нури абый белән икәү без.

Яшьләр театры гел күченеп йөрде. Әле яңа гына үз оясын ныклап корды. Үз йорты булмау актер өчен бик авырдыр?

– Әлбәттә. Мәртәбәле исемнәрем булса да, артык нык популяр актриса түгел мин. Моңа да шул күченүләр гаепле. Үз тамашачыбыз булды дигәндә генә, тагын күченәбез. Башта труппа Каравай бистәсендәге ПТУ подвалында яшәде. Аннан соң Островский урамына күчендек: мичле бер кечкенә бүлмәдә бухгалтер да, кадрлар бүлеге дә утырды, шунда ук репетицияләр дә үтә иде. Соңыннан Киров районында төпләндек, элекке Курчак театрында бер прапискасыз яшәп алдык. Ниһаять, менә шушында күченеп, рәхәтләнеп яши башладык.

Уйнаган алтмыштан артык ролегез арасыннан күңелегезгә аеруча кереп калганнары бармы?

– Яшь чакта Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендәге Рәхиләне яратып уйнадым, Шекспирның «Король Лир»ындагы Гонерилья дә якын. 50 яшем уңаеннан «Кичер мине, әнкәй» (Батулла) спектаклендәге Минзифа ролен визит карточкам дип саныйм. «Көзебезнең язы» (Рушан Шәриф) бик кадерле...

Ни өчен?

– Ул спектакльне күп еллар элек беренче тапкыр температурам 40 белән уйнап чыктым. Авырсам да, сәхнәдә очып йөрдем. Нури абый: «Күптән менә шулай уйныйсым килгән иде», — диде. Шул бер тапкырдан соң озак уйнамадым. Биш-алты ел элек Нури абый спектакльне киредән сәхнәгә күтәрергә тәкъдим итте. Ул вакытта курчак театрында идек. Репетицияләр өчен безгә сәхнә булмады, хуҗалык бүлмәсендә өйрәнеп, сәхнәгә алып чыктык. Шуңа да кадерледер ул. Тамашачылар да бик ярата бу спектакльне. Актерларга рольләрнең монысын уйныйм, монысын уйнамыйм, дип әйтергә ярамый, диләр. Үземне ачып булмастай рольләрдән әкрен генә баш тартканым булды. Аны кабул итә алмыйм икән, сәхнәдә дә уйный алмаячакмын. Ул яшәү түгел, кылану булачак. Ролем аша халыкка әйтер сүзем юк икән, нигә сәхнәгә чыгарга?!

Уйныйсы килеп тә уйный алмаган рольләрегез булдымы соң?

– Әле дә бар. (*Көлә.*) Яшерен-батырын түгел, театрыбызның визит спектакле булган «Кәҗүл читек»тә әби ролен бик уйныйсым килгән иде. Ничә тапкыр караганмындыр ул спектакльне...

Галиябану, Мәйсәрә рольләре турында хыялланмадыгызмы?

– Театрга килгәндә ул рольләрне уйнарга карт идем инде. (*Көлә.*) 25 яшьлек Галиябану буламы инде, йә? Әмма минем үз Галиябануым бар. «Беренче мәхәббәттә»ге Рәхилә ул.

Сез убырлыларны бик күп уйнагансыз...

– Тискәре рольне уйнар өчен эчтә рух ныклыгы булу кирәк. Аны үзеңә кертү күп көч сорый. Чәчелеп китәсең икән, рольне юкка чыгарасың. «Король Лир»дагы Гонерилья ролен өйрәнгәндә тирә-яктагылар белән салкын, басынкы гына сөйләшеп җәфаландым. Рольдән чыга алмый да интегәсең шулай. «Кызлар-йолдызлар»да миңа командир ролен бирделәр. Шуның кадәр нык кереп киткәнмен, өйгә кайткач, ирем белән дә кискен итеп приказ бирү тонында сөйләшәм икән. Берзаман ирем: «Отставить», – дип кычкырып җибәрде. (*Көлә.*) Ярый әтисе аңлый инде. «Премьерага әзерләнәбез, синең ярдәмең кирәк», – дим үзенә спектакль чыгарган саен.

Өйдә аңлаулары олы бәхет инде ул, Халидә апа.

– Ринат миңа танышкач ук рефератлар әзерләргә ярдәм итә иде, хәзергә кадәр аның ярдәмен тоеп яшим. Гастрольләрдән кайтып кермәгән чаклар бар иде. Беркайчан да дәгъва белдермәде. Кызыбыз Чулпанны ул карады. Мине гастрольдән өчпочмаклар пешереп, плакатлар ясап каршы алалар иде. Ул минем әтием дә, ирем дә, сөяркәм дә.

Гадәттә, артист баласы сәхнәгә тартыла, чөнки ул шул мохиттә үсә. Татарстанда династияле актерлар гаиләсе күп. Кызыгызның да артист буласы килмәдеме?

– Чулпанның сәхнәгә чыкканы булды. Әмма һөнәр сайлар вакыты җиткәч: «Ишек төбендә балаларымның әниләрен көтеп утыруларын теләмим», – диде. Кызымны бик аңлыйм. Бервакыт зур гастрольгә чыгып китәргә җыенабыз. Чулпан миңа: «Әни, мине песи баласы кебек калдырасың да чыгып китәсең», – диде. Гастроль буена еладым. (*Күзләренә яшь тула.*) Балалар бакчаларында спектакльләр уйнап йөрисең, ә үз балаңның күңеле буш кала. Менә шундый авыр чаклар да булды. Артист тормышы җиңел түгел инде ул...



Халидә апа, сез утыз елдан артык сәхнәдә. Элек спектакльләр бик самими, гади итеп куела иде дип әйтимме соң... Режиссер аны халыкка якынайтып бетерә иде, хәзер, күрәсез, башка төрле трендлар өстенлек итә. Тамашачы үзе уйлап, үзе аңлап бетерсен, диләр. Куелышлар да кабул итәргә авыррак. Символлар белән күп эшлиләр. Мондый яңалыкны ничек кабул итәсез?

– Мин яңалык яклы. Билгеле, традицияләр дә булырга тиеш. Аклы-каралы фотоларны хәзер дә яратып карыйбыз бит. Ә үзгәрешләр театр тормышында гына түгел, яшәешнең бар почмагында. Яшьләр хәзер бик алдынгы карашлы, эрудицияле. Без генә ул кечкенә чакта берни күрмәдек. Яшь тамашачыларыбыз безгә интернеттан карап, белеп, укып киләләр. Аларны яңалык белән генә кызыктырып була. Шуңа традицияләргә ябышып яту дөрес булмас, алга карап яшәргә кирәк. Шул ук вакытта репертуарда төрле әсәрләр булсын инде ул. Ә үзем театрда булган төрле лабораторияләрдә катнашырга яратам. Аңламаган чакларым да бар, әмма барыбер яратам. Сәхнәдә ямьсез күренешләрне кабул итә алмыйм. Сәнгатьтә иң элек матурлык булырга тиеш. Сәнгать бит ул шуңа да! «Калеб»ләргә мөкиббәнмен. Алар татарның интеллигенциясе булырга тиеш.

Сездә яшьләр бик күп. Бүген театрны алар тартып бара дисәң дә була. Көнләшмисезме?

– Әле ничек кенә көнләшәм. (*Көлә.*) Бик яратам үзләрен. Аларда башка энергетика. Артларыннан калмыйм, иярәм, чөнки алар белән рәхәт. Хәзерге буын ихлас, эчкерсез ул. Бергә эшләргә генә язсын. Театрдан артистлар китүен бик авыр кичерәм... (*Бармак шартлатып.*) «Кәҗүл читек»тә нигә уйныйсым килә дип уйлыйсың соң? Балаларым – яшь артистларым уйный бит анда! Алар – бөтенләй башка дөнья!

Халидә апа, әңгәмәбезнең башында беренче татар актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяны искә алдык. Аның яшь чагын уйнадым, дидегез. Белүемчә, театр премьерага әзерләнә. Айгөл Әхмәтгалиева әсәре буенча сәхнәләштереләчәк «Яратып туя алмадым» драмасы. Сез анда кабат Сәхибҗамалны уйныйсыз.

– Әйе, Чулпан, миңа кабат Сәхибҗамалны уйнау бәхете тиде. Бик куркып кына алындым бу рольгә. Ул бит җыелма образ түгел, шәхес! Бөек татар актрисасының соңгы көннәрен – фаҗигасен уйнаячакмын. Ул ялгызы кала, гомеренең ахырын интернатта үткәрә. Әмма шунда да, авыруларны җыеп, спектакль куярга тели. «Тәнемдә җаным булганда уйналмаган ролемне уйнарга сәхнә бирегез. Халыкка әйтер сүзем бар», – ди ул. Йөрәгем генә түзсен бу рольне уйнап чыгарга. Режиссерыбыз Ринат Әюпов: «Сәхибҗамалга охшагансыз», – ди. Бардыр уртак сыйфатлар да... Әле мин дә уйнап туймадым. Уйныйсы рольләрем, тамашачыга әйтәсе сүзләрем бар...

Видеокотлау »





Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Безнең Иске Байсар – Казан–Уфа юлында, Сөн буенда, нәкъ Башкортстан чигендә урнашкан борынгы, бик бай тарихлы авыл.

Түбән очта сакланып калган кайбер биналар, кибетләр, сәүдәгәр йортлары революциягә кадәр үк салынган булган инде. Үзенчәлекле архитектуралы Мөсаллия мәчете, заманча мәдәният йорты, өч катлы мәктәп, кафе, кибет, төзек йортлар янәшәсендә алар узган гасырлар ядкаре булып утыра, авылның олы юл өстендәге эре сәүдә үзәге булуын искәртә.

Тарих укытучысы буларак, шуңа игътибар иткәнем бар: безнең мәктәп балаларында туган авыл, күренекле якташлар, аларның күркәм эшләре белән горурлану көчле. Моңа, әлбәттә, җирлек, мәктәп тарафыннан оештырылган төрле чаралар, очрашулар, бәйрәм-йолалар да йогынты ясый. «Байсарда базар көне», «Сөн буенда кичке уенда», «Урамыбыз бәйрәме», «Карга боткасы» – шундыйлардан. Мәктәпкә килеп керүгә үк музей каршы ала. Ә дистәләгән альбомнарга язылган мәктәп тарихы калын-калын томнар кебек.

Күренекле авылдашларыбыз диюгә, укучыларыбыз иң элек «Ташкын» хуҗалыгы җитәкчесе, Россия һәм Татарстан күләмендә танылган белгеч, РФның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Рәүхәт абый Салихҗанов исемен телгә алалар. Тарихи романнар авторы, Г. Тукай премиясе лауреаты Вахит абый Имамов та – безнеке. Бер очрашуга кайткач, ерак тарихка кереп китеп, XVII гасырда ук нигез салынган авылыбыз, Карабәк шәҗәрәләре турында сөйләп, балаларда үткәннәр белән кызыксынуны тагын да көчәйтте. Авыл турындагы әсәр дигәннән, күренекле эстон язучысы Лилли Прометның «Ирләрсез авыл» романы Байсар, Чишмәбаш, аның кешеләре турында инде! Бөек Ватан сугышы елларында Байсарга эвакуация белән килгән эстон кызы безнең мәктәптә немец теле укыта, татар халкының гореф-гадәтләрен өйрәнә. Еллар узгач, ул күренекле язучы булып китә, һәм татар авылындагы тормышы да иҗатында чагыла. Авылыбыз турындагы роман сигез телдә китап булып чыга.

Танылган якташларыбызны фәндә дә, әдәбиятта да, сәнгатьтә дә, спортта да күрергә була. Танылган баянчы Фәнис Гыйльметдинов, социология фәннәре докторы Айсылу Нәгыймова, Россия хатын-кызлар хоккей командасы уенчысы Лиана Ганиева – шундыйлардан.

Байсар авылы егете, күренекле дәүләт эшлеклесе Шәйгәрдән Шәймәрдановны аерым зурлап искә аласы килә. Ул 1890 елда ярлы крестьян гаиләсендә туган. Волость башкарма комитеты рәисе, волость хәрби комиссары булган, ак чехларга, Колчак армиясенә, сәнәкчеләргә каршы сугышларда катнашкан. Шәймәрдановны 1925–27 елларда Татарстан Үзәк Башкарма комитеты Президиумы рәисе, соңрак ТАССР Халык комиссарлары Советы рәисе итеп куялар. Ул эшче һәм крестьяннар арасыннан милли кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә. Эш кәгазьләрен татар телендә тутыруны гамәлгә кертә. Аның инициативасы белән татар телен гамәлгә кертү үзәге каршында курслар оештырыла, ТАССР Конституциясе языла... 1928–30 елларда ул Мәскәүдә ВКП(б) Үзәк Комитетының җаваплы инструкторы, РСФСР Финанс халык комиссариатының коллегия әгъзасы итеп билгеләнә. Ул – сәяси репрессия корбаны. 1939 елда кулга алына, 1940 елда иң югары җәзага хөкем ителә. Кызганыч, үзе үлгәннән соң гына иseme реабилитацияләнә.

Идарә каршына куелган Шәйгәрдән Шәймәрданов сыны көн саен авылдашларын сәламли кебек. Нәкъ җырдагы кебек инде: «Күңелләргә якын син, Байсар! / Үз авылын бүген күрсен иде / Шәймәрданов – батыр комиссар!» Быел сентябрь аенда аның тууына 130 ел тулу вакыйгасын билгеләп үттек, митингка җыелып, һәйкәленә чәчәкләр салдык, истәлекләр яңарттык. 1967 елларда композитор Сара Садыйкова белән шагыйрь Мостафа Ногман авылыбызга килеп, «Шәймәрданов комиссар» дигән җырны язып киткән булган. Ул җыр да яңгырады.

Фото: Анна Арахамия

Авылыбыз үзе тарих дәресләре бирә безгә. Мәдәният йортында озак еллар эшләгән Әнвәр абый Вәлиев күрше Яңа Байсарның иске клубында Туган як музееn ачкан иде. Меңнән артык экспонат тупланган анда! Борынгы киемнәр, көнкүреш әйберләре, һөнәрчелек үрнәкләре, авыл күренешләре, кульъязмалар, китаплар... Ниләр генә юк! Балалар, экскурсиягә барып, туган як тарихы буенча дөнья кадәр мәгълүмат туплый. Ә Байсар үзәгендә моңарчы ашханә булып торган зур тәрәзәле яшел йорт – XIX гасыр истәлеге – үзе үк тарихи бина. Әнвәр абый оештырган музей тагын да баеп, тулыланып, озаклаамый шунда күчәр дип өметләнәбез.

Луиза ХӘЙРИЕВА.
Актаныш районы.

Интернетта таралган әлеге сүзләр яшь аралаш көләргә мәҗбүр итә: «Бу елның азагында Җир шарына чит планета кешеләре килеп төшсә, аптырамучы булмас».

Пессимистик кәефне тартып китергән күңелсез хәлләр кабатланып торса да, узып баручы елда башкаланы шаулаткан башка вакыйгалар булуын да истән чыгарырга ярамыйдыр. Әлбәттә, коронавирусның популярлыгы һәм актуальлеге белән бер генә чара да тиңләшә алмас. Урамга чыгу өчен «смс» аша рөхсәт алулар һәм кесәдә телефон белән бергә маска, перчатканы да йөртергә гадәтләнүләр ул вакыт өчен авыр бер сынау буларак истә калгандыр. Ләкин шундый катлаулы вакытта Казаныбызга җан өргән кайбер вакыйгалар зур игътибарга лаек дип уйлыйм.

Без, студентлар, уку йортының ишекләрен ачу, укытучының күзләренә карап дәрес тыңлау белән берرәттән, гадәти чараларның да ничек кадерле булуын аңладык. Шуңа күрә ирек тәмен яңадан татыгач та мөмкин булган барлык чараларда катнашырга ашыктык.

Татарстан Республикасының яңартылган Милли китапханәсе күпләрне җәлеп иткәндер, чөнки экскурсия билетлары күз ачып йомганчы юкка чыга, бары тик иң җитезләргә генә эләгә. Ул кунакларны төсле утлар белән янып торган хәрефләр каршы ала. Шуларның бизәүен күрү өчен генә дә китапханәдә булу кирәк!

Г. Камал исемендәге театрның өч премьерасы арасыннан иң зур шаушу тудырганы «Сүнгән йолдызлар» булды. Фәрит Бикчәнтәев куйган әлеге спектакль бик күп каршылыклы фикерләрнең бәрелешенә сәбәп булды, матбугатны, тәнкыйтьчеләрне җанландырып җибәрде һәм шуның белән игътибар казанып, үзенең тамашачысын тапты.

Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» әсәре буенча төшерелгән сериал тагын да кискенрәк уй-фикерләр өчен азык булды. Дөреслекне эзләп янган укучы-тамашачылар рәтенә безне, ягъни татар филологиясе студентларын да тезгән бу вакыйга бар халыкны тетрәндерде кебек.

Икеләнүләргә урын калдырмаган һәм бер караштан ук күпләрне бар кешене гашыйк иткән «Урам» экстрим-паркы Россиядә иң зур мәйдан дип табылды. Парк ачылганнан соң, инстаграмны матур һәм оригиналь фотолар белән «тутырырга» теләгән яшьләр ташкыны шунда агылды. Бу аңлашыла да: фотоаппаратка үзеңне генә түгел, киләчәктә Олимпия уеннарында җиңәргә дип максат куйган сәләтле велосипедчы һәм скейтбордчыларны да төшерергә була бит.

Без – тарихи елның шаһитлары. Минемчә, 2020 елның төп вакыйгасы алда санап үтелгәннәрдән шактый ерак тора. Иң мөһиме: бу ел бәхет критерийларын үзгәртте. Әгәр иртән уянып, үзеңне яхшы хис итәсең икән, син чиксез бәхетле кеше. Чиксез! Әлеге елның төп ачышы шулдыр.

Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.
Казан шәһәре.

Бүген кайбер матбугат чараларында (газета, радио) кыз урлауны романтик күренеш, гореф-гадәт итеп күрсәтә башладылар. Мондый алым киләчәктә яшьләрне ялгыш юлга, җинаятъ кылырга этәрмәсме?

Хатын-кызны көчләп җинаятъ кылган өчен хөкемгә тартып булганлыгын да яшьләр исләреннән чыгармасыннар иде. Моның өчен хокук сагында торучыларга мөрәҗәгать итү генә кирәк. Ләкин күп очракта урланган кыз шок хәлендә була, кайвакыт аңа көчле басым ясала, куркытырга да мөмкиннәр. Шуңа күрә ул каядыр барып гариза язарлык хәлдә булмаска мөмкин. Кыз урлану турында сүз чыкса, бу турыда авылдашлары хокук саклаучыларга хәбәр салырга тиештер бәлки?! Урланган кыз үзе «мин риза» дигән очракта да, урлаучы һәм аның дуслары әйбәтләп тикшерелергә тиештер?! Ә бәлки кыз урлауны закон нигезендә үк тыяргадыр?! Безнең заманда бит инде урлап түгел, иркенләп, килешеп, сөйләшеп тә никах укытырга, гаилә корырга мөмкин. Шәхес ирке дигән әйбер дә бар бит әле... Урланган кызны үстергән әтиәни мәнфәгате, аларның фикере турында да онытмаска кирәк дип уйлыйм.

Кыз урлауны күңелле, романтик гадәт итеп кенә күрсәтергә ярамый. Электән килгән гадәт булса да, аның кеше хокукына бәйле яклары да, зур җаваплылык икәнен дә истән чыгарырга ярамый дип уйлыйм мин. Яшьләр моңа җиңел карамасын иде!

Исемемне күрсәтмим,
йә урланган кыз дип уйларлар.
Казан шәһәре.

РЕДАКЦИЯДӘН: менә шундый кызыклы фикер язылган хат алдык без укучыбыздан. Ә сез кыз урлау гадәте турында ни уйлыйсыз? Кыз урлау гадәте яшәгән яклар бармы әле? Хатларыгызны, фикерләрегезне көтәбез!

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

75 ҖИҢҮ! 1945–2020

Илгә ябырылган олы кайгы – миллионнарча корбаннар биргән сугыш афәте без – балалар өчен дә зур сынау, балачагыбызны урлаган, бик күпләребезне ятим иткән кара көннәр булып йөрәккә уелып калган. Безнең чор баласы авыр физик хезмәт белән иза чигүләрдән тыш, сәяси яктан кыерсытылу газапларын да башыннан уздырды шул. Искә төшереп, күз алдына китерсәң, җаннар телгәләнә. Ләкин без барысына түздек...

ИРТӘ ОЛЫГАЙДЫК...

Мин үскәндә авыл урамнарында бала-чага тавышы үзенә бер ямь биреп, тынычландырып тора иде. Безнең Түбән очның һәр йортыннан өчәр-дүртәр бала чыгып, төрле уеннар уйныйбыз: йөгереп тә ярышабыз, «сызыкташ» та сикерәбез; малайлар, тал агачыннан «кәшәкә» ясап, шарсыман йомры ташны куышалар; «чүрәкикалак» (авылча теннис) осталары да күп.



Ә минем укытучы буласым килә!

Күрше әбидә яшәп укытучы Оркыя (Түбән Кенә кызы), Гайшә апа (Носы авылы кызы) кебек!.. Әле хәреф белмәсәм дә, капка төбенә «Югары уңышка» газетасын тотып чыгам да, иптәшләремне тезеп утыртып, «газета укыйм», янәсе! Чынлыкта, үзем ишетеп белгән, әби сөйләгән әкиятне газетадан карап сөйлим. Укытучы апалар кебек булырга тырышам!

Бер көнне шулай әни эшкә киткәнче чәчемне үреп китте. Күршедәге укытучы апага кереп, шул ике толымымны кистердем. Минем куануыма шатланып, Гайшә апа үзенең кәкре тарагын башыма кадап куйды да киселгән ике толымны кулыма тоттырып озатты. Миңа 6 яшь, ул елларда 8 яшьтә укырга бара идек. Бәхеткә, әби мине аңлады: учактагы утын ялкынына теге ике толымны «бисмилласын» әйтеп урнаштырды. Мин инде, валлаһи, «укытучы» идем! Тик әни бу тәвәкәллегемне авыр кичерде... Әнидән сорый белмәгәнмен... Әти, өйдә тынычлык сакчысы буларак: «Кызым, синең чәч тиз үсә ул, үзең тарап, үзең үрерсең», – дип тынычландырды.

Абышкада кара болыт – хәвефле...

Инде гасырга якын вакыт үткән... Ләкин Абышка елгасы турысында урман өстендәге шомлы кара болыт күз алдыннан китми һаман. 1941 елның июньнең бер көнендә без, икенче классны тәмамлап өченчегә күчкән укучылар, урманга печәнгә барасы идек. Әмма бригадир абый урманга җибәрмәде: «Колхоз идарәсе янына барып басыгыз», – диде. Теге кара болыт куркыта, ахрысы. «Абышка болыты халык теленә кергән, хәвефле санала дип сөйлиләр», – дип үзара сөйләшә-сөйләшә идарә йорты янына киттек. Нindидер шомлы тынлык. Халык җыела башлаган. Колактан-колакка сүзләр йөри, елаучы апалар да бар, каяндыр «сугыш» сүзе дә ишетелә...

Ул елларда радио һәм телефон идарә йортында махсус бүлмәдә генә. Халык арта бара, ә без – кызлар, «сугышмадык», дип елаша башладык. Район үзәге Балтачтан атка атланып килгән абыйны күргәч, курку тагын да көчәйде. Әти-әниләр килеп җитеп, әниләргә тотынып елаулар артты. Без балалар күңелендә һич онытылмый торган хәвеф... Әле дә (бүген 90 нчы яшемдә) һич онытылмый торган хәл, әле дә күз алдында, хәтта кайда кем белән басып торуым да хәтердә. Районнан килгән вәкилне тыңлап аңламасак та, тыңлап белергә тырыштык. Инде иртә таңда сугышка китәсе тугыз ир-егетнең фамилиясе әйтелгәч, сабырлыклар күз яшьләре белән юылды. Дөньяда ничек яшәргә икәнен, өйгә кайткач ни эшләргә кирәген белмичә, әниләргә җитәкләнеп, елый-елый таралыштык. Сугыш хәбәрен зурларның ничек кабул иткәне ул чакта без балаларга бөтенләй аңлашылмый иде. Әмма өлкәннәр сүзсез генә аңлаша торган еллар иде ул, чөнки нидер әйтү, сорап белергә тырышу гаепләнә. Ул чорның шәхес культы хакимлек иткән куркыныч еллар булуы күпләргә ахырдан гына билгеле булды.

1418 көн барган сугышның һәр көнен, төнен үткәрү бер газап иде.

Бер башак та җирдә калмасын!

...Без – сугыш елы балалары әниләр, әби-бабайлар белән җәй буе эштә кайнаштык. Яшелчәчелектә, иген һәм бәрәңге басуында башланган эшебез урып-җыюга килеп тоташа. Әниләр уракка иртә таңнан алып бара. Чөнки «Бер башак та җирдә калмасын!» дип эшлибез. Печән җыю, борчак чабу эшләрендә мәрхәмәтле бабайлар йомшак сүзләре, тормышның бай тәҗрибәсе белән күптөрле эшкә өйрәттеләр. Әтиләр белән фронтка атлар да китте. Бабайлар ат сбруен сыерүгезгә көйләп, аларны бөтен төр авыр эшкә кулланырга өйрәттеләр.

Уку елы 1 сентябрьдә түгел, октябрьдә – бәрәңге алгач кына башлана. Алай да күп кенә укучыны өйләреннән эзләп табасы... Олы кызым Нурия: «Әтине яздыңмы?» – дип сорауга, җавап таба алмыйча, читкә карап яшь түктем. Ирем Бакыйның әтисе – гражданнар сугышы ветераны – 1941 елның октябрендә Ватан сугышына китә. Өйдә 72 яшьлек авыру бабай белән әби, биш бала кала. Җәмәгате Ләмигага: «Сиңа газизләремне ышанып калдырам», – дип саубуллаша... Тик газизләрнең әнисен дә Чуашия җиренә окоп казырга җибәрәләр... Укулар башлангач, Карадуган җидееллык мәктәбе укытучысы Андреева Сания апа укучысын – бу гаиләнең төп терәге булган Бакыйны эзләп килә... Ә монда укучы бала белән бабай мунча сүтеп утын әзерлиләр – ягарга утын беткән. Зыятдин бабай: «Бүгенгә генә калсын. Ике көнлек утын булгач, иртәгә барыр», – дип, укытучыны озата. Шулай итеп, әнисе кайтканчы Бакый мәктәпкә ике көнгә бер генә бара. Әмма үтә тырыш яхшы укучы була Нуриянең әтисе – минем ирем Бакый.

Илдә авыллар күп, күп булуы да яхшы икән. Яшәү ямен-тәмен аңлатучы илаһи көч бүләге ул – авыл! Сугыш илбасарларыннан саклау урыны да булды ул! Эвакуацияләнеп, күпме кеше килде авылга. Безнең сулъяк күршедә биш кешелек «Мәскәү әби» гаиләсе өч ел яшәде Кенәбашта. Каршы як урамда 19 кешелек дүрт гаилә Эстониядән күчеп килгән иде. Район үзәк больницасына яралы солдатлар урнашты.

Мин – әтиле!

Бүген миңа бик ямансу... Классташларым арасында 25 укучыдан мин генә исән...

Әтием 1941 елның сентябрендә фронтка китеп (Мәскәү өчен барган сугышта сапёр була ул), бот төбеннән сул аягын югалтып, бер аяк, ике таяк белән кайтты. Бу 1943 елның көзе иде. Авылда бер тере сугыш ветераны иде әти. Без – биш бала, әби һәм әни – әти белән яшибез. Әти балта остасы. Авылда булдыра алганча төзү эшендә йөри. Классташларым арасында бер мин – әтиле, күз яшьләрен тыеп булмый.

Әти кайткач куандык. Әмма аңа бик авыр иде. Өйдә ашарга юк. Юлда кесәсендә кайткан ике сынык ипиен, күчтәнәч дип, безгә бирде, берәр кабып суырып йоттык. Ипи тәмле шул! Тана сыер әле бозауламаган, сөт тә юк, әтине балта эшенә чакырып эшләтүчеләр көнгә бер ашатып җибәргәли. Күршедә яшәүче урманчы абзый әтигә: «Син шешенә башлагансың, менә шушы онны сөткә болгатып ашатсыннар әле», – дип, бер төенчек он бирә. Шулай очын-очка ялгап исәнлекне саклыдык. Урманда җәй башында җиләк пешә башлады, тана бозаулады – сөтебез бар. Ашлык өлгерә башлагач, әти ашлык тарту тегермәненә урнашты. Шөкер, исән калдык шикелле...

Сугыш еллары авылы турында мин язучы Мөхәммәт Мәһдиевнең «Кеше китә – җыры кала» дигән әсәрен укырга киңәш итәр идем. «Мәйсүфә карчыкның башы шаулый» дигән бүлеге... икеләндерә, барысы да чынбарлыкмы дип ышанмый торасың. Ничек кенә әле! 1940 елны туган укучым Закиров Мөхтәр инде тугызынчы класста укыганда яза:

Сугыш вакыты белән тыныч чорның
Уртасына туры килгәнгә,
Тормыш безнең чукып чыныктырды
Үзе таләп иткән кимәлгә.
Сугыштан соң булган замананың
Варисы да идек, колы да,
Кирәгеннән артык кечкенә дә
Кирәгеннән артык олы да...

Сугыш ятимнәренең башына төшкән авыр тормышны язып аңлата алмамдыр. Барлык халык куанып бәйрәм иткән Җиңү көннәре дә аларга күңел җәрәхәте булып кына килде. Араларында әтиләрен күреп белмәгәннәре дә, бер мәртәбә әти дип әйтә алмаганнары да бар иде. Әмма ул ятимнәрнең ничек яшәве белән ил кызыксынмады, хәтта белергә дә теләмәде... Инде ул ятимнәрнең толлык әчесен йота-йота балаларын кеше итү өчен көн дими, төн дими тырышкан әниләре дә дөнья куйды... Урыннары оҗмахта булсын иде.

Иртәгә укырга килегез, балалар!..

Мин – укытучы булырга хыялланган, өстәвенә, авылда туган колхозчы кызы. Уйлыйм да сокланам: шундый авыр чорда да укытучыларыбыз олы җанлы, мәрхәмәтле булган. Язу өчен ручканы каз каурыеннан хәстәрлибез, салам яккан мич корымыннан әбиләр язу карасын ясап бирә, дәфтәребез юк, иске китапларның юл арасына язабыз. Дәреслекләрне укытучылар каян таба, шулардан файдаланабыз. Расписание буенча татар теле, рус теле, немец теле дәресләре керә. Мин укыган Түбән Кенә җидееллык мәктәбенә немец телен укытырга яңа гына институт тәмамлаган Каюма исемле шәһәр кызы килде. Үзе шундый матур, ягымлы... Бик әйбәт укытты. Мин Каюма апа өйрәткәннәр буенча укыдым да,

Көтеп алган Җиңү көне ятимнәр күңеленә күз яшьле көн булып кереп калды.



Мәктәптә укыган елларым. 1946 ел.

иптәшләремә булыштым. Еллар үтә... Җиденче класста сугыштан кайткан абыйлар да укытырга керә. Тәртип хәрбиләрчә, әле сугыш беткәч тә «Военное дело» дәресе дүрт уку елы буе барды. Авыл халкы мәктәп хәлен аңлады, укытучыларга рәхмәтле булды. Әниләр: «Укытучыңа әйтәм әле», – дисәләр, көл була идек. Акчасын белмим, укытучыларга ел буена 3 литр керосин, мичкә ягу өчен 5 куб. метр утын бирәләр иде. Мине материал ягы алай ук кызыксындырмый, укучылар алдында белемле, алдынгы, киң карашлы директорыбыз Низамиев Нәби абый кебек мәрхәмәтле өлкән кеше булып күренәсем килә иде. Шөкер, минем укытучыларым, сугыш елларында да, сугыштан соңгы авыр елларда да илаһи көч булып каршымда балкып, гел үзләренә тартып тордылар, рәхмәт аларга.

Бүген мин лаеклы ялда. 41 еллык хезмәт стажым бар. Башта – җидееллык, соңгы елларда урта мәктәптә укыттым. Уйланам да – сокланам! Мин мәктәпләрне изге урын дип саныйм. Төрле гаиләләрдә үскән балаларга зур бер гаилә тәрбиясе бирә торган мәктәп булмаса?.. Күз алдына китерүе дә кыен.

Мәктәп үз юлында, изге максатында эшләде. Ә бит укучы балаларның хәле бик авыр иде. Мичтә пешкән бәрәңге ашап, 4 километр җәяү укырга килгән Кенәбаш һәм Хәсәншәех балаларының дәрестән соң авылларына кайтырлык хәле дә калмый. Мәктәп директоры Низамиев Нәби абый ничек җаен тапкандыр, шушы ике авылга кайтасы балаларга ашау оештырды – кайнар шулпа пешереп ашаттылар. Аңа үзебездә үсә торган файдалы үләннәр туралган, он тугланган, тозы да бар, Нәби абый безне тезеп бастырды да шулпа салынган савытлар өләшеп чыкты. Ә без баскан килеш кенә савыттан шулпаны эчеп, рәхмәт әйттек. «Балалар, исән-сау кайтыгыз, иртәгә дә укырга килегез, кайнар аш булыр...» – дип озатып калды Нәби абый.

...Укытучы булырга теләгән балачак хыялымны гел ачык ишекләр каршы алды. Мин җиденче класста укыганда мәктәптә үзешчән театр эшчәнлеге башланды! Безгә халык әкиятләрен сәхнәләштерергә куштылар. Өстәвенә, якташыбыз, җырчы Җәвалһирә Сәлахова, Рәшит Ваһаповлар төркеме, фронтта сугышчыларга концертлар куеп йөргәннән соң, Түбән Кенәгә ялга кайткан. Директорыбыз Нәби абый, балаларны куандырып, безгә бәйрәм ясады: артистлар белән киңәшеп, укучыларга бушлай концерт күрсәтте. Шулкадәр зур куаныч булды, сәхнә бүгенгәчә күз алдында... Электр юк, дүрт дәрес укыгач, көн яктысында без Рәшит Ваһапов, Җәвалһирә Сәлахова, Гани Вәлиев концертын карадык, мәңге онытылмый торган бәйрәм булды!

Җидееллык белем алгач, тизрәк укытучы булу өчен Арча педагогика училищесына укырга киттем. Тик мин ашыксам да, дөнья үзенчә, училищеда уку сугыш елларында өчьеллык иде, 1946 елдан дүртьеллыкка әйләнде. Үкенмим! Училище миннән әзерлекле укытучы ясады. Андагы укытучылар чын педагогик һәм фәнни белем бирде безгә. Сугыш аркасында ятим калган балалар белән эшләү нечкәлекләренә өйрәтте алар, укыту – изге гамәл икәнен аңлаттылар. Мин язмышыма рәхмәтле!

Мәдинә ЗЫЯТДИНОВА,
СССРның Халык мәгарифе отличнигы, ветеран укытучы.
Балтач районы,
Карадуган авылы.



75
ЖИҢҮ!
1945–2020

Хәтер – мәңгелек...

Хәтер – мәңгелек...


Бөек Җиңүгә миллионлаган гап-гади кешеләрнең каһарманлыгы бәрабәренә ирешә алдык. Алар арасында безнең татар егетләре, татар кызлары да байтак. Минем бабам, синеке, аныкы... Сугыш афәте кагылмаган, сугыш ишек шакымаган капка, гаилә калды микән? Җиңү таңы безгә шуңа да кадерле... Инде бу хакта бүгенге яшьләребезгә дә аңлатасы, төшендерәсе, күңелләрендә горурлык хисләре уятасы килә. Бу проект – шул хакта. Мондый ядкарьләр, бәлки, сезнең гаиләләрдә дә сакланадыр. Юк икән, аларны шушы сайттан табып алырга мөмкин: https://pamyat-naroda.ru. Бабаларыгызга орден-медальләр ни өчен бирелде икән? Балалар, оныклар белән бергә утырып эзләп карагыз әле. Әлеге тарихи документларны үз күзләре белән күргәч, Җиңү сүзенә алар инде берничек тә битараф калалмас...
Табышларыгызны безнең белән дә уртаклашыгыз. Хатларыгызны көтәбез.



Әтиебез Маһияров Миңлегаян Фәтхелбаян улы 1925 елда Башкортстанның Яңабирде авылында туа. Рәҗәп урта мәктәбенең унынчы классында укып йөргән җиреннән – 1943 елның декабрендә Бөек Ватан сугышына алына. Ул елда аның кебек унсигезе дә тулмаган күп егетләр фронтка җибәрелә. Әти сугышчан юлын 2 нче Украина фронты составындагы 5 нче танк гвардия бригадасында санинструктор булып башлый. Киев, Буг, Прут, Яссы өчен барган сугышларда ике тапкыр яралана. 20 нче гвардия танк бригадасының 5 нче моторизацияләнгән десант бригадасы составында Корсун-Шевченко юнәлешендә авыр сугышта танкистлар белән бергә илледән артык кешегә медицина ярдәме күрсәтеп, яу кырыннан алып чыга. Үзе дә каты яралана. Шушы батырлыгы өчен әтинең Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнүе турында архив документы бар. Россия Федерациясе Оборона министрлыгы Үзәк архивыннан килгән документлар арасында бер хат безне аеруча тетрәндерде. Маршал Малиновский үзе кул куйган бу котлау хатында әтиебезнең тизрәк савыгуын теләгән. Шундый югары җитәкченең гади солдатка хат язуы үзе бер вакыйга бит.

Бөек Җиңү яулап кайтканнан соң старшина Маһияров мәктәптә балаларга аң-белем бирү эшенә алына. Кушнаренко педучилищесын тәмамлап, математика, тарих, физика фәннәрен, татар, рус, немец телләрен укыта. Мәктәп директоры да булып эшли. Уфа пединститутында биология фәне буенча югары белем ала. Ул минем беренче укытучым да... Әти бик бала җанлы, белемгә омтылучан кеше иде. Аның бу сәләте безгә, сигез баласына да күчкән. Безнең арада да галим, хәрби, экономист, инженерлар бар.

Зилә МАҺИЯРОВА.
Казан шәһәре.



155

Все графы заполнять полностью

НАГРАДНО[Й] ЛИСТ

1. Фамилия, имя и отчество Могияров Минегоян Фатаулбаянович
2. Звание гв. Старшина м/с 3. Должность и часть санинструктор 20 гв. танк. бр. 5 танк. корпус.

Представляется к Ордену „Красной Звезды“

4. Год рождения 1926 г. 5. Национальность Татарин 6. Партийность чл. ВЛКСМ
7. Участие в гражданской войне, последующих боевых действиях по защите СССР и Отечественной войне /где, когда/ 1943 г. – Январь. Киев, Буг, Прут, Яссы. 1944 г.
8. Имеет ли ранения и контузии в Отечественной войне 2 раза ранен
9. С какого времени в Красной Армии 1943 г. январь 10. Каким РВК призван Шикмогушовским РВК Башкирская АССР
11. Чем ранее награжден /за какие отличия/ Не награждался.
12. Постоянный домашний адрес представляемого к награждению и адрес его семьи

I. Краткое, конкретное изложение личного боевого подвига или заслуг.

...ки 20й гв. танк. бр. участвовал в боях подь Корсунь ...ченковский в 4й дес. мех. бат. действуя на танке ...стно с десантниками оказал боле 50 десантникам ...анкистам медицинскую помощ. и вынес с поле боя ...твовал в форсировании р. Прут. В прорыве оборон... под Яссами оказал боле 10 танкистам мед. помощ. ... с поле боя и был тяжело ранен.
Достоен правительственной награды.
Орден „Красная Звезда“.

Начальник ... м/ст. [signature]
Зам. начальника по политической части
[signature]



«Син – гомер агышларым»



Раилә
ХӘЯЛИЕВА

Шагыйрь Нажар Нәҗминең 1980 елда Уфада башкорт телендә нәшер ителгән «Тарафтар» китабын кулыма алам. Вакыт җиле кунып, битләренә саргылт төс иңгән, чит-читләре шактый таушалырга өлгергән (димәк, укучы күп булган!) бу китапта шагыйрьнең шигырьләре, поэмалары... Ә мине аеруча сөендергәне – җырга әйләнеп киткән шигырьләре булды. «Өфе юкәләре», «Сиңа тагын мин бер киләм әле», «Юкка түгел, юкка түгелдер» һәм, ниһаять, «Син – гомер агышларым»...

Йотлыгып шигырьне укырга керешәм. Бу китап кулыма килеп кергәнче «Син – гомер агышларым» шигыренең ничек җырга әйләнү тарихы турында шактый мәгълүмат туплап өлгергән идем инде. Кем белән генә аралашсам да, һәркемнең бу җыр белән бәйле тарихы, мәхәббәте, истәлекләре күп булып чыкты. Туганда ук гади генә җыр булып тумагандыр ул. Аның асылында серле дә, бүгенге көн өчен инде чак кына сәер тоелган шагыйрь мәхәббәте тарихы салынганлыгын соңрак аңладым.

Фото М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры архивыннан алынды.

Кышкы романс

Акты ярсып, акты ташып кар сулары,
Шулдыр инде язның шашып ярсулары.
Акты безнең кар өстендә калган эзләр,
Акты елап, икәү бергә салган эзләр...

Кушымта:
Син — гомер агышларым,
Син — минем сагышларым,
Син — минем шатлык илем,
Югалту-табышларым.
Син — гомер агышларым.

Язлар килә, язлар китә, сулар ага.
Агым сулар кебек, айлар, еллар ага.
Суларның да, айларның да, елларның да
Агышыннан эзләр кала, эзләр кала.

Кушымта.

Менә инде тагын җиргә карлар ява,
Бөтен нәрсә калган төсле кар астында.
Ага сулар, айлар ага, еллар ага,
Сине күрәм айлар, еллар карашында.

Кушымта.

«Син – гомер агышларым» җырын безнең буын «Кышкы романс» дип белә. Җыр беренче тапкыр җитмешенче елларда М. Гафури исемендәге Башкорт академия драма театры сәхнәсендә яңгырый. Көр тавышы, бер карашы белән тамашачыны үзенә гашыйк иткән яшь җырчы Фидан Гафаров башкара аны. «Ул вакытта композитор Рим Хәсәнов белән театрда бергә эшли идек. Наҗар аганың «Син – гомер агышларым» шигыренә көй минем тавышка атап язылды. Җырны беренче тапкыр сәхнәдән башкарганымны хәтерлим. Тамашачы бу җырны күтәреп алды, алкышларга күмде, залда аңлатып бетерә алмаслык бер халәт, тетрәнү узды. Аңа чаклы мондый стильдәге җырлар юк иде бит әле! Халык өчен генә түгел, җырның авторлары өчен дә зур тетрәнү бар иде бу җырда. Күпмедер вакыттан соң җырны оркестрга җырлап, радиода яздырырга булдык. Репетициягә җыелдык. Әле дә күз алдында, җырның беренче куплетын гына җырлап бетергәндә карыйм, безгә режиссерлык итеп торган Рим Хәсәнов нык тәэсирләнгән, күзләрендә яшь.... Репетицияне туктатып, Рим янына җыелыштык. Үз тарихы бар аның, ди. Әмма ул безгә билгесез булып калды. Менә шулай йөрәкләргә үтеп кереп, күңелләрне кузгата торган тирән эчтәлекле җыр булды ул. Беренче тапкыр башкарганнан бирле бер генә концертым да бу җырдан башка узмый. Репертуарга кертмәсәм, халык сорап булса да җырлата. Ул инде классик ретро җырга әйләнде, – дип искә төшерә Фидан Гафаров. – Бу – үлемсез җыр. Кайчак бу җырны яшь башкаручыларның җырларга тырышканын ишетәм дә, күңелсез булып китә. Бәгырьләрне өзеп, мәгънәсен аңлап башкара алмый торган җырларга тотынырга кирәкме икән?! Үлемсез җырларны бозып җырлауга каршы мин».

Җыр халык арасында бик тиз тарала башлый. Озакламый Казанга да килеп җитә. Тукай клубында узучы «Әдәби җомга» кичәсендә беренчеләрдән булып студент кыз Флюра Низамова башкарганын хәтерләүчеләр дә бар. Ә менә журналыбызның әдәби мөхәррире Эльмира апа Закирова болай искә төшерә: «1975 елда без студент чакта радиодан еш кына Фидан Гафаров башкаруында «Кышкы романс» җыры яңгырый башлады. Матур җыр! Һәркем сүзләрен эләктереп, отып калырга тырыша. Бауман урамындагы Матбугат йорты каршында пластинкалар ясап сата торган кечкенә генә «Звукозапись» кибете бар иде. Шунда, чират торып, «Кышкы романс» җырын яздырып алдык. Бәхеткә, безнең бүлмәдә проигрыватель бар. Бөтен тулай торакка яңгырарлык итеп Фидан Гафаровның «Кышкы романс»ын куябыз...»

Җыр популярлык казанып, китапларга кертелә башлагач, бер уңайсыз хәл килеп чыкканы ачыклана. Имештер, җырның кайбер сүзләре Мостай Кәрим шигыре белән тәңгәл килә икән. Бу урында Наҗар Нәҗминең Казанга, шагыйрь Рәдиф Гаташка язган хатына күз салыйк:

«Син – гомер агышларым» дигән җыр, җыр китабына керә калса (популяр җырлар китабы чыга иде бит! – *Р. Г.*) хәбәр ит әле, төзәтәсе урыннарым бар дигән идем. Чыннан да, бу җырга Мостайның (Мостай Кәрим турында сүз бара – *Р. Г.*) бер юлы кереп киткән. Ул юлны хәтерләмисеңдер дә. Ә җырның логикасы үзеннән-үзе шул фикерне китереп чыгара. Менә ул юл:

Язлар килә, язлар китә, сулар ага,
Көннәр ага, айлар ага, еллар ага
Суларның да, айларның да, елларның да
Агышыннан эзләр кала, эзләр кала.

Икенче юл аның «Ярлар кала» дигән шигырендәге юлларга туры килә. Мин аны «Агымсулар кебек айлар, еллар ага» дип төзәттем. Ә җырчылар беренче вариант белән пленкага яздырган да вәссәлам! Төзәтерлек җай юк. Казан китабына (җырлар китабына) керсә, төзәтермен дигән идем. Бу үзеңә генә язылган сүз. Әгәр дә китап чыга торган булса, мыегыңа урап куй әле шуны. Юлларның шулай туры килүе миңа бик уңайсыз, әлбәттә.

Ярый, хуш. Сәлам белән, Наҗар абыең.
14 август, 1977 ел».

Ихлас, эчкерсез кеше буларак, мондый хәл килеп чыгуына шагыйрь шактый борчыла, әлбәттә. Янәдән «Тарафтар» китабына күз салам. Монда шагыйрь телә-



гәнчә «Агымсулар кебек айлар, еллар ага» дип бирелгән. Әмма җырчылар аны барыбер беренче вариантта истә калдырган булса кирәк, бүген яңгыраган җырларда икенче юл төзәтелмәгән.

Серле җыр бу. Хәтта артык серле сыман… Язылу тарихы да, шигырь язуга этәргән мәхәббәт тарихы, хәтта әлеге язманы әзерләү тарихы да мең төрле сер чишүгә тиң булды. Инде җырның көе язылу тарихына күчик.

…Бервакыт Наҗар Нәҗми «Күршеләрдә кунак» спектакленең премьерасыннан соң театр труппасын Актерлар йортына кичке ашка чакыра. Шунда Рим Хәсәновтан яңа җыр язуын сорый шагыйрь. Композиторның куен кесәсендә кышның гүзәллегенә сокланып язылган бер көе бар икән инде үзе. «Ул вакытта мин солдат идем, – дип искә төшерә композитор. – Шәһәргә «увольнительный» белән чыккан вакыт. Хәрби частьта төнге каравыл алышынгач, клубка киттем. Җиргә төшкән кар бөртекләренә карый-карый пианинода уйнап җибәрдем. «Кышкы романс» шулай туды. Нәкъ шушы көйне Наҗар Нәҗмигә җырлап күрсәттем. Шагыйрь икенче көнгә очрашу билгеләде, музыканы бик ошатуын әйтте. Әзер көйгә җыр тексты язарга теләге барлыгын белгертте. Берничә көннән Наҗар Нәҗминең шигырен укыгач, тәнемнән ток узгандай булды. Бу гениаль шигырь иде! Аның белән Актерлар йортына киттек, һәм мин үзебезнең яңа гына язылган «Син – гомер агышларым» җырын ун тапкырлап җырлаганмындыр. Шагыйрь дә миңа кушылып җырлады, аның бик канәгать булуы сизелеп тора иде. Соңыннан Наҗар Нәҗми, язып тутырылган өч дәфтәр күрсәтеп, мине янә шаккаттырды. Болар безнең яңа җырның каралама вариантлары иде!»

Ә җырның сүзләре кемгә багышланган соң? Автор кемне «югалту, табышларым» дип атый?! Инде менә шул серле мәхәббәт тарихын ачыкларга кирәк иде. Кем белән киңәшергә, җеп очын кайдан табарга? Әлбәттә, Наҗар ага белән аралашып, күрешеп йөргән язучыларда сакланырга мөмкин бу сер. Марсель Галиев белән элемтәгә чыгабыз. Марсель абый бу тарихны шактый көрсенеп искә төшерә. Әлеге тарих аның «Рух» китабына язылган истәлекләрендә дә урын алган икән: «Наҗар ага тезе өстендә сабый кебек утырган тальян күреген сыйпап куйды, үзен уза алырдай җырчы булмаудан канәгать елмаеп, тагын бер кат халәтенә кайтып төште. «Их, егетләр, белмисез!.. – дип, башын чөеп, үз күңеленә үрелеп караган сыман, бер сулышлык ара хисләнеп алды да әйтмичә түзә алмады, – Казаннан ерак та түгел… Минем яшьлек мәхәббәтем яши бит. Утыз биш ел инде хат язышып торабыз. Күп кенә шигырьләрем аңа багышлап язылган. «Син – гомер агышларым», «Сиңа барам» кебек җырлар тууга да ул «гаепле». Мин аның үзен бер мәртәбә дә күргәнем юк. А-а-а, хатларын укып карасагыз икән… Һәр сүзеннән гөл тама…

Ни әйтик соң өлкән шагыйребезгә, мәхәббәт – кеше күңеленең иң серле могарәсе, аның ишеге төбендә чит-ятларны үрелдерми торган, күзгә күренмәгән ярсу җәлладлар сакта тора шул… Шагыйрь йөрәге картаймый, диләр. Мәхәббәт – бәлки, аның кырыс еллар аша олыгайганчы саклап килгән матур ялганыдыр, бәлки, ул аның беркайчан да янына барып җитәсе килмәгән илһамлы күңел учагыдыр. Моны аңлар өчен, бер гасыр яшәргә ашкынган ир йөрәгенең кан тибешен шигырь юлларыннан тыңлый белергә кирәктер…»

Наҗар абый чын хат остасы булган, озын, матур хатлар язарга яраткан ул. Димәк, җыр сүзләре дә – моңарчы беркайчан да күрешмәгән, бары тик хатларына язган асыл сүзләр аша үзенә гашыйк иткән серле гүзәл затка багышлана! Ул аның гомерлек хыялы, күңеле белән тудырган, аны мәңгелек җырлар иҗат итәргә канатландырган, хатлары белән үзенә гыйшык итеп торган эпистоляр образ булып йөрәгендә сакланган.

«Кышкы романс» – Наҗар Нәҗми, Рим Хәсәнов һәм Фидан Гафаров «өчлегенең» иң популяр җыры. Әнә бит быел 73 яшендә Рим Хәсәнов «Кышкы романс»ны әле кабат кларнетта уйнарга өйрәнгән. Композитор күңелендә кадерле урын алып тора торган аерым көй, аерым тарих бу, күрәмсең.

Бу җыр Айдар Галимов, Зәйнәб Фәрхетдинова белән Зөфәр Билалов, Рөстәм Асаев кебек җырчыларның репертуарында хәзер. Хәтерлисезме икән, шактый еллар элек республика җитәкчеләре, министрлар популяр җырчылар белән бергә җырлап, үзенчәлекле концерт күрсәткән иде тамашачыларга. Дәүләт эшлеклесе Зилә Вәлиева «Кышкы романс» җырын башкарды. «Безнең яшьлектә ул җырны җырламаган, белмәгән кеше юк иде. Бу җырны яздырган пластинкалар һәр өйдә булгандыр ул вакытта. Минем өчен бу җырның тарихы күренекле композитор Рим Хәсәнов исеме белән бәйле. Аның әле иҗат юлында күтәрелеп кенә килгән вакыты иде. Яшь, талантлы яшьләр ул чакта Уфада чыгып килүче «Ленинец» газетасы редакциясендә җыела. Иҗади яшьләр шау-шу килә иде монда! Рим дә яңа җыр иҗат итсә, беренче булып редакциягә килеп керә, музыкасын уйнап күрсәтә. Бик талантлы, нечкә күңелле кеше ул. Киләчәктә шлягер буласы җырларын беренче булып без ишетә идек! Янып йөргән яшьлек елларыбызның күңелгә уелып калган җыры ул безнең «Кышкы романс». Ул концертта нәкъ шул җырны сайлавыбыз да юкка гына түгел. Эшлекле сәфәрләрдән ашыгып кайтып, әзерләнүләр, «Казан егетләре» белән чыгыш ясаулар инде үзләре бер тарих булып калды», – дип искә төшерә ул көннәрне Зилә ханым.

Инде ничәнче көн бүлмәмдә «Кышкы романс» яңгырый. Урамда кар ява. Бу җырда кайнар сөю сагышы белән бергә кар исе, пар эзләрнең ап-ак җирне таптап, шаярып биюләре, аннан, тиздән аерыласын сизеп, бер-берсен сөеп кочулары, вәгъдә бирми генә пар эзләрнең ике якка аерылуы һәм яңадан йөгереп килеп бер-берсенә сыенулары сизелә сыман. Кыш көне язылган шигырьдер бу. 1974 елның битне чеметә торган салкын кышы булгандыр ул…



« Әлеге видеода Фидан Гафаров «Кышкы романс» җырын башкара. 1975 нче еллар. Видео «Башкортостан» ГТРК архивыннан алынды.



Гөлүсә БАТТАЛОВА, шагыйрә, Г. Тукай исемендәге Әтнә Татар дәүләт драма театрының директор урынбасары

Былтырның язында «Безнең җыр» проекты старт алды. Оештыручылар мине әлеге проектка чакыргач, үземне сандугач, былбыллар арасына килеп эләккән бер ала карга кебек хис иттем. Моңа кадәр җыр сүзләре авторы булу гына түгел, хәтта минем шигырьләргә көй язып була дип тә уйламый идем. Проектка килгәндә борчылдым да, дулкынландым да.

Жирәбә белән төрле командаларга бүленеп эшләдек. Һәр командада бер җырчы, шагыйрә һәм композитор. Беренче этапта «Көтмә син» җыры туды, ә икенче этапта Эльза Заяри, Миләүшә Хәйретдинова белән иҗат иттек. Миләүшәнең «Синсез яшәргә» шигыремә язган көен ишеткәч, аһ иттем, дөньякүләм танылган фильмның саундтрегы кебек кабул иттем аны. Эльзага да бик ошады ул. Җырчы, композиторларның текстка шул дәрәҗәдә игътибарлы булуы, сүз тәмен белүләре сокландырды да, гаҗәпләндерде дә. Гомумән, «Безнең җыр» проекты идея өчен яшәүче, татар җыр сәнгате алга китсен өчен тырышучы энтузиастларны җыйды дип аңладым. Әлеге проект безгә – шагыйрьләр, композиторлар, җырчыларга бергә аралашу, бер иҗади казанда кайнау мөмкинлеге дә бирде.

Аллага шөкер, 2020 ел бик уңышлы булды. Г. Тукай исемендәге Әтнә Татар дәүләт драма театрында минем пьеса буенча «Җомга базары» музыкаль манзара спектакле сәхнәләштерелде (режиссёры – Рамил Фазлыев). Бу әсәремне ТАССРның – 100, Әтнә районы оешуының 30 еллыгына багышланган иде. Мин моны драматургиягә кереп китү димим, ә беренче талпынышым дип кенә билгеләп узасым килә. Татарстан китап нәшрияты тәрҗемә дөньясына тартып кертте: Якут шагыйрьләрен, Есенинны тәрҗемә иттем. «Тарих иләде, татар иләнде» шигъри циклым туды. Киләчәктә дә иҗат тормышында кайнап яшәргә язсын!

мәдәният « СОКЛАНДЫРДЫЛАР-2020

Концертларда тыйнак кына баш иеп, пианино артына чыгып утыручы яшь композитор Миләүшә Хәйруллина турында: «Ул безнең татар музыкасына, мәдәни мирасыбызга космик биеклектән карый ала торган иҗат әһеле. Аның интерпретациясендә татар моңы галәм күләменә чыга», – диләр. Быел «Безнең җыр» проектында катнашып Миләүшә зур уңышларга иреште.

– Быел зур сәхнәләрдә яңгыраган җырларымның күбесе Гөлүсә Баттал белән бергәләп иҗат ителде, – ди Миләүшә. – Аның белән «Безнең җыр» лабораториясендә танышкан идек. «Синсез яшәргә» дип аталган беренче җырыбыз махсус Эльза Заярига атап язылды. Җырны иҗат иткәндә Эльзаны башкаручы буларак драматик амплуада күрдем. Ягъни шул шигырь юллары миндә аерым хисләр уятты, иҗади эзләнүләргә этәргән илһам импульсы бирде.

Күптән инде Казаным турында бер матур җыр язарга хыяллана идем. Бу хакта Гөлүсәгә дә әйттем. Шулай итеп икенче иҗат җимешебез – «Казан» җыры туды. Эльзаның ире Артур Исламов, җырны ошатып, дуэт итеп яздырырга тәкъдим итте. Хәзер инде бу җырны әлеге дуэт башкаруында гына ишетеп

Миләүшә ХӘЙРУЛЛИНА – Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе аспиранты, күпсанлы халыкара һәм Бөтенроссия конкурслар лауреаты, композитор, педагог һәм пианист



була төсле, бик отышлы килеп чыкты ул! Шулай итеп, «Казан» җыры аша без Артур Исламов белән дә таныштык. Артур безнең алга янә бер иҗади бирем куйды. Шулай итеп «Кем идек» җыры туды.

Искиткеч талантлы кешеләр белән таныштырып торганы өчен тормышыма бик рәхмәтлемен. Алар иҗатымны баета, илһамлы мизгелләр бүләк итә. Бу ел яңа җырларга, иҗади ачышларга бай булды. Киләчәктә дә бергәләп иҗат итәргә насыйп булсын!



Фото: www.pixabay.com

УМКА



Асия ЮНЫСОВА

Ятимнәр йортына Индираны ике атна элек кенә китерделәр. Сәрхуш әнисеннән йолкып алганнан бирле кыз беркем белән дә сөйләшми. Әмма үзе ятимнәр йортындагы тормыш агышын каш астыннан гына күзәтә. Бала түзеп булмаслык шартларда да түзәргә, яраклашырга күнеккән булырга охшап тора. Әйе, ул әлегә күзәтә. Кемнең – аңа, аның кемгә көче җитәрен чамалап утыра. Тормыш аның өчен – туган көненнән алып көрәш мәйданы. Ул берәүдән дә рәхим-шәфкать көтми, ахрысы.

Ялгыша бала. Үзе кебек мәхрүмлекләр татыган сабыйлар арасында да сабыйлык сафлыгын югалтмаганнар очрап тора ул. Әнә шуларның берсе Индирага якын ук килеп баскан да кызны күзәтә. Күзәтеп арыгач, тел очындагы соравын ишеттереп әйтеп куйды: «Исемең бармы синең? – Җавап ала алмагач, якын ук килеп, кызның чәченнән сыйпап алды. – Син матур! Киемең дә матур».

Киеме матур шул. Кичә бер апа белән абый килгәннәр иде. Шулар ак йомшак кофта кидереп киттеләр. Индира кофтаны яратты. Кигәннән бирле салмый. Әле дә ак кофтасыннан: аякларын тездән генә бөкләп, йомран кебек утырып тора. Шулай селкенмичә чүмәшеп утыргач, чыннан да йомранга охшап тора бугай ул. Тик моны кыз үзе белми. Йомран күргәне бармыни аның. Ул яшәгән өйдә телевизор-фәлән, китап-мазар юк иде. Индира урман барын белә – әнисе аны җиләк җыярга ияртеп йөртә иде. Җиләк сатып ипи ала торган-

нар иде. Ипидән калганына – аракы...

«Киемең матур» дигән малай кабат әйләнеп килде. Кабат кызга текәлде. Йә, ни кирәк инде аңа? Берни дә кирәкми икән. «Син үзең дә матур», диясе генә килгән икән. Индира үзенең алтын чәчле, зәңгәр күзле матур кыз икәнен белми. Аңа бу хакта әйткән кеше булмады. Ә менә малай белә икән. Әнә бит күзен ала алмый: «Син Умкага охшаган!»

Умка! Акыллы дигән сүз бугай инде ул умка.

– Умка кем ул? – Кызның теле ачылды.

– Бозлар арасында яшәүче ак аю баласы. Белми идеңме әллә?

– Ә аны әйтәсең икән. –

«Белмим», димәде. Әмма шул көннән Умка турында гына уйлый башлады. Ул – Умка! Бозлар арасында озак яшәде ул. Тик үзенең ак аю баласы булуын бүген генә белде.

Тиздән Яңа ел җитәсе икән. «Кыш бабайга хатлар языгыз. Сезгә нинди бүләк алып киләсен белмичә йөдәп йөрмәсен», – диде тәрбияче апа. Ятимнәр йортындагы балалар сөенә-сөенә хат язарга керештеләр.

Рәмзия эш белән Казанга килгән җиреннән базарга да кереп чыкты. Һи-и, монда хикмәт икән! Яңа ел алды сәүдәсе гөрли. Өй түренә кайтып басасы чыршыларның кайсын туен көткән кәләш сыман бастырып куйганнар. Кайсыларын, шпагат белән кат-кат урап, бәбәй кимәлендә тезеп салганнар. Халык ала. Шул чыршылар белән кешеләрнең өйләренә бәйрәм кайта. Чыршы кайткан өйләрдәге балалар өчен шатлык булып керә инде бу урман кызлары.

Их, Рәмзиянең дә болын кебек өе чыршы тирәли әйлән-бәйлән әйләнер өчен бер дигән, иркен дә бит. Чыршыга сөенер сабыең булмагач, чыршы бизәүнең кызыгы юк шул. Төшләрендә күреп йөдәгән кызлы була алмады хатын. Шуңа күрә гомере дә заяга уза кебек тоела үзенә. Бәйрәм саен гына түгел, һәр ял саен диярлек туган-тумачасы килеп тора инде өенә.

Әле алар дөньяда Кыш бабай дигән мәрхәмәтле бабай барлыгына чын күңелдән ышана беләләр иде.

Шуларны көйләп, үзе бәйрәм итү түгел, эш атнасыннан соң ял да итми кала торган иде. Быел, соңлап кына дигәндәй, тиң яры белән кавышкач, кызлы булу хыялы тагын уянды. Хыялын сөйгән яры белән дә уртаклашты. Тик яше олыгаеп китте шул инде Рәмзиянең. Үзе тапкан нарасыен кулга алулар насыйп булмастыр инде. Хәләле дә аңлый моны. Әмма чын ирләрчә тәвәккәл дә соң инде үзе. Бер көнне әйтә бу: «Әйдә, бер җиргә кереп чыгыйк әле, – ди. – Анда сине кызың көтеп тормый микән?!»

Ятимнәр йортының ишегеннән атлап керүгә Рәмзиянең тез буыннары йомшап китте. Ничек моңарчы уйламаган ул бу хакта? Ничәмә ничә бала ана назына тилмереп яши икән ләбаса!

Хәләле ымлап кына бер кыз балага ишарәләде: «Синең төшләреңә кергән кыз шул түгелме, янәсе?» Рәмзия үзе дә шул баланы аерымлап алган иде.

Бала янына буш кул белән якын киләсе түгел, дип, бик матур ак кофта, тәмле конфетлар чыгып алдылар да кабат әйләнеп керделәр. Индира – шул үзе, хыялдагы кыз иде. Кофтага шатланды кебек, конфетларны ашыгып-ашыгып яшереп куйды. «Безгә кунакка барасыңмы?» – дигән сүзләре һавада эленеп калды. «Безнең кыз буласың киләме?» – дип сорарга иртәрәк иде әле.

Инде менә Рәмзия белән Кәрам, зур йомышлы кешеләр кебек, Яңа ел алды ыгы-зыгысына чумган Казан кибетләрендә йөриләр. Каян гына табасы икән ул ак аю баласын. Зуры кирәк икән бит әле кызга! Аларның бик тә иркә, бик тә кадерле булачак кызларына! Йөри торгач, түшенә йөрәк чигелгән ак аю табылды бит тәки. Зурысы. Йөрәк сурәте дә нәкъ урынында кебек тоелды. Йөрәк эше йөртә бит инде аларны да. Өй түренә зур чыршы куясы гына калды. Хәзер инде Яңа ел мәшәкате Рәмзия белән Кәрамгә бик ямьле мәшәкать булып тоела башлаган иде.

Чыршы бәйрәменә барлык туган-тумачаны бала-чагалары белән җыярлар, һәрбарчасына Кыш бабай бүләге әзерләп, чыршы төбенә тезеп куярлар. Өй түрендә ялтыр уенчыклар белән бизәлгән чыршы басып торыр. Кәрам Кыш бабай булып киенер, Рәмзия үзе Кар кызына әйләнер.

Шулай булды да. Тиздән кадерле кызларына әйләнәчәк Индираны алар бизәкле чанага утыртып алып кайттылар. Кайтуга, Кар кызыныкы сыман ак күлмәк кидереп куйдылар. Кызның зәңгәр күзләрендә чыршы уенчыкларыннан чагылган нурлар кабынды. Ниһаять, бала кыска гомерендә беренче мәртәбә чын бәйрәм уртасында калды. Яшел ылыс, алтын мандариннар исе аңкыган дөнья бик гүзәл икән ул! Кинәт кыз Умканы күреп алды. Кыш бабай аның бу йортка кунакка киләсен кайдан белде икән соң? Әллә монда тылсым ияләре яши микән? Ләкин ул әле уйлаганын әйтерлек халәттә түгел иде. Аның күңел тышауларын чишәр өчен яңа әти-әнисенә байтак тылсым серләрен өйрәнергә туры киләчәк иде әле.

Чыр-чу килеп уйнап йөргән, бүләк барлаган бала-чага бер дә ялыктырмый икән ул. Сабыйлар шатлыгы татлы шатлык була икән. Араларында үзеңнеке дә булганга күрә инде ул.

Инде менә дистә елдан артык Умка – Индираның иң яраткан сердәше. «Минем Кыш бабайдан бүләккә ак аю баласы көткәнемне кайдан белдегез?» – дип бер дә сораганы булмады. Яңа ел сере булып калды ул.

DRESSA

ГАИЛӘНЕ ЮМОР САКЛЫЙ



Әсхәт – җырчы, фитнес-тренер;
гаилә стажы – 20 ел;
балалары – Лилия, Эльвина, Ләйсән, Әмирхан;
оныгы – София.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Чибәр, зифа буйлы, үзен-үзе карап йөргән, матур киенгән хатын-кызга карамый булмый. Күзләр шуның өчен бирелгән. Әмма йөрәккә үтеп керер өчен бу гына җитми. Кешенең күңеле матур булсын. Моны белү өчен биш минут сөйләшеп алу да җитә. Аннан күзләренә карыйм. Майлап, янып торган күзләрне яратмыйм. Күзләр тыныч икән, тормышы да тыныч кына ага дигән сүз. Андыйлар белән аралашу да рәхәт. Бите ясалган хатын-кызларның күңеле дә ясалма, алар белән нәрсә турында сөйләшмәк кирәк?!

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Бөтен нәрсәне гафу итәсең, чөнки яратасың. Ошамаган сыйфатлар турында сөйләшеп була, зирәк хатын-кыз нәтиҗә ясамый калмый. Беребез дә идеаль түгел.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Берсүзсез, хыянәт! Хатын-кыз хыянәте бик куркыныч. Уҗымга чыгып керүче ирләр күп. Әмма алар барып кайталар да, оныталар. Ә хатын-кызныкы башка. Алар бөтен җаны белән хыянәт итә. Шуңа да аны гафу итеп булмый. Мин уздым хыянәтне. Нәрсә икәнен беләм. Моны беркемгә дә теләмим. Аллам сакласын! Агуга тиң ул. Ир-ат өчен моннан да көчле психологик яра юк дип уйлыйм. Бар да астыөскә килә: дөнья да, мөнәсәбәтләр дә, хәтта үзең дә. Бернәрсә дә күрмисең, ишетмисең, ашамыйсың, кислород җитми. Бөтен нәрсәгә әзерсең. Ул ирне бәреп үтерү дә берни тормый кебек.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсы якынрак?

– Икесе дә якын. Хатын рухландырып торсын инде ул. Аның хуҗабикә генә булуы кызыксыз булыр иде. Өеңдә ашарга пешкән, ди, әмма хатының белән сөйләшер сүз юк, чөнки ул дөньядан артта калган, берниндн дөньяви тренд белән кызыксынмый. Андый хатын белән яши алмас идем. Ашауга гына бәйләнмәгән бит ул тормыш. Хатын хисләндереп тора икән, таулар күчерергә әзермен. Нигә яшереп торырга, дөньяны ир-ат кулы белән хатын-кызлар идарә итә. Алар сүзе белән сугышлар да чыга. Бөтенебез дә рухландыручы хатын-кыз авызына карап яшибез.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әлбәттә. Минем өчен хатыным Айгөл дус та, туган да, хатын да, сөяркә дә. Аның белән теләсә нинди темага сөйләшә алабыз. Танышларым күп, аралашырга бик яратам, әмма дусларым юк. Беркемне дә үземә якын китермим. Бәйле булырга яратмыйм. Кешеләргә ышанмыйм. Якын кеше сиңа бервакытта да начарлык теләми. Ә дус бүген бар, иртәгә юк... Бу – мин-минлек түгел. (*Уйланып.*) Балачактан шулай. Ә якын танышларым барысы да шәп кешеләр! Миңа алар белән ерактан торып аралашу уңайлырак.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Айгөлне беренче тапкыр дуслар белән бер эшмәкәргә кунакка баргач күрдем. Түгәрәк кысалы күзлек кигән, тыныч кына йөргән үсмер кызга карап: «Бу кызга өйләнер идем», – дип уйлап куйган идем. Сигез елдан соң Казанда шул дусларым белән төнге клубка баргач, Айгөл белән тагын очраштык. Танымадым. Үсмердән бик чибәр кызга әйләнгән. Уртак танышларыбыз гына Айгөлнең кем икәнен исемә төшерде. Кич буе рәхәтләнеп биедек. Аннан бергәләп дусларны кунакханәгә илттек. Айгөлгә әйтәм: «Минем зур караватым бар. Әйдә миңа», – дим. Ул: «Юк, мин үз караватымны яратам. Өйдә генә йоклыйм», – ди. Аптырап киттем. Миңа бер кызның да каршы килгәне юк иде. «И Аллам, әле бозылмаган кызлар бар икән», – дип, шатланашатлана өенә илтеп куйдым. Әгәр ул төнне миңа килгән булса, безнең аралашу шуның белән тәмамланыр иде. Икенче көнне пейджерына (ул заманда кәрәзле телефоннар юк иде әле) хәлен белешеп хәбәр җибәрдем. «Итле белен пешерәм. 15 минуттан килсәгез, өлгерерсез», – дигән җавап килде. Өйдән өч минутта җыенып чыгып киттем. Аның фатир ишегендәге кыңгырауга басканда 15 минут узмаган иде әле. Очрашып йөргәннән соң бергә яши башладык. Аерылган идем ул вакытта, кабат законлы тормыш

башларга курыктым, яралар да төзәлмәгән иде бугай. Айгөлле тормыш бөтенләй башкача иде. Өемә җылы кертте ул. Үкенечем: матур итеп тәкъдим ясамадым. Йөзекне алып кайттым да кулына тоттырдым. Ул вакытта кыргый җәнлек кебек идем, романтика бөтенләй юк. Хәзер генә кино карасам да елыйм, Айгөл җебетте. (*Көлә.*)

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Ул хакта уйлаганым булмады. Әмма бик яхшы беләидем: хатыным дөньяда бердәнбер булачак. Хәзер улыма да әйтәм: «Үскәч, әниең кебек бик яхшы күңелле, нәфис хатын ал», – дим. Моны чын күңелемнән телим!

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Карьера дип тырышкан, йә бизнес алып барган хатыннар турында сүз барадыр. Уйлап карагыз: хатын-кыз күп акча эшли икән, димәк, тәүлек дәвамында эш турында уйларга мәҗбүр, аның гаиләгә, балага, иренә, көнкүрешкә вакыты калмый. Айгөлнең дә күбрәк эшләгән вакытлары булды. Өйдә тынычлык, ямь булсын, хатыным һәрвакыт елмаеп торсын, эштән алҗып кайтмасын. Гап-гади гадәти тормыш ошый миңа.

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Моның бер начарлыгын да күрмим. Төрле кешеләр бар бит дөньяда. Аңлату гына түгел, мәхәббәтне тоярга да кирәк бит әле. Миңа беренче булып мәхәббәт аңлатканнары булмады үзе. Гомумән, мәхәббәткә ышанмый идем. Айгөл белән яши-яши генә аның нинди көчле хис икәнен белдем. Балабыз тугач, таныш булмаган хис урап алганын аңладым: канатлар үсә, ул кешене күрүгә эчке импульслар уйный башлый. Мәхәббәт йомгагы елдан-ел зурая гына.

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Үзенә ышанган ир-атны бер хатын-кыз да игътибарсыз калдырмый. Күз алдыгызга китерегез: горур гәүдә, карашы – аяк астына түгел, ачык һәм еракка төбәлгән, җиңел, тыныч кына атлый. Әлбәттә, аңа карыйлар.

11 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Игътибарсыз калмаганыма шикләнгәнем булмады. (*Рәхәтләнеп көлә.*) Бицепсларымны күрсеннәр иде дигән уйны башыма да китермим. Үземә ошыйм, комфортлы хис итәм, нигә миңа кемнеңдер игътибары?!

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Юк, куркытмый. Хатын-кызда әлеге ике сыйфат та булса, кайф инде ул! Минем Айгөл чибәр дә, акыллы да, бер грамм да куркытмый (*Рәхәтләнеп көлә.*)

13 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

Яши башлаганда үпкәләп елап ушларны ала иде. (*Көлә.*) Гаебемне аңламыйм, аннан сорыйм, ә ул: «Үзеңнең башыңа килмәсә, минем әйтүдән ни файда», – ди иде. Хәзер алай үпкәләүләр бетте инде. Хатын-кызның нидер әйтеп бетермәвен аңламыйм. Әйтмичә, эченә үпкәсен җыеп йөргәннәрне кабул итә алмыйм. Үзем ни уйласам, шуны әйткәнгәдер, мөгаен. Турысын әйтәм дә салам. Миңа да турысын әйтергә кирәк. Ирләр, хатын-кызлар кебек, юк кына әйберне дә уйлап, анализлап йөрми.

14 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора. Сез нишлисез инде? Кафега чыгып китәсез яки пиццага заказ бирәсез? Тиз генә үзегез берәр нәрсә пешерәсез?

– Эшләп алҗыган икән, сүз юк. Үзем пешерәм. Мин йомырка тәбәсен шундый тәмле пешерәм, аны бөтенесе ашаячак. (*Көлә.*) Эшсезлектән арып иркәләнеп ятса, ачу чыгар иде. Андый хатын белән яши дә алмас идем.

15 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан. Бу сезнең ачуны китерәме? Китерә икән, бу хәл белән ничек көрәшәсез?

– Ачу ничек кенә кайный әле! Үзем дә соңга калырга яратмыйм! Көтәргә дә яратмыйм. Беркөнне театрга җыендык. Спектакль кичке җидедә башлана. Алтынчы яртыга киенеп куйган идем инде. Айгөл киенү түгел, бизәнә дә башламаган. Безнең өйдә юмор күп бит. «Син кая җыендың?» – ди, көлә-көлә. «Театрга, син соңга каласың», – дим. Көлештек шулай. Ул әзерләнә, мин өй буйлап әрлебирле йөрим. Йөрдем-йөрдем дә, машинага чыгып утырдым. Музыка тыңладым. Көтеп ялыккач, тагын нервландым. Кычкырта башладым. Ул көлә-көлә машинага чыгып утырды да: «Нәрсә кычкыртасың, тик кенә утыра белмисеңме әллә?» – ди. Мин дә көлеп җавап бирдем. Шуның белән бөтен ачулар онытылды. Әгәр мин мыр-мыр килсәм, ул җавап бирсә, тигез җирдә тавыш чыгарга мөмкин иде. Икебезнең дә юмор хисле булуыбыз коткара. Гомумән, юмор күпмедер күләмдә гаиләне саклый ул!

16 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә. Сез алган бүләкләрнең иң ошаганы һәм ошамаганы?

– Әби белән икебез дә Укчы йолдызлыгында туганбыз. Бүләк бирә белмибез. Әби дә өстәлгә акча китереп куя да китә. «И әби, мин сине аңлыйм», – дим. Бүләк ала башласам, монысын ошатмас, тегесен очсыз дияр дип шикләнә башлыйм. Шуңа күрә акчалата бирәм. Киемнәрен, бриллиантларын үзе сайласын. Ә Айгөлнең 20 ел бергә яшәү дәверендә ошамаган бүләк биргәне булмады. Бөтенләй! Бу игътибарлылык инде. «Ничек син шундый кирәкле бүләкләр генә бирәсең соң?» – дип сорыйм кайчак. «Кешене аңларга кирәк», – ди. Ул, күрәсең, «Эх, бу әйбер кирәк!» дип әйткәнне хәтеренә салып куя, ә минем бер колактан керә, икенчесеннән чыгып китә ул. Айгөл бик күп бүләкләр бирде, әмма беренче бүләге истә калган. Ул вакытта бергә яшәми дә идек әле. Фатир ачкычларым, тарау йөреп, чалбар кесәсен тишә иде. Бу хакта әйткәнем булгандыр, күрәсең. Туган көнемә күннән эшләнгән ачкыч савыты бүләк итте. Шаккаттым. Иң кирәк әйбер бит ул! Каян белгән икән дип уйладым. Ул вакыттан күпме еллар узган, ачкыч савыты искереп бетте, әмма ыргытмадым. Шкафта саклана ул. Минем өчен иң кадерле һәм кәттә бүләк!

Тулысынча укыгыз »





«Балагызның гемоглобины төшеп киткән». Табибтан бу сүзләрне күп кенә әти-әниләргә ишетергә туры киләдер, мөгаен. Югыйсә баланың туклануын да начар дип әйтеп булмый, ә менә анемия күзәтелә. Моның сәбәпләре һәм кисәтү юллары хакында Республика балалар клиник хастаханәсенең 3 нче поликлиника табибы, КДМУның госпиталь педиатрия кафедрасының ординаторы Мария ПЕТРОВА белән сөйләшәбез.

АНЕМИЯ НИЛЕКТӘН БУЛА?

Анемия, ягъни азканлылык – кан күләме берәмлегендә гемоглобин һәм эритроцитлар концентрациясенең кимүе ул. Аның бер сәбәбе – үз яшәү дәверендә эритроцитларның төрлечә зарарлануы, «ватылуы». Бу зарарлану нәселдән дә булырга мөмкин, яшиләш дә барлыкка килүе ихтимал. Азканлылыкның төрләре күп. Балаларда исә тимер кытлыгы белән бәйле булганы ешрак очрый.

Диагноз баланың кан анализында эритроцитлар һәм гемоглобин күләменә карап билгеләнә. Аның нормасы төрле яшьтә төрлечә, шуңа да төгәл диагнозны бары табиб кына куя ала. Эритроцитлар һәм гемоглобинның кимүе организмда тимер кытлыгының зур булуын һәм организм әлеге микроэлементның җитмәвен үзлегеннән генә компенсацияли алмавын күрсәтә. Диагнозны мөмкин кадәр иртәрәк билгеләр өчен башка төрле анализлар да алынырга тиеш.

Дәва билгеләр алдыннан анемиянең нилектән килеп чыгуын ачыклау мөһим. Тимер җитмәү аркасында барлыкка килгән очракта тимер препаратлары билгеләнә. Әлеге төр анемияне бары диета ярдәмендә генә дәвалавы мөмкин түгел. Дару препаратларын табиб билгели, бәләкәй балаларга аның сироп рәвешендәгесен бирү уңай. Тимер тозлары препаратлары ашарга бер сәгать кала кулланыла. Аны аскорбин һәм фолий кислотасына бай продуктлар белән берләштереп кабул итәргә мөмкин, чөнки бу кислоталар тимернең яхшырак үзләштерелүенә булыша. Ә менә чәй, кофе, сөт һәм сөт продуктлары, кальцийга бай ризыклар, киресенчә, тимернең үзләштерелүен тоткарларга сәләтле. Тимер препаратларын кабул итүне тиешле күрсәткечләргә ирешкәннән соң да берникадәр вакыт туктатмаска кирәк, кандагы тимер депосын җитәрлек тулыландыру мөһим.

Тимер җитмәүгә бәйле анемиянең сәбәпләре
- организмга тимер микроэлементының җитәрлек кермәве (тиешенчә тукланмау, ашказаны-эчәк трактында тимернең тиешенчә үзләштерелмәве);
- организмның тимерне кергәненнән артыграк куллануы (ялкынсыну процесслары, суалчаннар һәм паразитлар белән зарарлану аркасында);
- тимернең организмнан читкә чыгарылуы (кан югалту, ашказаны-эчәк тракты җәрәхәте).

Анемиянең билгеләре
- тән тиресенең һәм тәндәге лайлалы тышчаларның аксыллыгы;
- чәчләр, тырнакларның тиз сынуы, тән тиресенең корылыгы;
- баланың хәлсезлеге, тиз аруы;
- ризык үзгәләве – ком, акбур, туфрак ашавы;
- ис тою үзгәрү – буяу, ацетон исләренә тартылуы;
- баланың күз аллары караңгыланудан зарлануы;
- бала кайчак аңын да югалтырга мөмкин.


ДРКБның матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

✓

Балада анемия булмасын өчен:
- рационда терлек һәм кош ите, терлек бавыры;
- балык һәм диңгез продуктлары;
- йомырка;
- карабодай, солы, арпа, арыш, бодай көрпәсе;



- кызыл чөгендер, шпинат, брокколи, спаржа, кукуруза, фасоль, ясмык, борчак;
- чикләвек һәм көнбагыш;
- каражимеш, күрәгә, йөзем, инжир булсын.



Бу мөһим:
Азканлылыкның онкологиягә китерүен раслаган мәгълүматлар юк. Әмма анемия озакка сузылса, организмда хроник гипоксия башланырга, организмның чирләргә каршы торучанлыгы кимергә мөмкин. Тимер кытлыгыннан барлыкка килгән анемияне кисәтү өчен тимер препаратларын табиб киңәше белән профилактик дозада кабул итәргә була.





Без тормыштагы 80 процент мәгълүматны күзләр аша алабыз. Һәр көнне кояш яктысын, күкнең зәңгәрлеген, җиһанның матурлыгын күрер өчен күзләребезнең сәламәт булуы кирәк. Югары категорияле табиб-офтальмолог, Республика клиник күз авырулары хастаханәсенең глаукома кабинеты мөдире, Россия глаукома җәмгыяте әгъзасы Ольга ЗВЕРЕВА белән җитди күз авыруы – глаукома турында сөйләшәбез.

ГЛАУКОМА СИЗДЕРМИ КИЛӘ

Глаукома – күрү нервларының хроник һәм акрынлап көчәя баручы атрофиясе. Ул – социаль әһәмияткә ия чирләрнең берсе, Россиядә күз белән бәйле инвалидлык алу очракларының күбесе нәкъ менә шуның аркасында. Авыручыларның уртача яше 55–60 тирәсе. 25–30 яшьлек кешеләрдә дә очрарга мөмкин, монысы инде тумыштан килгән аномалияләр белән бәйле.

Глаукома белән авыручы пациентның күрү сәләтен саклап калуның бердәнбер юлы – чирне башлангыч стадиядә үк ачыклау. Тик аның мәкерлелеге дә шунда – ул чорда әле бернинди дә билгеләре булмый. Аны гадәти поликлиникада ачыклавы да кыен, чөнки төп фактор саналган күз эчендәге югары басым баштагы чорда әле даими түгел. Табибка килгән көнне ул нормада да булырга мөмкин, ә күрү нервларында ниндидер үзгәрешләр әлегә сизелми. Алар чир инде зуррак стадияләргә күчкәч кенә барлыкка килә башлый, ә бу – якынча 10–15 ел дигән сүз. Менә шушында диссонанс килеп чыга да инде: пациент күзләреннән зарланмый, күрүе яхшы, симптомнар юк, ләкин аны нәкъ менә хәзер, күпчелек нерв җепселләренә зыян килгәнче үк дәвалый башларга кирәк. Вакыт барган саен, әлеге җепселләр эшчәнлеген югалтачак. Күзнең күрү сәләте начарлану глаукоманың төп билгесе түгел, чөнки күзнең үткенлеге иң соңгы стадиягә кадәр сакланырга мөмкин. Безнең организм шулай җайлашкан: бер күз күрмәсә, аны икенче күз тулыландыра. Глаукома вакытында күрү кырлары тарая башлый, ләкин кеше үзе аны берничек тә сизми. Зуррак стадияләрдә күздә буш таплар – скотомалар барлыкка килә. Ләкин баш мие ул тапларны үзе тулыландырырга сәләтле, һәм кеше үз алдындагы предметны тулаем күрә кебек тоела.

Глаукоманы тулысынча дәвалау әлегә мөмкин түгел. Әмма күзнең эчке басымын нормада тотарга булышучы дәва методлары чирне озак вакытка тоткарларга мөмкинлек бирә. Диагноз вакытында куелса һәм пациент табибның киңәшләрен тулысынча үтәсә, 90% очракта дәвалауның нәтиҗәсе була. Пациент һәм табиб үзара партнерлар булганда гына уңышка ирешү мөмкин. Чөнки әлеге чир еллар дәвамында табиб күзәтүендә булуны таләп итә. Кайбер очракта лазер яки хирургик дәва методлары да билгеләнә.

Билгеләре юк дисәк тә:
- күзләрнең авыртуы һәм бу авыртуның маңгайга күчүе;
- күзгә чүп кергән кебек тоелу;
- күз алмасының коры булуы;
- күзлекне ешрак алмаштырырга ихтыяҗ туып тору (ярты елдан да ешрак);
- күзнең күрү сәләте начарлану;
- күздә буш таплар – скотомалар барлыкка килү сагайтырга тиеш.

Белеп тору кирәк:
- глаукоманың көчәюенә китерүче төп фактор – күз эчендәге басымның артуы;
- күз алмасындагы сыекчаның чыгу юллары тараюы һәм чүпләнүе басымның артуына йогынты ясый;
- күз эчендәге басымның артуы күзәнәкләрнең иртә картаюына китерә;
- төп рольне нәселдәнлек уйный;
- глаукома – күпфакторлы чир;
- диагноздан куркырга кирәкми, башлангыч стадияләрдә ачыкланган очракта аны тоткарларга мөмкин.



Табиб киңәш итә:
- организмның иртә картаюын кисәтү ул – глаукоманы да кисәтү;
- актив тормыш рәвеше алып бару;
- күзләргә гимнастика ясау;
- дөрес туклану, яшел һәм сары төстәге яшелчә, җиләк-җимешләрне күбрәк куллану;
- гәүдәнең авырлыгын нормада тоту;
- физик активлык;
- күзләр эшләргә тиеш, ягъни күзләргә көч килмәсен дип, уку, телевизор карау, бәйләү, чигү кебек эшләрдән баш тартмагыз;
- глаукоманың югары стадияләрендә машина йөртүдән тыелу хәерле.



Республика клиник күз авырулары хастаханәсенең матбугат сәркатибе Рида Борһанова ярдәме белән әзерләнде.

PRESSA

Урамда нинди генә салкын җилләр уйнамасын, буран тузынмасын – Яңа ел көтелмәгән шатлыклар, могҗизалар, гаилә җылысы белән уза торган, бер-береңне бүләкләр белән сөендерә торган күңелле бәйрәм ул! Иң мөһиме: бәйрәмгә дөрес итеп алдан әзерләнү генә кирәк. Туасы ел Кытай календаре буенча – Ак металлы Үгез елы. Зәвыклы табак-савыты, металл төсендәге чыршы шарлары, бантлар, кипкән чәчәк-үләннәрдән кул эшләнмәләре, икебаналар куеп, мөмкин кадәр табигый чималдан эшләнгән декор бизәкләр белән өйне бизәп, Яңа елны каршылау – Үгез елын зур әзерлек белән көтеп алу дигәнне аңлата, һәм бу ел инде сезне, һичшиксез, яхшы хәбәрләре, уңай үзгәрешләре белән генә сөендерер! Тәрәзләрдән чыршы утлары җемелдәп күренә, чыршы уенчыклары хәрәкәткә килә, бүләкләр исемлеге төзелә торган күңелле вакыт бу! Өстәлдә – хуш исле әфлисун, мандарин, дарчин, канәфер салып пешерелгән чәй туңып кайтканнан соң тәнне җылыта, кәефләрне күтәрә. Телевизорны ачкан саен, «Ирония судьбы или, С легким паром!», «Карнавальная ночь», «Ёлки» фильмнарының таныш көйләре җанны иркәли...



Ә бездә – Яңа ел!

Раилә ХӘЯЛИЕВА

Бүген без кунакка Казанның Азат Аббасов урамында яшәүче Алсу ИБРАҺИМОВА гаиләсенә барабыз. Ул безгә өйдә гади һәм матур итеп ничек Яңа ел рухы тудыру турында сөйләр.

Без килгәндә өйнең хуҗабикәсе Алсу, кызлары Мәдинә һәм Амелия мәш килеп чыршы бизиләр иде. Кызлар чыршы уенчыклары белән мәш килгән арада, Алсу өй бизәү серләре, үзләренең яңа ел йолалары белән таныштырды.

– Минем өчен Яңа ел ул иң якын, кадерле кешеләр белән уздыра торган гаилә бәйрәме. Үзебезнең өйгә кунаклар чакырырга, матур итеп өстәл әзерләргә яратам. Өйне бизәү өчен базардан яшел чыршы ботаклары алып кайтабыз. Аларны вазага гына утыртып куйсаң да, өйгә хуш ис, Яңа ел яме биреп торачак. Мәшәкатьле булса да, өй бизәүгә балаларны да тартам. Алар һәрнәрсәдә могҗиза, матурлык күрә белә, ә син дөньяга алар күзе аша карый башлыйсың.

Балалар бүлмәсе

Бизәү өлешенә керешкәнче беренче эш итеп уенчыкларны, төрле ялтыравык бизәкләрне барлап куярга кирәк. Алар бер-берсен тулыландырып, үзенә күрә мәгънәви композиция килеп чыкса әйбәт булачак. Балалар бүлмәсен бизәгәндә, тәрәзәгә бергәләп бизәкләр төшерергә яки кәгазьдән төрле формалар кисеп, гирляндалар ясарга була. Бу бүлмәгә мөмкин кадәр табигый чималдан ясалган декор куллану әйбәт.

Әмма артык декор, купшылык балаларга комачауларга да мөмкин, шуңа күрә иң әйбәте – үзләре ясаган бизәкләр һәм матур гирляндалар. Кая гына элсәң дә, гирляндалар аерым бер тылсымлы халәт тудыра.



Аш бүлмәсе

Бәйрәмгә әзерләнгәндә иң зур игътибарны аш бүлмәсенә бирәбез, чөнки күп вакытыбызны биредә уздырабыз. Диварларга Кыш бабай рәсеме төшкән бизәкләр, гирляндалар эләбез.

Яңа ел өстәлендәге бизәкләр ак, кызыл, яшел төсләрдән торырга тиеш кебек. Җете төсләр белән бәйрәм рухы да арта. Без исә һәрвакыт шәмнәр куябыз. Сәгать төнге 12 не сукканда, теләкләр теләп, аларны сүндерәбез. Бәйрәмдә дә, гадәти көннәрдә дә аш бүлмәсендәге өстәлгә ак ашъяулык җәяргә яратам. Әнием аш-су әзерләргә өйрәтсә, кайнанамнан зәвык белән өстәл бизәргә өйрәндем. Ризыкны матур савытка салып, күзне иркәли торган итеп бизәп тә бирсәң, ул тагын да тәмлерәк була! Өстәлдәге салфеткалар белән кашык-чәнечкегә бәйләнгән ленталар төсе туры килергә тиеш. Тәлинкә араларына бәйрәм тематикасына багышланган салфеткалар куеп калдырабыз. Өстәл түренә дә яшел чыршы ботакларыннан композиция ясарга яратам. Бәйрәмне үз кулларың белән тудырсаң, тагын да кадерлерәк була ул!

Ишекләр

Яңа елга өй бизәгәндә ишекләрне игътибарсыз калдырмагыз! Безнең тормышка яңа энергия, яңа шатлык, үзгәрешләр, финанс ягыннан уңыш энергиясе – өй ишеге аша керә. Яңа ел алдыннан кайбер халыклар ишек төпләрен махсус юып-чистартып та чыга икән. Аңа кибеттән алынган яки үзегез ясаган кышкы бизәкләр эләргә була. Ишек башына чыршы ботаклары, күркәләр дә куялар. Мин үзем яшел ботаклардан такыялар ясап, аларга җилем ярдәмендә кечкенә генә чыршы бизәкләре беркетеп, өйдәге ишекләргә элеп чыгарга яратам.

Йолалар

Гаилә корган елыбызда чыршы алып, изге теләкләребезне теләп, аңа ике шар элеп куйдык. Беренче кызыбыз туган елны – өч яңа шар алдык. Хәзер инде без гаиләдә дүртәү. Һәр елны дүрт яңа чыршы уенчыгы алабыз, һәм һәркем үзенең теләкләрен әйтеп, үз уенчыгын чыршыга элә.

Безнең гаиләнең тагы бер йоласы: Яңа ел алдыннан дәү әниләребезгә куна кайтабыз. 31 көнне иртән торгач, һәркем чыршы астыннан бүләк ала, теләкләр укый, бәйрәм иртәсендә үк бер-беребезне менә шулай шатландырырга тырышабыз. Яңа елга якты хисләр белән керү – үзе бер ләззәт.

Һәр гаиләгә күңелле Яңа еллар, шатлык-куаныч, имин тормышлар телим! Онытмагыз, Яңа ел могҗизасына ышансак та, бәйрәм рухын беренче чиратта без үзебез тудырабыз!

Идеяләр

- Аяк киемнәреннән калган тартмаларны ташламый торуыгыз әйбәт булган! Аларны төрле төсле кәгазьләр белән тышлап, өстенә төсле тасмадан бант беркетеп, чыршы астына куярга була.
- Кечкенә чыршыны фетрдан үзегез дә ясый аласыз. Чыршы уенчыгы урынына ябышкак бизәкләр, мишура кулланырга була. Аның каравы, балаларның үзләре бизәгән чыршысы өй түрендә торачак!
- Өйне эреми торган боз сөңгеләре белән дә бизәргә була. Моның өчен ак фильц тукыманы алып, кыекка эленгән боз сөңгеләре формасында кайчы белән кисеп чыгабыз.
Кул астында булса, ялтыравык кар бөртекләре кадап чыгарга да була. Фильц урынына ак кәгазь кулланса гыз да була.



Фото: Анна Арахамия

Яңа ел үрдәге



Беседка
студия творчества
Мастер-классы по всем видам рукоделия
Кулинарные мастер-классы
Товары для творчества
Флористика
РЕКЛАМА
г. Казань, ул.Муштари, 2а
(843) 264-51-15, 236-40-64
www.studiobesedka.ru
г. Казань, ул. Абсалямова, 19
(843) 221-03-73

Исе һәм төсе үк бәйрәм халәтенә туры килгән әфлисун һәм алма белән тутырылган үрдәк – Яңа ел табынына иң тәмле ризык булыр! Бәйрәм сыен танылган яшь җырчы, Башкортстанның Илеш районы Яркәй авылы егете Айдар РӘКЫЙПОВ әзерләп күрсәтте. Үрдәкне Айдарның әнисе Лидия ханым авыл болыннарында үстергән. Шуңа да ул искиткеч тәмле килеп чыкты!
Быел кытай календаре буенча Үгез елы булгач, өстәлгә ит ризыклары куймаска киңәш итәләр. Ә менә кош итен авыз итәргә ярый икән. Шуңа күрә алма, әфлисунлап тутырылган үрдәк килгән кунаклар өчен менә дигән үзенчәлекле сый булыр!

Кирәк

- үрдәк;
- 3–4 әчкелтем алма;
- 2 әфлисун;
- лимон;
- тоз, борыч;
- 3 аш кашыгы бал;
- 2 аш кашыгы сыек май;
- 3–4 тырнак сарымсак.










Эш барышы

- Үрдәкне әйбәтләп юабыз.
- Ярган урыныннан эчке майларын кисеп алабыз.
- Алма, әфлисун, лимонны юып, телемләп бүләбез. Тоз-борыч салып барысын бергә әйбәтләп бутыйбыз, эчлек әзерлибез.
- Үрдәкнең тышкы ягына сөртер өчен соус болай ясала: балга вак итеп турап сарымсак, 2–3 кашык җылы су (су урынына үзегез яраткан соусны кулланырга да була), тоз, борыч салып, әйбәтләп бутыйбыз.
- Әзер эчлекне үрдәккә тутырабыз, артык калган өлешен аерым савытка алып куябыз. Аның әле кирәге чыгачак!
- Гадәттә, каз-үрдәкне тутыргач, кырый-кырыйларын энә-җеп белән тегеп куялар. Без җайлырак ысул тәкъдим итәбез: җөйләү өчен теш чистарта торган агач таякчыкларны кулланабыз *(рәсемдә күрсәтелгәнчә)*.
- Мичтә пешерә торган махсус савытка фольга җәябез. Үрдәкне куйганчы, башта артып калган эчлекне (алма, әфлисунны чиратлаштырып) түшибез. Үрдәк янып китмәсен өчен шулай эшләнә ул.
- Үрдәкнең тышына алдан әзерләп куелган соусны сөртәбез. Соус артык калса, эчлеккә салып җибәрәбез.
- Үрдәкне фольга белән әйбәтләп төрәбез.
- 200 градуска кадәр җылытылган мичкә пешерергә куябыз. Ике сәгатьтән үрдәк әзер була.
- Табынга чыгарганда үрдәкне анар төшләре һәм яшел тәмләткечләр белән бизибез.

Табыннар мул булсын!
Яңа еллар күңелле узсын!


Фото: Анна Арахамия




Тиздән Яңа елның сихри төне җитәр. Ә аңа кадәр уңган хуҗабикәләр көне буе аш бүлмәсендә кайнашыр. «Оливье» салаты ясар, мичкә каз куеп җибәрер, тагын бер кат эскәтерне, табак-савытларын карап чыгар, күзгә күренмәгән вак-төяк эшләр дә җитәрлек... Бәйрәм өстәле янына арып-талып килеп утырмас өчен, бездән сезгә менә дигән киңәш. Бәйрәм табынына «Гудакен» фермер хуҗалыгында җитештерелгән хәләл сертификатлы сый-нигъмәтләрне алыгыз!

- «утка-табака», «цыплёнок-табака»;
- кош итеннән рулетлар, ысланган ит;
- пилмән, манты;
- купаты, шашлык;
- яңа суйган тавык, үрдәк, күркә, каз итләре;
- һәм башка төрле бик күп полуфабрикатлар.

Яңа елны мул табын артында каршылыйк!






gudaken

+7-903-305-77-88
Осиново Юбилейная, 37 б

РЕКЛАМА

Кучкар. Яңа елның беренче ае мәхәббәт маҗараларына бай булыр. Гаиләдә мөнәсәбәтләр җайланыр. Шәхси бизнес белән шөгыльләнүчеләр өчен дә уңышлы ай. Актив аралашулар, очрашулар чоры.

Үгезбозау. Яңа елны яңа максатлар куюдан башлагыз. Үгезбозауларны зур үзгәрешләр көтә: кемдер – имиджын, берәүләр тормыш мәгънәсен үзгәртер, сәяхәткә китеп баручылар да булыр.

Игезәкләр. Эшегез акрын бара икән, һич борчылмагыз, вакыты шундый! Аның каравы, үзегезгә карата ышанычыгыз артыр. Иҗатыгыз акча китерә башларга мөмкин. Тормышның уңайга үзгәрә торган чоры, яңалыкларга әзер булыгыз!

Кысла. Хыялларыгызны чикләп яшәмәгез. Тормыш рәвешен фикерләү дәрәҗәсе билгели. Һәрнәрсә дә бик тиз үзгәрергә сәләтле, шуңа күрә хыялларга ышанып, алга баруыгызны дәвам итегез.

Арыслан. Энергиягез үсеп киткәнне тоярсыз. Барлык сорауларыгызга җавап – үзегездә, күңелегезне тыңлап карагыз әле! Тормышыгыздагы һәрнәрсәгә рәхмәтле булыгыз. Кичләрен тынычлап ял итәргә тырышыгыз.

Кыз. Ашыкмагыз, зур амбицияләргә бирелмәгез! Барысы да үз җае белән барсын. Тормыш тәҗрибәгез шактый, сез инде югалып кала торган кеше түгел. Бик продуктив ай булачак. Өстәмә акча килү мөмкинлеге зур.

Үлчәү. Гаиләдәге рәхәт халәт кышкы кичләрдә күңелегезне җылытып торыр. Энергетик вампирлардан сакланыгыз. Дөрес тукланырга тырышыгыз. Акча энергиясе артыр. Күбрәк аралашырга тырышыгыз.

Чаян. Башкалар фикеренә колак салып йөрүдән туктагыз. Тормышны үзегез теләгәнчә, үзегезнең кагыйдәләр белән җайлар чак җитте. Сәламәтлегегезгә игътибарлы булыгыз, йога белән шөгыльләнү килешер.

Укчы. Гаиләгезнең сезгә булган уңай мөнәсәбәтеннән көч алып, бәхетегезгә сөенеп яшәр чак. Сөенер сәбәпләр күп булыр! Ялгызлар үзләренә сокланып, читтән яратып йөргән кешеләре белән танышыр.

Кәҗәмөгез. Барлык эшләрегездә дә йолдызлар уңыш юрый. Ял итәргә, көч җыярга вакыт табыгыз. Үз-үзегезне гаепләмәгез, булган шатлыкларга шөкер итеп яшәү сезгә күбрәк көч бирер.

Сукояр. Якыннарыгыз белән мөнәсәбәтләрне ныгытыр вакыт җитте. Финанс ягыннан көтелмәгән шатлыклар килергә мөмкин. Ашкайнату системасына игътибар сорала, сәламәт яшәү рәвешенә күчсәгез әйбәт булыр.

Балык. Бу чорда сезгә бик актив булырга кирәк! Интуицияне эшкә җигегез. Маҗараларга бай командировкаларга бару, сәяхәтләр, яңа кешеләр белән танышу чоры. Яңа елга булган планнарыгызны кәгазьгә язып куярга онытмагыз!

ЯҢА ҮЗГӘРЕШЛӘР БЕЛӘН ҮГЕЗ ЕЛЫ КИЛӘ!

Сизәсезме, якты өметләр белән Яңа ел якынлаша! Яңа елны быел безгә 2021 елның символы – Ак метал үгез алып килә. Күп мәшәкатьләре белән тарихта эзен калдырган кәбисә елыннан соң, 2021 ел тыныч булыр дип фаразлыйлар. Акыл белән уйланган, төпле фикерләр өстенлек иткән, җаваплы эшләр башкарганда зур тәвәккәллек сораган төпле ел булыр диләр аны. Чөнки бу сыйфатларның барысы да Үгезгә хас.

Үгез елы үзен көтеп алганнарын ярата. Аны шатландырыр өчен Яңа ел киченә күк, көрән, яшел, ак, металл төсендәге киемнәрне әзерләп куябыз. Кичке күлмәкләр кию дә мөһим түгел икән быел, джинсы чалбар, күлмәк, җиңел свитерлар сайларга да була. Аксессуарлар, шарф, яулыклар турында да истән чыгармагыз. Иң мөһиме – алар кызыл төстә булмасын!

Өстәлгә, киштәләргә үгез уенчыклар куябыз, ел символы төшерелгән кәгазь бизәкләр эләбез. Чыршыны аксыл, көмеш төсендәге шарлар, «мишура» белән бизәргә була. Аклык-сафлык төсе өй түреннән үк балкып торсын.

Бүләкләрне көнкүрештә кулланып булырлыкларны сайларга киңәш итәбез: телефон чехолы, термочынаяк, исемле футболка, өстәл уеннары, наушник, китаплар, «акыллы» будильник, йомшак плед, бияләйләр – менә дигән булачак!

Туып килүче елда мөһим эшләр күп булыр! Аларның барысын да «мөгез белән җир сөзеп» – бик тырышып башкарып чыкканда гына зур уңышларга ирешергә мөмкин. Үгез – үз артыннан авыр йөк сөйрәп барырга да, чирәм җирне иген чәчәрлек итеп сөреп чыгарга да сәләтле хайван. Шуңа күрә бу елда башланган яңа эшләрнең, проектларның асылына уңышы байлык салынган булыр. Эшләрегезнең нәтиҗәсенә ышаныгыз, нигезсез хыялларга ымсынып вакытыгызны әрәм итмәгез! Бигрәк тә җиргә нык басып торган хезмәт ияләренә – техник һөнәр белән бәйле кешеләргә, хәрбиләргә, исәп-хисап белән эшләүчеләргә финанс ягыннан уңышлы ел киләчәк.

Тыштан бик тәкәббер булып күренсә дә, Үгезнең уңай яклары да күп. Ул юмарт, киң күңелле. 2021 елда туган гаиләләр нык була дигән ышану да бар. Шулай ук бала табу, йорт җиткерү өчен дә Үгез елы уңышлы булачак. Яраткан кешеләр белән уртак планнар төзи торган рәхәт, җылы, ихлас аралашулар елы бу! Үзегезне яхшы якка үзгәртергә, хезмәттәшләр, күршеләр, туганнар белән араларны җайларга тырышырга кирәк. Тормыштагы һәр адымга мәгънә салынган булсын, көннәребез якты хыял-максатлардан гына торсын!

Йә, рәхим ит, Үгез елы! Хәерле сәгатьтә!

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен
Раилә ХӘЯЛИЕВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.
Фото: www.pixabay.com



Яңа ел белән!



БОЛАК АРТЫ ҖӨМҺҮРИЯТЕ

Быел җәй Камал театрыннан ерак түгел, Кабан ярында, башкала кунаклары яратып өлгергән урында күренекле рәссам, график Нияз Тавил улы Хаҗиәхмәтовның ачык һавада «Болак арты җөмһүрияте» дип аталган бик үзенчәлекле күргәзмәсе ачылган иде.

Модерн стилендәге плакатларда шәһәрнең горур карашлы, хәтта аз гына һавалы көяз ханым-әфәнделәре Европа төсмере чагылган купшы һәм зәвыклы милли киемнәрдә, кыйгач калфакларда, ретро машиналарда сурәтләнә анда. Казанның истәлекле урыннары, романтик рухтагы архитектура үрнәкләре булган Апанаев, Шамил, Шакир-солдат йортлары, Камал театры, Сөембикә манарасы шәрехләнә.

Традицион постерларга нигезләнеп эшләнгән картиналарда XX гасырда Казанның Татар бистәсендә яшәүчеләрнең документаль тарихы фаразланганын аңлап була. Картиналар фонында кичке радиоалгычлардан татар джазы яңгыравы да юкка гына түгелдер! Рәссамның идеясе белән джаз музыкасының асылы бер дулкында тибрәлә, азатлык рухы аваз яра сыман. Милли үзаңыбызның тарих төпкелендә калган тирән кайтавазы күргәзмә исемендә аерым бер тирән мәгънәгә ия.

«Идел-Урал штаты» проектын тар-мар итәләр, милли республика юкка чыгарыла. Мин аны торгызып, булган әйберләрен югалтмыйча, бергә туплап бирергә тырыштым, – ди рәссам үзе. – Тамырлар киселмәсә, без мәдәниятебез белән Европа югарылыгына ирешерлек халык була алыр идек. Рәсемнәрдә менә шул фәлсәфәне күрергә кирәк. XX гасырның 20–30 нчы еллары – халкыбызның югарыга үрелгән кабатланмас бер кыска чоры була. Әйтерсең лә кабынып алган да, кинәт янган ул. Мин шул мизгелдә булып өлгергән хәлләрне картиналарымда гәүдәләндерергә тырыштым. Үзебезнең шәһәр культурасы турында күптәннән уйланып йөрим. Булган бит ул! Иске фотоларда – затлы киенгән, югары мәдәнияткә омтылган татарлар... Тарихыбыз махсус киселмәгән булса, нинди дәрәҗәләргә ирешелер иде дип, үзебезнең башкача язылырга мөмкин булган тарихыбызны күзалларга тырышам. Г. Камалның «Беренче театр»ында да әйбәт күренә бу хөр күтәрелеш. Бу чорны Бакый Урманче да үзенең «Печән базары, Яхуд яңа Кисекбаш» сериясендә тасвирлап күрсәткән иде.

Сурәтләрдәге хатын-кызларның берсе дә кемнедер күз алдында тотып ясалмады. Хикмәт татар хатын-кызларының образы универсаль булуында. Аларда Европа чалымы да бар, Азиянеке дә. Минем әни менә зәңгәр күзле булган. Ләкин ул татар хатыны! Безнең глобаль халык булуыбыз турында сөйли бу фактлар. «Болак арты җөмһүрияте» күргәзмәсендә дә кемдер сурәтләрне үзенә охшата икән, бу бары тик очраклылык кына.

Күргәзмәнең дәвамы булырмы дип сорыйлар. Әлегә бер ни дә әйтә алмыйм, бер кергән суга икенче кабат керергә яратмыйм. Әмма бу теманың дәвам ителүен теләр идем. Кыска гына вакыт аралыгында да татар модерны тарихта шактый якты эз калдыра. Киләчәктә аны өйрәнүчеләрне кызыклы ачышлар көтә».

Нияз Хаҗиәхмәтов И. Репин исемендәге Ленинград рәсем, скульптура һәм архитектура институтын тәмамлый. Бакый Урманче исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Ул Казан тарихына багышланган бик күп саллы картиналар иҗат итә. Казан метросының Кремль тукталышын милли бизәкләр белән тулыландырган дизайнер, ТАССРның 100 еллык юбилеена багышланган рәсми эмблема авторы, китаплар бизәүче иллюстратор буларак та таныш ул безгә.

Раилә ХӘЯЛИЕВА


Рәссам Нияз Хаҗиәхмәтов эшләре.
«Болак арты җөмһүрияте» сериясе.

ИЮЛЬ

Д		5	12	19	26
С		6	13	20	27
Ч		7	14	21	28
П	1	8	15	22	29
Җ	2	9	16	23	30
Ш	3	10	17	24	31
Я	4	11	18	25	

ОКТЯБРЬ

Д		4	11	18	25
С		5	12	19	26
Ч		6	13	20	27
П		7	14	21	28
Җ	1	8	15	22	29
Ш	2	9	16	23	30
Я	3	10	17	24	31



АВГУСТ

Д		2	9	16	23	30
С		3	10	17	24	31
Ч		4	11	18	25	
П		5	12	19	26	
Җ		6	13	20	27	
Ш		7	14	21	28	
Я	1	8	15	22	29	

НОЯБРЬ

Д	1	8	15	22	29
С	2	9	16	23	30
Ч	3	10	17	24	
П	4	11	18	25	
Җ	5	12	19	26	
Ш	6	13	20	27	
Я	7	14	21	28	



СЕНТЯБРЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

ДЕКАБРЬ

Д		6	13	20	27
С		7	14	21	28
Ч	1	8	15	22	29
П	2	9	16	23	30
Җ	3	10	17	24	31
Ш	4	11	18	25	
Я	5	12	19	26	

Рәүфәл МӨХӘММӘТҖАНОВ, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры директоры





Милли репертуарыбызны барлап утырдым. «Алтынчәч», «Җәлил», «Сөембикә», «Шагыйрь мәхәббәте» опералары... «Алтын Урда», «Йосыф турында риваять» балетлары, Фәрит Яруллинның милли классик югарылыктагы «Шүрәле»се! Һәркайсы гүзәл сәнгать әсәре бит!

Күптән түгел Казан операсына – 145, ә татар опера һәм балет театры оешуга 80 ел тулуны билгеләп үткән идек. Шул дәвердә Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры Россиядәге иң дәрәҗәле музыкаль театрларның берсенә әйләнде. Аның репертуарында – дөнья музыкасы җәүһәрләре, рус классикасы, татар композиторларының данлыклы әсәрләре.

Соңгы елларда төрле халыкара проектларда катнашу театрыбызны заманча дөнья музыкасы театры дәрәҗәсенә күтәрде. Голландия, Германия, Австрия, Швеция, Швейцария, Франция, Бөекбритания театрларында узган Халыкара гастрольләр турнесында Европа тамашачысына ел саен йөздән артык спектакль тәкъдим итте безнең артистлар. Алар чыгышына яңгыраган алкышлар Татарстаныбызны да зурлау ул!

Фёдор Шаляпин исемендәге опера фестивале, Рудольф Нуриев исемендәге классик балет фестивале, «Үзгәреш җиле» татар җыры фестивале... Болар инде республикабызның мәдәни бренды статусын алды! Ул фестивальләрдә безнең сәхнәдән дөнья театрлары солистлары чыгыш ясый. Лондонның Ковент-Гарден һәм Париж Операсы, Бавария Милли балеты һәм Берлин Дәүләт балеты, Санкт-Петербургның Мария театры, Мәскәүнең Зур театры артистлары... «Үзгәреш җиле» концерты Нью-Йоркның атаклы Карнеги-холлында аншлаг белән узды! Татарстаныбызны халыкара дәрәҗәдә таныйлар!

Ә узып баручы ел вакыйгаларга, юбилейларга бай булды. ТАССРның 100 еллыгы, Бөек Җиңүнең 75 еллыгы...

Безнең театрда – тагын бәйрәм! Премьера! Яңа елны каршыларга әзерләнгәндә, рок яратучы, операга гашыйк затлы тамашачыбызга бүләк әзерләдек – «Алтын Казан» мюзиклы! Татарстаныбызның олы юбилей чараларына йомгак ясап, иҗат уңышларыбызны әнә шул югарылыкта тәкъдим итәргә булдык.

Һәркайсыгызга чын бәйрәм кәефе, онытылмас кичерешләр телим!

